ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# НИГЪМӘТУЛЛА СОЛТАНБӘКОВ ӘСӘРЛӘРЕ

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# НИГЪМӘТУЛЛА СОЛТАНБӘКОВ ӘСӘРЛӘРЕ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2024

**УДК 930.2+821.512.145-1**
**ББК 63.212+84(2=632.3)-5**
**С 61**

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
*Раиф Мәрданов*

**С 61** Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2024. – 248 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 33 нче китап).

Китапта Нигъмәтулла Солтанбәковның (1841–1928) шигырьләре, дүрт мәрсиясе һәм үзе төзегән нәсел шәҗәрәсе – 1895–1925 еллар арасындагы әсәрләре туплап бирелде.

Фаҗигале язмышлы (38 ел урын өстендә яткан) Нигъмәтулла мулланың сагышлы-моңлы иҗаты татар әдәбияты тарихын, һичшиксез, баета. Әсәрләреннән аның тирән дини белемле, киң мәгълүматлы, хөр карашлы һәм тәнкыйди фикерле әдип булганлыгы аңлашыла.

ISBN 978-5-88473-106-6

**УДК 930.2+821.512.145-1**
**ББК 63.212+84(2=632.3)-5**

© Мәрданов Р.Ф., 2024
© «Милли китап» нәшрияты, 2024

# «ОНЫТМАГЫЗ БУ ЗӘГЫЙФЬНЕ...»

«Татар археографиясе» сериясенең әлеге китабы Нигъмәтулла Солтанбәковның (1841–1928) шигъри иҗатына багышлана. Аның исеме татар әдәбияты тарихында күпмедер билгеле булса да, әсәрләре басылмаган.

Нигъмәтулла Мөхәммәтсафа улы Солтанбәков Мамадыш өязенең (хәзерге Татарстан Республикасының Мамадыш районы) Югары Ушмы авылында мулла гаиләсендә туган һәм шунда гомер кичергән. Бу авылда аның бабасы Колмөхәммәт Солтанбәк улы XIX гасыр башында имам булган һәм шигъри әсәрләр иҗат иткән. Колмөхәммәтнең улы Мөхәммәтсафа һәм оныгы Нигъмәтулла да XIX гасырда Югары Ушмыда имамлык вазифаларын үтәгәннәр.

1891 елда Нигъмәтулла хәзрәт авыруга дучар булган һәм гәүдәсе хәрәкәтсез калган диярлек. Ул яткан хәлендә, тырышып каләм тотып, иҗади язмаларын теркәгән. Ә аңарчы – сәламәт вакытында – мәрхүм авылдашларына һәм күрше-тирә төбәкләр өчен ул кабер ташлары язу белән дә шөгыльләнгән. Аның тарафыннан эшләнгән дистәләрчә ташъязма истәлекләр татар эпиграфикасы тарихында аерым урын били.

Нигъмәтулла Солтанбәковның безнең көннәргәчә килеп ирешкән кульязма җыентыклары белән танышкач, әдәбиятыбыз тарихына тагын бер үзенчәлекле шагыйрь исеме өстәлергә тиешлеге аңлашыла.

## Туган авылы турында кыскача

Нигъмәтулла Солтанбәков «Шәҗәрә» әсәрендә туган авылы Югары Ушмыны «Морзалар Ушмысы» дип атаган һәм анда морза Бакиевлар нәселе, шулай ук башка морзалар яшәгән дип язган. Чынлыкта да, Югары Ушмы авылы борынгы дәверләрдән үк килгән бай тарихка ия.

Авылның нигезләнү тарихына караган риваятьне галим Марсель Әхмәтҗанов элегрәк бастырган иде. Мәсәлән, 2002 елда

дөнья күргән бер хезмәтендә түбәндәгечә язылган: «Югары Ушманы икенче исем белән Морза дип, шулай ук аны русча Ярмаково дип тә атаганнар. Аннан аңлашылганча, Югары Ушма авылын Ярмәк морза биләгән икән. Бу хакта түбәндәге риваять тә кызыклы.

Югары Ушмага иң беренче булып Ярмөхәммәд (Ярмәк) исемле морза килеп утырган. Ул бик бай кеше була һәм, авыл тирәсендәге сазлык урманнарны бетереп, ул җирләрдә колларыннан көтүлекләр эшләтә. Күрше авыллар авылны шуңа «Морза авылы» дип йөрткәннәр, ә руслар «Ярмәк» дип атаганнар. Нократ буенда яшәгән Кара бәк нәселе шәҗәрәсендә Ярмәк морза исемле кеше бар. Кара бәктән таралган морзалар Арча, Биектау, Кукмара, Саба, Алабуга, Әгерҗе төбәкләрендә җирләр алып утырганнар. Югары Ушманы нигезләгән Ярмәк морзаны да шушы нәселгә нисбәт итәбез»[1]. Әлеге китапта Югары Ушмыда язып алынган, элекке бабалары Ярмәк морзага тоташкан нәсел шәҗәрәсенең төп буыннары тәкъдим ителгән һәм М.Әхмәтҗанов аңа аңлатма биргән. Андагы буыннар тәртибенә галим төзәтмә кертеп, әүвәлгерәкләрен дә өстәгән: «Рахманкол морзаның атасы Морат морза, Моратның атасы Ибраһим морза, Ибраһимның атасы Ярмәк морза, Ярмәкнең атасы Дустмөхәммәт морза, Дустмөхәммәтнең атасы Пәйке морза, аның атасы Биги бәк, аның атасы Чуаш бәк, аның атасы Әлсуфый, аның атасы Гали бәк, аның атасы Кара бәк»[2].

Бу авылның XVII гасырда ук татар морзалары карамагында булганлыгы тарихи чыганаклар белән раслана. Югары Ушмы зиратында XVII гасырга караган ике кабер ташы сакланган. Аларның берсе Дүскәй морза улы Ярмөхәммәт морза каберенә куелган таш, бу шәхеснең вафаты 1695 елда дип язылган. Әлеге Ярмөхәммәт исеме кыскартылган рәвештә Ярмәк дип йөртелгән дә инде. Ә Дүскәй исеме – Дустмөхәммәтнең кыскартылган варианты. Бу ташъязмадагы исемнәрне хезмәттәшем Ирек Һадиев белән бергә

[1] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 242–243.
[2] Шунда ук. – Б. 243.

ачыклап, тулы текстын бастырган идек[3]. Ярмөхәммәт морзаның кабер ташын икетуган кардәше Килмөхәммәт морзаның улы Колмөхәммәт язып куйганын, шулай ук аларның Карабәк нәселе дәвамчылары булганлыгын, тарихи мәгълүматларга нигезләнеп, аңлаткан идек[4]. Аерым алганда, Казан өязенең 1647–1656 еллардагы теркәү кенәгәсендә булган әлеге нәсел вәкилләренең исемнәре һәм биләмәләре турында мондый мәгълүмат бастырдык: «За служилыми мурзами за Ишмаметем да за Доскеем Бакеевыми деревня Ошма на реке Ошме... За служилыми мурзами за Ишмаметем да за Доскаем Бигеевыми сельцо, что была деревня Буж на речке Бужевке...»[5].

Димәк, Югары Ушмы авылы җирләре 1640 нчы еллардан ук Ярмөхәммәт морзаның этисе Дустмөхәммәт һәм аның кардәше Ишмөхәммәт биләмәсендә булган. Ә йомышлы татар Бәйкәй морза Бигиевнең Арча юлындагы Бужа авылында (хәзерге Арча районы территориясендә) биләмәләр тотканлыгы, аның ата-бабаларының Казан ханлыгы дәвереннән үк шунда хуҗа булганлыгы 1602–1603 еллардагы теркәү кенәгәсендә язылган[6].

Югары Ушмы авылы зиратында Ярмөхәммәд морзаның 1697 елда вафат булган хатынына куелган кабер ташы да сакланган. Анысын да Колмөхәммәт Килмөхәммәт улы язган. Бу кабер ташындагы хатын-кыз исеме хаталы язылганга күрә, аны төрлечә укып фаразларга мөмкин, дөресе – Җәмиләсолтан булгандыр.

Югары Ушмыда мәчет-мәдрәсәләр төзүне һәм аларны тәэмин итүне Ярмәк морзадан дәвам иткән нәсел тармаклары үз өсләренә алганнар. Бу турыда Нигъмәтулла Солтанбәков та язып калдырган.

## Автор һәм аның нәселе

Нигъмәтулла Солтанбәков Югары Ушмы авылының Мөхәммәтсафа мулла гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгән.

[3] Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2015. – Б. 146.
[4] Шунда ук. – Б. 12.
[5] Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов. – Москва, 2001. – С. 214, 382.
[6] Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов: публикация текста. – Казань: изд-во Казанского ун-та, 1978. – С. 134–135.

Ул Түнтәр авылындагы данлыклы Гали ишан мәдрәсәсендә укыган булса кирәк. Нигезле белем алганнан соң Нигъмәтулла, үз авылларында имам булып, зур абруй казанган. Ләкин 50 яшендә – 1891 елның 31 май көнендә кинәт сырхауга дучар булып, зәгыйфьләнеп һәм хәрәкәте чикләнеп, аннан соңгы гомерен урын өстендә ятып уздырган. Авылдашларының хатирәләренә караганда, Нигъмәтулла мулланы, «авыру булганлыктан, арба белән генә йөрткәннәр»[7].

Аллаһы Тәгалә озын гомер насыйп итеп, Нигъмәтулла мулла калган 38 елын түшәктә үткәргән, шигъри әсәрләр иҗат иткән. Аны хатыны – Бибитаибә Могтәмидшаһ мулла[8] кызы – 34 ел дәвамында бала урынына тәрбияләгән. Бибитаибә абыстай 1924 елның 26 декабрендә кинәт дөнья куйганнан соң, хәзрәт тагын 4 ел яшәп, 88 яшенә җитеп, 1928 елның 28 декабрендә вафат булган. Югары Ушмы авылының зиратында икесенең дә каберләре билгеле, ташлары сакланган. Абыстайныкында «53 ел Югары Ушмы авылында тәгълим-тәрбия эше белән шөгыльләнү белән бәрабәр, 34 ел аяныч зәгыйфь хәлдә калган ирен тәрбия кылып, зәгыйфь иреннән алда вафат итте» диелгән булса, Нигъмәтулла мулланыкында «38 ел аяксыз» ятканлыгы искәртелгән. Әлеге ике кабер ташы да Морт авылында (хәзерге Алабуга районында) яшәгән мәзин Мөхәммәтзакир Мөхәммәтшакир улы тарафыннан язылган.

Солтанбәковларның нәсел дәвамчылары – уллары һәм кызлары калган. Нигъмәтулла мулла 1895 елда төзегән шәҗәрә сызымында үз нәселләрендәге Бибишәргыя Габдессаттар мулла кызының исеме янәшәсендә «зәгыйфь мулла Нигъмәтулла мәнкүхәсе»

---

[7] Зәйниева Г. Кол Мөхәммәднең шигъри иҗаты: текстология, проблемалар һәм тел үзенчәлекләре. – Казан, 2006. – Б. 17.

[8] *Могтәмидшаһ мулла* – Югары Сон авылының имамы булган дип фаразладык. Хәзерге Мамадыш районындагы Югары Сон авылы зиратында 1891 елның 21 гыйнварында вафат булган «дамелла Могтәмидшаһ мулла Габделҗәлил ишан угылы»на куелган кабер ташы бар (Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре…, 2015. – Б. 136). Ташның язып куючы остасы күрсәтелмәгән булса да, аның эшләнешеннән һәм бизәлешеннән Нигъмәтулла Солтанбәков башкарганлыгы аңлашыла. Нигъмәтулла мулла үзе нәкъ шул елда сырхауга дучар булганлыктан, бәлки, энесе Хөҗҗәтулла, Могтәмидшаһ хәзрәтнең кабер ташын язып, эшен төгәлләгәндер.




*Нигъмәтулла мулланың кабер ташы*

(ягъни, никахлы хатыны) дип искәрткән. Бу мәгълүматка карaганда, Нигъмәтулла мулланың Бибитаибәдән башка (аңа кадәрге үк) хәләл җефете дә булган. Шәҗәрә сызымында Нигъмәтулла хәзрәтнең барлыгы 15 баласы теркәлгән. Аларның икесе ир бала – Мөхәммәтфатих һәм Нурелфуад, калган унөче – кызлар. Әлеге балалар хәзрәтнең ике хатынынnan туганнар[9]. Нигъмәтулла мулла балаларының күбесе кызлар булганга, ул шигырьләренең шактыен аларга атап һәм багышлап язган. Ихтимал, әсәрләрен күчереп балаларына тараткан булгандыр.

Нигъмәтулла хәзрәтнең әтисе Мөхәммәтсафа 1867 елда дөнья куйган, авыл зиратында кабере билгеле, ташы сакланган.

[9] Һәрхәлдә, 1866 елда вафат булган кызы Гыйззеҗамал беренче хатынынnan туган. Чөнки Бибитаибә абыстай белән 55 ел гомер сөргәнлекләрен искә алганда, Нигъмәтулла мулла аңа 1869 елда никахланган. Н.Солтанбәков биографиясенең үзебезгә мәгълүм булган хәтлесен гомуми рәвештә генә яздык. Аның тормыш юлын архив чыганаклары нигезендә тәфсилләп өйрәнүне өстебезгә йөкләмәдек.

Мөхәммәтсафаның әтисе Колмөхәммәт Солтанбәков-Ушмыви (1777–1849) Уфа губернасының Стәрлетамак өязендәге Карамалы (хәзерге Башкортстанның Авыргазы районындагы Яңа Карамалы) авылында дөньяга килгән. Үз чорының мәшһүр мәдрәсәләреннән Мәчкәрә авылында (хәзерге Кукмара районында) Мөхәммәтрәхим ахуннан[10] белем алганнан соң, 1802–1803 еллардан алып Югары Ушмы авылында имамлык вазифасын башкарган, мәдрәсәдә укыткан. Ул XIX гасыр башында шигъри әсәрләр – дини-әхлакый эчтәлекле тезмә нәсихәтләр иҗат иткән. Оныгы Нигъмәтулла бабасы Колмөхәммәтнең «Иказ тәрҗемәсе», «Тәгърифел-вилдан», «Мөһиммә әс-сыйбиян», «Тәгаллемел-ихван» исемнәрендәге дүрт әсәр язганлыгын теркәп калдырган[11].

Колмөхәммәт Солтанбәковның әсәрләре үз вакытында халык арасында кулъязма күчермәләр рәвешендә таралган һәм укылган. Аның шигъри үрнәкләре кулъязмалар хәлендә Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының музыкаль һәм язма мирас үзәгендә, шулай ук Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана.

Югары Ушмы авылындагы мәдрәсә 1830 елда янгында харап

---

[10] Мөхәммәтрәхим әл-Ашытый Мәчкәрә мәдрәсәсендә 1780–1818 елларда мөдәррис булып торган. Аның турында Шиһабетдин Мәрҗани бик зурлап язган (Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б. 263–264). Бу укымышлы нәселнең шәҗәрәсе «Татар археографиясе» сериясенең 28 нче китабында басылды: Шәҗәрәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 61–66. Мөхәммәтрәхим ахунның «Ашытый» дигән нисбәсенә күрә, аның мәдрәсәсе Ашыт авылында булган һәм шагыйрь Колмөхәммәт шунда укыган дип язучылар ялгышалар. Н.Солтанбәковның «Шәҗәрә» әсәре текстында Колмөхәммәтнең «Казан йирендә» укуы турындагы сүзләр дә «Казан ягы» мәгънәсендә булып, шагыйрьнең Мәчкәрәдә укуы күздә тотылган. «Казан йире» дигәнне Г.Зәйниеваның «Казанга килеп белем туплый башлый» дип язуы (Зәйниева Г. Кол Мөхәммәднең шигъри иҗаты... 2006. – Б. 9) дөрес түгел.

[11] Шагыйрь Колмөхәммәтнең иҗатын Гөлнара Зәйниева фәнни яктан өйрәнеп, 2002 елда филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклаган иде (Зайнеева Г.Н. Поэт Кул Мухаммед (жизнь и творчество). Автореф. дисс. на соиск. уч. ст. канд. филол. наук. – Казань, 2002. – 20 с.).

булгач, Колмөхәммәт Солтанбәк улы гаиләсе белән үзенең туган ягына кайтып киткән. Анда мәшһүр мөдәррис буларак танылган. Улы Мөхәммәтсафа Югары Ушмыда имам булып калган.

Нигъмәтулла Солтанбәков язганга караганда, бу нәселдән 50-дән артык имамнар чыккан. Аларның кайберләре әйтеп үтелгән Югары Ушмы авылында, шулай ук Мамадыш һәм Кукмара төбәгендәге башка авылларда имамнар һәм мәзиннәр булып хезмәт иткәннәр. Әлеге нәсел вәкилләре Колмөхәммәт хәзрәтнең туган якларында да мулла булып торганнар. Димәк, Нигъмәтулла Солтанбәков укымышлы һәм бәрәкәтле нәсел вәкиле булган. Шигъри иҗатка сәләте Колмөхәммәт бабасыннан килгәндер, һәрхәлдә, аның йогынтысы көчле булганлыгы аңлашыла.

Фамилияләре Колмөхәммәтнең әтисе – XVIII гасырда яшәгән Солтанбәк исеменнән дәвам иткән. Нигъмәтулла мулла шәҗәрәсендә язылганга караганда, Солтанбәк Мөхәммәтшәриф улы Стәрлетамак төбәгендә җирле гаскәри-административ идарә җитәкчеләреннән булган. Солтанбәктән элеккеге буыннары: аның әтисе Мөхәммәтшәриф, аның әтисе Габдулла, аның әтисе Уразкилде булганлыклары билгеле. Бу исемнәр әлеге нәсел дәвамчыларының шәҗәрә сызымнарында язылган[12]. Төп буыннарның тәртибе һәм аларның дәвамы булган күп тармаклары Нигъмәтулла Солтанбәков язып калдырган шәҗәрәгә дә тәңгәл килә. Нигъмәтулла мулла схемасында Уразкилдедән элеккеге буыны да теркәлгән. Әлеге исем кульязмада начар күренсә дә, аны Мөхәммәт дип язылганга охшаттык.

Бу нәселнең төп яшәгән урыны Яңа Карамалы тарихына багышланган китапта әлеге авылны чукындырудан качып килгән Казан ягы татарлары 1635–1638 нче елларда нигезләгән дип язылган[13]. Карамалы халкын архив документларында башта ясаклы татар буларак язганнар, XVIII гасырның икенче яртысыннан «типтәр» катлавында теркәгәннәр. Оренбург губернасындагы типтәрләр 1855 елда башкорт гаскәри идарәсенә кертелгән.

---

[12] Солтанбәков Ф. «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...» (Җәлилче истәлекләре). – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2001. – Б. 139.

[13] Сулейманов Р., Мулюков Г., Сафин М. На миркитминской земле. – Уфа, 2007. – С. 9. Бу китапта Солтанбәковлар нәселенә бәйле XVII–XX гасырлардагы мәгълүматлар шактый.

Югары Ушмыда мулла булып торган Колмөхәммәт Солтанбәк улы һәм аның дәвамчылары да рәсми документларда ата-бабаларының төп яшәгән урыннарында – Яңа Карамалы авылында теркәлгәннәр. Яңа Карамалы тарихы китабында архив документлары (халык исәбен теркәү язмалары) нигезендә авылның барлык нәселләренең шәҗәрәләре язылган. Анда 1841 елда туган Нигъмәтулла Мөхәммәтсафа улының исеме дә бар. Китапта Солтанбәковлар шәҗәрәсе иң зур нәселләрнең берсе буларак, архив чыганакларыннан ачыкланган борынгы бабалары исеменә нисбәт ителеп, «Байтирәк нәселе» дип бирелгән. Архив документлары нигезендә төзелгән шәҗәрәнең элеккерәк буыннары Нигъмәтулла Солтанбәков язып калдырган шәҗәрәгә тәңгәл килеп бетми һәм туган-үлгән еллары да Ф.Солтанбәков белән Г.Зәйниева китапларында[14] күрсәтелгәннән башкачарак.

Ф.Солтанбәков һәм Г.Зәйниева китапларында язылган Н.Солтанбәков шәҗәрәсендә төп буын вәкилләре һәм аларның яшәгән еллары бу рәвешле: Уразкилде (1610–1672) – Габдулла (1650–1720) – Мөхәммәтшәриф (1690–1755) – Солтанбәк (1735–1799) – Колмөхәммәт (1775–1845) – Мөхәммәтсафа (1805–1875).

Архив документлары нигезендә төзелгән шәҗәрәдә исә төп буыннар исә мондый: Байтирәк – Уразмәт (1659–1747) – Шәриф (1711–1789) – Солтанбәк (1750–1806) – Колмөхәммәт (1777–1849) – Мөхәммәтсафа (1810).

Беренче вариантта Мөхәммәтсафаның вафат елы тәгаен дөрес түгел, чөнки аның кабер ташында 1867 елда үлгәнлеге теркәлгән. Колмөхәммәтнең һәм башка буыннарның туган-үлгән еллары да архив чыганакларыннан аермалы. Мөхәммәтшәриф (Шәриф) исеменнән әүвәлге исемнәр тәңгәл килми.

Мондый очракта, әлбәттә, архив документлары ышанычлырак. Әмма әлеге нәсел вәкилләре төзегән шәҗәрәне дә бөтенләй кире кагып булмый. Чөнки аларның шәҗәрәсендәге Мөхәммәтшәрифнең әтисе итеп күрсәтелгән Габдулла исеме ялгышлык белән генә

[14] Нигъмәтулла Солтанбәковның «Шәҗәрә» әсәре һәм схематик сызымыннан тыш, әлеге нәселнең XX гасырдагы шәҗәрә мәгълүматлары Фәрит Солтанбәков китабында һәм Г.Зәйниева хезмәтендә дә бирелгән (Солтанбәков Ф. «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...» ..., 2001. – 240 б.; Зәйниева Г. Кол Мөхәммәднең шигъри иҗаты..., 2006. – 132 б.).

теркәлмәгәндер. Ихтимал, ул төп буындагы кайсыдыр бабаның бертуганы булгандыр (иске шәҗәрәләрдә бертуганнардан берәрсенең исемен аерым буын итеп ялгыш язу очраклары булган). Яңа Карамалы авылы китабындагы «Байтирәк нәселе»ннән соң «Габдулла нәселе» шәҗәрәсе бирелгән булуы да бу фикерне куәтли. Архив чыганакларында бөтен нәрсә дөп-дөрес дигән сүз түгел, Уразкилде дигән исем рәсми документка Уразмәт дип ялгыш теркәлеп калган булуы да мөмкин бит. Шулай ук, архив документында Нигъмәтулланың энесе Гайфулла дип теркәлгән исем Н.Солтанбәков төзегән шәҗәрәдә юк, ә Гарифулла дигән энесе бар. Һәрхәлдә, шәҗәрә вариантларын тәфсилләп өйрәнгәндә, кайбер тәңгәл килмәгән мәсьәләләрне ачыкларга мөмкиндер.

Солтанбәковлар нәселенең тарихы бик бай һәм шәҗәрәләре күптармаклы. Бу нәсел вәкилләренең каһарман җәлилче Фәрит Сәхиулла улы Солтанбәков (1916–2002) кебек мәшһүр затлары да булган. Ул – Нигъмәтулла мулланың бертуган энесе, Югары Ушмы авылы мәчетендә хезмәт иткән Гарифулла мәзиннең оныгы.

Фәрит Солтанбәковның китабы мондый юллар белән башлана: «Минем әтием – Сәхиулла Гарифулла улы Солтанбәков – Казан губернасының Мамадыш өязендәге Югары Ушмы авылында туып, шунда үскән. Дәү әти дин мәктәбендә укып, Югары Ушмы авылындагы мәчеттә мөәзин булып эшләгән... Әтием хәзерге Балтач районының Түнтәр авылындагы атаклы мәдрәсәдә белем алган...». Аннан соң автор 1911 елда әтисенең Луганск өязендәге Ирмино шәһәренә китеп шахтёр булып эшләвен, 1915 елда туган ягына кайтып өйләнгәнен һәм яңадан китеп баруларын, «шунда 1916 елның маенда мин дөньяга килгәнмен»[15] дип язган. 1923 елда гаиләләре белән туган якларга кайтып, Тарлау авылында[16] яши башлаганнар, әтисе шунда имам булган. Эзәрлекләнү еллары

[15] Солтанбәков Ф. «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...» ..., 2001. – Б. 5–6.
[16] Китапның 6 битендә (татарча текстта) Тарлау авылы янәшәсенә җәяләр эчендә «хәзер Саба районына керә» дип искәртелгән, ләкин текстның рус телендәгесендә Саба районына нисбәт иткән искәрмәсе юк. Хәзерге Саба районындагы Язлы-Арташ авылының элекке исеме Тарлау булган. Әмма электрон чыганакларда исә Кукмара районындагы Тарлау авылы мулласы Сәхи Солтанбәковның 1930 ел көзендә «халык дошманы» буларак кулга алынганлыгы турында мәгълүмат бар. Безнең фикеребезчә, Сәхиулла Солтанбәков, чынлыкта, Кукмара районындагы Тарлауда имамлык иткән һәм гаиләсе белән шунда яшәгәндер.

турында Ф.Солтанбәков «әтиебез... түзмәде – яңадан читкә, эш эзләп чыгып китте. Авылда без – әни, мин, сеңелем генә торып калдык. Көннәрдән бер көнне безне өебездән үк куып чыгарып, авыл читендәге кечкенә генә, череп беткән бер алачыкка урнаштырдылар. Безгә авылда яшәргә көн бетте...» дип искә алган[17]. Шуннан соң алар Кукмара аша Казанга, ә 1930 елда Үзбәкстанга барып төпләнгәннәр. Китап авторы «әти-әни ягыннан байтак туганнарыбыз шунда яши иде» дигән. Әтиләре 1928 елда ук Ташкентка китеп урнашкан.

Фәрит Солтанбәков китабында бирелгән шәҗәрә сызымнарында Мөхәммәтсафа Колмөхәммәт улының дәвамчыларыннан Гарифулла (1845–1929), Сахипзадә (1850–1912), Тәхаветдин (1860–1944) тармакларының хәзерге заманга кадәрге буыннары теркәлгән[18].

Солтанбәковлар токымы дәвамчылары хәзерге заманда да ишле, алар арасында әүвәлге бабаларыннан килгән имамлык вазифасын үтәүче игелекле затлар да бар.

### Кабер ташлары ясау остасы

Сәламәт вакытында Нигъмәтулла мулла Солтанбәков кабер ташлары әзерләп, аларны язучы-бизәүче оста буларак танылган. Аның тарафыннан ясалган татар ташъязма истәлекләре аеруча сәнгатьле бизәлешләре, текстларының хатасыз булуы белән үзенчәлекле.

Гарәп язулы татар ташъязмаларын күп еллар дәвамында өйрәнеп килүче тәҗрибәле белгеч Ирек әфәнде Һадиев белән 1998 елның көзендә Кукмара районындагы татар мөселман кабер ташларын өйрәнгән вакытыбызда Нигъмәтулла мулла тарафыннан эшләнгән ташъязмаларны беренче тапкыр күргән идек. Ул үзе ясаган кабер ташларында махсус штампсыман яисә аерым юл итеп «кятибәһе мулла Нигъмәтулла» дип, исемен күрсәтеп яза торган булган. Нигъмәтулла хәзрәт һәм аның бертуган эне-

---

Ә Тарлау авылының исемен Саба районына нисбәт итү Ф.Солтанбәков китабын басмага хәзерләүчеләр тарафыннан өстәлгәндер. Китапта этисе Сәхиулланың яшәгән еллары 1886–1959 дип теркәлгән.

[17] Солтанбәков Ф. «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...» ..., 2001. – Б. 8–11, 86.

[18] Шунда ук. – Б. 139–142.



*Нигъмәтулла Солтанбәковның үзе уйган ташларда исемен белдергән хаттатлык тамгасы*

се Хөҗҗәтулла тарафыннан язылган зиннәтле һәм монументаль эшләнешле ташъязмалар бер-берсенә охшаш. (Бу ике бертуган оста тарафыннан язылган затлы истәлекләр башка төбәкләрдә дә ачыкланырга мөмкин әле).

Мамадыш районындагы мөселман татар авыллары зиратларындагы эпиграфик истәлекләрне өйрәнгәндә – 2012 елда Нигъмәтулла мулла Мөхәммәтсафа улы тарафыннан язылган кабер ташларын шактый күрдек. Югары Ушмы авылы зиратында 1867 елда вафат булган Мөхәммәтсафа мулланың кабер ташына «догаи хәер өмид кыйлып куелды әткәем – дамелла Мөхәммәдсафа мулла Колмөхәммәд угылының баш очына» дип язылган. Аның бизәкләре, өслекнең язу юлларына бүленеше, текстындагы кайбер гыйбарәләре XVII гасыр ташъязмаларына охшатып уелган. Ә алгы өслек тирәли төшерелгән кайма бизәк (чәчәк-үсемлек орнаменты) Казан ханлыгы дәвере традицияләрен кабатлый. 1893 елда вафат булган әниләре Бәдигыльҗамал Габделмәҗит кызының да кабер ташы шунда гына. Бу авыл зиратында Нигъмәтулла мулла ясаган 7 данә ташъязма (уючының исеме күрсәтелгәннәре) хәзерге вакыткача сакланган[19].

Нигъмәтулла мулла тарафыннан язылган иске кабер ташлары Мамадыш төбәгенең башка авылларында да бар. Әйтеп

[19] Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре..., 2015. – Б. 139–151.

үткәнебезчә, ул язган истәлекләр Кукмара районындагы авыл зиратларында да саклана. Шулай ук Балтач районында (Балтач бистәсенең зиратында) ул язган бер кабер ташы саклануын 2002 елда ачыклаган идек[20].

Гомумән, Нигъмәтулла мулла тарафыннан язылган кабер ташлары Мамадыш районында Югары Ушмы, Түбән Ушмы, Ишки, Кече Кирмән, Көмешкүл, Тулбай, Урта Кирмән, Шәмәк, Югары Сон авылларының һәм Мамадыш шәһәренең зиратларында барлыгы – 21 (исемнәре язылганы) данә, Кукмара районындагы Әсән-Елга, Битләнгур авылларында барлыгы 5 данә, Балтач районында – бер данә, Балык Бистәсе районының Балтач авылында – 1 данә. Бөтенесе бергә 28 кабер ташы. Аларның иң әүвәлгесе – 1866 елда вафат булган үз кызы Гыйззезҗамалга куелган, иң соңгысы исә Көмешкүл авылының 1906 елда дөньядан күчкән Шәмселбәдәр исемле кызның каберендә. Соңгысының 1906 елда куелган булуы аңлашылып җитми. Чөнки ул вакытта авыру Нигъмәтулла мулланың кабер ташлары язарлык физик мөмкинлеге булмаган. Күрәсең, ул әлеге ташка уелырга тиешле текстны кәгазьгә язып бирүче буларак катнашкандыр һәм, бәлки, аның бизәлеш өлгеләре кулланылгандыр.

Нигъмәтулланың бертуган энесе Хөҗҗәтулла[21] (1852–1899) тарафыннан эшләнгән кабер ташларының безгә мәгълүмнәре Мамадыш, Кукмара, Алабуга һәм Балык Бистәсе районнарында 18 данә (исеме күрсәтелгәннәре). Ул ясаган иң элекке ташъязма 1862 елда, ә соңгысы 1895 елда вафат булган кешеләргә куелган.

Ташъязмаларның үзләрендә исемнәре күрсәтелмәгән, әмма эшләнешләре буенча бу ике останыкы дип әйтерлек, дистәләгән башка кабер ташлары да бар. Андыйларның кайсын кем ясаган булуын төгәл билгеләү читен, чөнки Нигъмәтулла һәм Хөҗҗәтулла, шулай ук алар белән бер чорда ташлар уюы белән шөгыльләнгән якташлары – Югары Ушмы күршесендәге Иске Завод авылының Шаһимәрдан Бәйкиев хәзерләгән кабер ташла-

---

[20] Һадиев И., Мәрданов Р. Балтач төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Яр-Чаллы: «Ислам нуры» дини-эшмәкәрлек үзәге, 2021. – Б. 14, 24–25.

[21] Хөҗҗәтулла Мөхәммәтсафа улы Түнтәр авылындагы данлыклы Гали ишан мәдрәсәсендә укыган, 1889 елда имамлык шәһадәтнамәсе алган. 1899 елның 28 ноябрендә вафат булган (кабер ташында 1900 елда дип уелган). Татарстан Милли китапханәсендә Хөҗҗәтулла Солтанбәковның да кульъязмасы бар.

ры төп калыплары, бизәлеш элементлары һәм язу үзенчәлекләре белән бер-берсенә бик охшаш.

Татар эпиграфик ядкәрләрен өйрәнүче замандашыбыз Айдар Гайнетдиновның Солтанбәковлар турында махсус мәкаләсе дә булды. Анда әтрафлы мәгълүмат бирелгән. Шулай да, Н.Солтанбәковның авыру хәлендә ташлар язган булуы турындагы, бигрәк тә хатыны Бибитаибә абыстайныкы «ире тарафыннан язылган булса кирәк»[22] дигән фикерләре ялгыш. Чөнки, беренчедән, Нигъмәтулла мулла кабер ташларын язу эше белән авыруга дучар булганчы (1891 елга кадәр) шөгыльләнгән һәм, икенчедән, Бибитаибә абыстайның кабер ташы, алда әйтеп үтелгәнчә, Морт авылы мәзине Мөхммәтзакир тарафыннан уелган.

***

«Балык Бистәсе районы эпиграфикасы» китабында (авторлары: Венер Усманов, Нурулла Гариф) Нигъмәтулла Солтанбәков турында язылган мәгълүмат ачыклык кертүгә мохтаҗ.

Бу хезмәттә (21 биттә) язылганга караганда, 1864 елда 65 яшендә вафат булган ишан, хаҗи Габдулла мулла Ислам улының Котлы Бөкәш авылы зиратында сакланган кабер ташындагы икенче юлында «әл-мәет Нигъмәтулла хәзрәт хәлифәсе» диелгән. Нигъмәтулла исеменә карата китаптагы аңлатмада «Нигъмәтулла Мөхәммәтсафа угылы Солтанбиков, Югары Ошма авылы кешесе...» дип, безнең «Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре» китабындагы (144 биттәге) мәгълүмат күчерелгән[23]. Аннан соң «Балык Бистәсе районы эпиграфикасы» хезмәтенең авторлары: «Котлы Бөкәш авылы зиратындагы кабер ташының иясе мулла Габдулла Ислам улы мулла Нигъмәттулла белән таныш булган, яшь булса да, күрәмсең, аны, үзенең остазы дип санаган. Аның белән аралашкан, аның фәлсәфи уйлары белән бүлешкән» дип, ялгыш фаразлар теркәгәннәр.

---

[22] Гайнетдинов А. Ташка язу осталары бертуган Солтанбәковлар // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2015. – №3/4. – Б. 255–256.

[23] Усманов В., Гариф Н. Балык Бистәсе районы эпиграфикасы. – Казан, 2023. – Б. 21, 165–167. Бу китапта Солтанбәков Хөҗҗәтулла язган ташлар турында да мәгълүматлар бар. Аның исеме китапта Хөҗәтулла, Хаҗҗәтулла, Хаҗҗиатулла вариантларында язылган (21, 167 битләрдә).

«Ялгыш» дибез, чөнки, беренчедән, Габдулла мулла үлгәндә Нигъмәтулла Солтанбәков 23 яшендә һәм мәрхүмнән 42 елга яшьрәк кеше булган. Мондый очракта бернинди остазлык турында сүз булырга да мөмкин түгел. (Гомумән, китап авторларының әлеге ике мулла тыгыз бәйләнештә торган дип аңлатырга омтылуын төшенеп булмады). Икенчедән, Габдулла Ислам улының кабер ташындагы Нигъмәтулла исеме алдында китапның 21, 165, 166 нчы битләрендә төрлечәрәк итеп «әл-мәет», «әл-мәүт» һәм «әлмәййит» дип язылган (асылда бер үк) сүзнең дөресе – «Әлмәт» (ташъязманың китапта гарәп хәрефләре белән бирелгән текстында ул шулай басылган да). Ягъни, таштагы текстның башы «Әлмәт Нигъмәтулла хәзрәт...» дип укылырга тиешле. Ә ул исә бөтенләй башка шәхес. Кизләү ишаны Гобәйдулла мулланың өлкән улы Нигъмәтулла хәзрәт турында Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтендә аның Яңа Әлмәт авылында озак вакытлар имам-хатыйп һәм мөдәррис булганлыгы, ишанлык белән дә шөгыльләнеп, «Әлмәт ишан» исеме белән танылганлыгы язылган. Тарихчы Ризаэтдин Фәхретдин дә Чистай өязе Әлмәт авылының 1853 елда вафат булган Нигъмәтулла ишан Гобәйдулла улы турында язып калдырган[24]. Элекке Чистай өязенең Әлмәт авылы – хәзерге Норлат районындагы Яңа Әлмәт авылы. Нигъмәтулла Гобәйдулла улы XIX гасырның беренче яртысында шул авылның имамы булганлыгы һәм 1853 елда вафат иткәнлеге архив документлары белән раслана. Шулай итеп, Габдулла Ислам улы Яңа Әлмәт авылының Нигъмәтулла хәзрәт шәкерте булган.

## Кулъязмалары

Әдәбият тарихына караган мәкаләләрдә һәм фәнни хезмәтләрдә Нигъмәтулла Солтанбәков исеме 1980 нче елларда искә алына башлаган иде. Ул археограф Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан 1981 елда Саба районында табылган, бабасы Колмөхәммәт әсәрләреннән торган кулъязма җыентыкның күчерүчесе буларак һәм XIX гасырның икенче яртысында яшәгән

[24] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар ..., 1989. – Б. 293–294; Фәхреддин Р. Асар. Т. 2 / төз.: Гыймадиев И., Миңнуллин Р., Баһавиева С. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 56.

билгесез татар шагыйре дип телгә алынган[25]. Әлеге кулъязма истәлекнең соңрак басылган тасвирламасында аның Байлар Сабасы авылында Әсма Шәяхмәтовадан алынганлыгы белдерелгән һәм Нигъмәтулла Мөхәммәтсафа улы Солтанбәков күчерүче буларак аталган[26].

«Татар әдәбияты тарихы»ның 1985 елда басылган икенче томында шагыйрь Колмөхәммәт иҗатына бәйле рәвештә Н.Солтанбәков турында кыскача искәрмә язылган. Анда болай диелгән: «М.И.Әхмәтҗанов 1981 елгы археографик экспедиция вакытында ТАССРның Саба авылында Колмөхәммәтнең егермедән артык шигыре кергән җыентыгын тапты. Ул Н.Солтанбәков тарафыннан 1885–1891 елларда төзелгән»[27]. Марсель Әхмәтҗановның «Шагыйрь һәм фикер иясе Кол Мөхәммәд» мәкаләсендә Нигъмәтулла Солтанбәков Колмөхәммәтнең шигырьләрен күчерүче буларак телгә алынган[28].

Колмөхәммәт әсәрләренең Нигъмәтулла Солтанбәков тарафыннан күчерелгән тагын бер җыентыгын галим Рәфис Әхмәтов Аксубай төбәгендә табып алган. Ул кулъязманың тасвирламасындагы мәгълүмат мондый: «Җыентыкны ша-гыйрьнең оныгы Нигъмәтулла бине Мөхәммәтсафа бине Кол-Мөхәммәд бине Солтанбәк әл-Болгари әл-Ушмави күчереп язган»[29].

---

[25] Ахметзянов М. Рукописи, пережившие века // Советская Татария. – 1982. – 14 марта; Шул ук // Әхмәтҗанов М. Мәгариф, археографик эзләнүләр. – Казан: ТФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-ты, 2009. – Б. 35.

[26] Ахметзянов М. Татарская археография. Отчеты о результатах археографических экспедиций (1972–2010 гг.). Часть 1. – Казань, 2011. – С. 169.

[27] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 2 том: XIX йөз татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1985. – Б. 69.

[28] Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 224–225.

[29] Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары. Сигезенче кисәк. – Казан, 2011. – Б. 118. Шагыйрь Колмөхәммәтнең исемен фәнни хезмәтләрдә һәм мәкаләләрдә Кол-Мөхәммәд һәм Кол Мөхәммәд рәвешләрендә язып киләләр. Ләкин, кагыйдә буларак, берничә компонентлы татар кеше исемнәре кушылып языла. Ономастика галиме, филология фәннәре докторы Гомәр Саттаров хезмәтләрендә алар шулай бирелгән дә. Колмөхәммәт Солтанбәковның да исеме, иҗади псевдоним булмаганга күрә, кушылып язылырга тиешле. Татар теле кагыйдәләрен төгәл үтәве белән үрнәк булган Татарстан китап нәшрияты тарафыннан басылган «Татар әдәбияты тарихы»ның 1985 елгы икенче томында ук (69 биттә) әлеге исем дөрес итеп «Колмөхәммәт» дип басылган иде.

Фәнни хезмәткәр Айдар Гайнетдинов Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан 2013 елда Мамадыш районына оештырылган комплекслы экспедиция вакытында Түбән Ушмы авылында Н.Солтанбәковның бер кульязмасы табылуы турында хәбәр иткән иде, 1902 елга нисбәтле ул җыентыкта Колмөхәммәт әсәрләре, шулай ук «Бәдәвам» һ.б. күчерелгән[30].

Татар әдәбиятының күпгасырлык тарихында бик авыр сырхауларга дучар булган (сукыр, хәрәкәте чикләнгән һ.б.) әдипләрнең бай иҗади мираслары калган кебек, Нигъмәтулла Солтанбәковның да үз куллары белән язган шигъри (тезмә) әсәрләре хәзергәчә сакланган.

Шагыйрь Колмөхәмәт мирасын өйрәнгән Г.Зәйниева Нигъмәтулла Солтанбәков, бабасы кульязмаларын күчерүдән тыш, үзе дә шигъри әсәрләр иҗат иткән дип язган һәм аның шигъри «Шәҗәрә» әсәре белән энесе Шәехзадәгә багышланган мәрсиясе текстларын монографиясендә тикшергән[31]. (Бу әсәрләрнең кульязмасы Солтанбәковлар нәселен дәвам итүчеләрдә саклана).

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Нигъмәтулла Солтанбәковның үзе күчереп кәгазьгә теркәп калдырган сигез кульязма җыентыгы бар. Аларның өчесе 2000 елда Казан шәһәрендә һәм Байлар Сабасында табып алынган, икесе китапханә хезмәткәрләренең 2016 һәм 2019 елларда Мамадыш районына оештырган археографик экспедицияләрендә табылды, өчесе Яр Чаллы каласында яшәүчедән 2019 елда алынды. Кульязма истәлекләрнең саклanышлары, гомумән, уртача диярлек: кайберләре тулы хәлдә булсалар, башкаларының текстлары тулы түгел – башлары яки ахырлары юк. Арада шактый тузган-таушалганнары да бар.

---

«Кеше исемнәре һәм фамилияләре – икенче кисәге ялгызлык исеме булса да, булмаса да кушылып язылалар» дигән кагыйдәнең хәзер дә гамәлдән чыкканы юк (Татар теленең орфография сүзлеге / проф. Ф.Ә.Ганиев редакциясендә. – Казан: «Раннур» нәшр., 2002. – Б. 430).

[30] Гайнетдинов А. Мамадыш районына оештырылган археографик экспедиция нәтиҗәләре // Традиционная культура народов Поволжья: материалы II Всероссийской научно-практической конференции с международным участием (10–12 февр. 2015 г.). – Казань: Ихлас, 2015. – Б. 131.

[31] Зәйниева Г. Кол Мөхәммәднең шигъри иҗаты..., 2006. – Б. 7–18.

Нәтиҗәдә, хәзерге вакытка Нигъмәтулла Солтанбәков каләме белән язылган 12 кульязма истәлек билгеле. Шуларның өчесендә Колмөхәммәт әсәрләре язылган, калган тугызында Н. Солтанбәковның үз әсәрләре теркәлгән. Әлеге ядкярләрнең сигезе Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, өчесе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, берсе әдипнең нәсел дәвамчыларында саклана.

Монда әйтелгәннәр, әлбәттә, Нигъмәтулла мулла иҗатының хәзерге вакытта фәнгә билгеле бер өлеше генә. Аның шигъри җыентыклары, бәлки, башка китапханәләрдә һәм музейларда да бардыр. Шулай ук нәсел дәвамчыларында һәм Мамадыш төбәгендәге төрле авылларда һаман да сакланып килә торганнары, фән өчен әлегә билгесезләре булуы мөмкин. Ә замана кыенлыклары аркасында мәңгелеккә юкка чыкканнары күпме булгандыр – бер Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм.

Мамадыш районының эпиграфик истәлекләренә багышланган, 2015 елда дөнья күргән хезмәтебездә, Нигъмәтулла Солтанбәковның кабер ташы турында мәгълүмат бирелгән урында Татарстан Республикасы Милли китапханәсендәге кульязма шигъри җыентыгы («Иказел-әүляд») турында кыскача язган идек[32]. «Татар археографиясе» сериясендә 2021 елда дөнья күргән «Шигъри ядкярләр» дип аталган китапның кереш мәкаләсендә дә Нигъмәтулла Солтанбәковның Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган кульязма җыентыклары турында язып үтелде. Аның әсәрләре, аерым алганда, әдәбият галимнәре тарафыннан өйрәнелергә лаек дип бәяләнде. Шунда ук бу авторның үз кулы белән язылган җыентыклары турында кыскача мәгълүмат бирелде, кульязмасының фоторәсеме дә урнаштырылды[33].

Нигъмәтулла Солтанбәковның кульязмаларына күз төшергәч тә, аның читенлек белән, уңайсыз хәлдә, бераз калтыраулы кул белән язылганлыгы аңлашыла. Шуңа карамастан, үзенең «хаталы яздым» дигән сүзләре бер дә дөрес түгел дияргә мөмкин. Чөнки

---

[32] Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре..., 2015. – Б. 144.

[33] Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 19–21.

барлык текстларын бергә җыеп караганда да, аның хаталары санаулы гына. Ул бөтен текстларын да диярлек, укучыларга аңлаешлы булсын өчен хәрәкәләр кулланып язган[34]. Шунлыктан, гадәттә, төрлечә укылырга мөмкин булган сүзләрнең автор теләгәнчә укылышын аңлап, хәзерге графикага күчергәндә үзгәртмичә бирергә мөмкин. Өстәвенә, ул гарәп һәм фарсы алынмаларының тәрҗемәләрен, шулай ук кайбер архаик сүзләрнең аңлатмаларын юллар арасында язып барган.

Авторның күбесенчә хәрәкәләр куеп язганлыгына килгәндә, андый махсус билгеләр татар телендәге текстларда XIV–XVI гасырларда иҗат ителгән әсәрләрдә кулланылган. Авторның, авыру халәтенә карамастан, бик тырышып язганлыгы күренә. Ләкин, куллары калтыранганлыктан, кайбер хәрефләре («әлиф», «дәл», «ра», «мим» «уау») бер-берсенә охшабрак киткән урыннары бар. Гомумән, язуы үзенчәлекле, ләкин төшенмәслек түгел. Нигъмәтулла мулланың әүвәлгерәк кулъязмалары (мәсәлән, 1895 елда иҗат ителгән һәм кәгазьгә теркәлгән «Шәҗәрә» тексты) йөгерек һәм шомарак теркәлгән, ә 1909 елга караганнары һәм бигрәк тә гомеренең соңгы елларында – 1927 елда күчергән «Бибитаибә абыстай мәрсиясе» һәм аңа өстәлгән гыйбарәләре аеруча читенлек белән язылган.

Солтанбәковның Милли китапханәдә саклана торган кайбер кулъязмаларының 1909 елда күчерелгән булулары теркәлгән. Иҗат ителгән вакытлары элеккегерәк кайбер әсәрләрен ул, ихтимал, балаларына бирү өчен дип, яңадан күчергәндер[35]. Мәсәлән, хәзер «6674т» шифры белән теркәлгән кулъязма җыентыгын ул 1909 елның 10 апрель көнендә күчереп тәмамлаган, «Иказел-әүляд» исемле шигъри җыентыгын 1909 елның 12 июлендә күчереп төгәлләгән булуын теркәп куйган. Ә «Мәүлид» әсәре кулъязмасын 1909 елның 19 июлендә күчереп бетергәнлеген белдергән. Соңгы икесенең даталарына күрә шуны искәртергә кирәк – автор берничә әсәрен параллель күчереп язган булса кирәк. Чөнки, бер-бер артлы күчергән дип караганда, шак-

[34] Бабасы Колмөхәммәтнең әсәрләрен дә Н.Солтанбәков хәрәкәләр белән күчергән (Зәйниева Г. Кол Мөхәммәднең шигъри иҗаты... – Казан, 2006. – Б. 120–125.

[35] Авторның шигъри юллар арасында язган күпсанлы искәрмәләреннән шулай аңлашыла.

тый күләмле «Мәүлид» кулъязмасын үзе авыру хәлендәге кеше бер атнада күчереп бетерә алмас иде. Һәрхәлдә, Нигъмәтулла Солтанбәковның сакланган хәтле кулъязмаларының күплеге – аның даими язу эше белән мәшгуль булганлыгын ачык раслый. Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире белән чиктән тыш катлаулы язмышка дучар булса да, аңа бирелгән иҗади сәләт әрәмгә китмәгән – ул тырышып язган әсәрләр бер гасырдан күбрәк вакытны узып, хәзерге чор укучыларына килеп ирешкәннәр.

## Әсәрләре

Нигъмәтулла Солтанбәковның «Шәҗәрә» дип исемләнгән шигъри әсәрендә Югары Ушмы авылының игелекле заты – Хәнәфия мирзаның гамәлләре[36], Югары Ушмы һәм Түбән Ушмы авылларындагы имамнар, үз нәселенең тарихы, бабасы Колмөхәммәт Солтанбәк улының тормыш юлы тасвирланган. Соңгысының 1802–1803 еллардан алып Югары Ушмыда имам булып торганлыгы һәм шигъри әсәрләр иҗат иткәнлеге турында язылган. 1830 елда Югары Ушмыдагы мәдрәсәләр янгында харап булганнан соң, бабасы үзенең зур гаиләсе белән туган ягына кайтып киткәнлеген, этисе Мөхәммәтсафаның исә Югары Ушмыда мулла булып калганын һәм аның дәвамчылары турында бәян иткән. Башка туганкардәшләре хакында кыскача мәгълүмат биргән.

Әсәрдә Колмөхәммәт Солтанбәк улының туган якларына кайткач, Кормантау авылында мәдрәсәдә укытуы, күп шәкертләр тәрбияләве, мөфти хәзрәт белән аралашып торуы, мөфтигә багышлап мәдхия язуы, әдип һәм галим Габдерәхим Утыз Имәни белән дә мөгамәлә кылуы турында бәян ителгән. Шулай ук Колмөхәммәт хәзрәтнең китаплар күчереп язу белән шөгыльләнүе, ук-мылтыкка осталыгы, лачын кебек ау кошларын өйрәтеп, Агыйдел буйларында аучылык итүе тасвирланган.

Шигъри шәҗәрә юлларында очраган кеше исемнәренә бәйләп, автор аларның нәсел дәвамчыларын да өстәп язган.

[36] «Шәҗәрә» текстында Хәнәфия мирзаның игелекле эшләренә бәйләп, Г.Зәйниева китабындагы (2006, 8 бит) «башка байлар исә бу эштә ярдәм итәргә теләмәгәннәр» дигән фикер дөрес түгел. Нигъмәтулла Солтанбәков текстында андый сүзләр юк. Ул, киресенчә, авылдагы башка мирзаларның да күп тырышлыклары булган дип язган.

Шәҗәрә тексты теркәлгән җыентыкта «Шаехзадә мәрсиясе» һәм Н.Солтанбәков тарафыннан эшләнгән шәҗәрә сызымнары да бар. Әлеге кыйммәтле истәлек шушы нәсел дәвамчыларында хәзергәчә кадерләп саклаңган.

Сүз уңаеннан искәртик, татар халкы тарихында нәсел шәҗәрәләрен шигырьләп язган үрнәкләр бик сирәк. Мәсәлән, галим Марсель Әхмәтҗанов 1895 елда язылган бер шигъри шәҗәрәне бастырган иде. Ул Күлле Киме авылының (хәзерге Татарстанның Әтнә районында) «Хәйретдин Хәбибулла улы шәҗәрәсе» исеме белән дөнья күрде[37]. Шунысы игътибарга лаек – әлеге шәҗәрәнең авторы (Хәйретдин Хәбибулла улы, 1842–1911) Нигъмәтулла Солтанбәковның замандашы булган һәм аның шигъри шәҗәрә тексты 1895 елның 13 июнендә язып тәмамланган. (Н.Солтанбәков шәҗәрәсе дә шул ук 1895 елда, 12 октябрь көнендә язылып төгәлләнгән).

Замандашыбыз, шагыйрь Әхмәт Рәшит тә үз нәселенең шәҗәрәсен «Минем шәҗәрәм» дип аталган поэмасының «Нәсел агачы» бүлегендә язганлыгы билгеле[38].

***

Солтанбәковның «Шәҗәрә» әсәрен тикшереп, галимә Гөлнара Зәйниева, һичшиксез, зур иҗтиһад күрсәткән. Аның хезмәтендәге кайбер урыннары төзәтмәгә мохтаҗ. Мәсәлән, «Шәҗәрә» текстында Мөхәммәтсафа Колмөхәммәт улы вафатыннан соң аның ике хатыны һәм 14 баласы («тукыз угылы, биш кызы һәм ике мәнкүхәсе») – барлыгы 16 гаилә әгъзасы калган дип язылган. Хатыннары Бәдигыльҗамалдан туган 6 баласы һәм Бибифатыймадан туган 8 баласының исемнәре теркәлгән. Шулардан «Ике угылы сахибе михраб, урынында...», ягъни әтиләре урынына имам булып (михраб ияләре, мәчет түрендә) калганлыгы, юллар арасында «Нигъмәтулла» һәм «Хөҗҗәтулла» дип исемнәре дә теркәлгән. Зәйниева хезмәтендә Мөхәммәтсафа мулланың ике хатыныннан сигезәр (барлыгы 16 баласы) калган итеп, ике

[37] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. II т. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б. 213–219.

[38] Рәшит Ә. Язмыш җилләре: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2006. – Б. 134–140.

улы «Сахиб» һәм «Михраб»[39] исемнәрендә булган дип, ялгыш аңлатылган.

Шулай ук Колмөхәммәт хәзрәтнең кызы Сәрвиҗамалны «Эстәрлетамак каласының куписы алмыш сорап» дигәндәге «купис» (купец, сәүдәгәр) сүзе Г.Зәйниева тарафыннан «күбесе» дип укылып, «бик күпләр сорап килүләренә»[40] бәйле дип тәкъдим ителгән.

«Шәҗәрә» әсәрендә Габдерәхим Утыз Имәнинең биографиясендәге Мерәс авылына бәйлелек мәсьәләсен язганда Г.Зәйниева ялгышрак шәрехләгән урыны бар. «Кол Мөхәммәд аны башкорт дип санаган... Ләкин Нигъмәтулла автор белән килешми»[41] дигән аңлатмасыннан Колмөхәммәт бу очракта нинди әсәрнең авторы булганы турында сүз барганлыгы аңлашылмый. Гомумән, «Шәҗәрә» текстында Колмөхәммәт белән оныгы Нигъмәтулла арасында бернинди полемика чалымнары, шул исәптән, Г.Утыз Имәнинең башкортмы-түгелме икәнлеген ачыклау проблемасы да, бөтенләй юк[42].

Әлеге әсәр текстында очраган Аксыбы исемле авыл Г.Зәйниева хезмәтендә «хәзерге Кукмара районы Байлангар авылы»[43] дип ялгыш күрсәтелгән. Дөресе, Аксыбы (Аксуфи) – шул райондагы Битләнгур авылы.

***

Әдипнең кайбер җыентыклары гомуми исем астында берләштерелгән аерым цикл рәвешендә дияргә мөмкин. Мәсәлән, 23 шигъри тексттан торган җыентыгы «Иказел-әүляд» (Балаларга искәртү) дип исемләнгән. Мөхәммәт пәйгамбәр мәүлиденә багышланганын «Мәүлид» дигән гомуми исем берләштерә. Шулай ук «Кадер кичәсе» турындагы җыентыгы да бар (монысы иң начар сакланганы – ул тузган-таушалган һәм күп битләре җуелган).

---

[39] Зәйниева Г. Кол Мөхәммәднең шигъри иҗаты..., 2006. – Б. 11, 129.
[40] Шунда ук. – Б. 13.
[41] Шунда ук. – Б. 12.
[42] Габдерәхим Утыз Имәнинең Мерәс авылына бәйлелек мәсьәләсе һәм биографиясе турындагы соңгы мәгълүматларны карагыз: Ямаева Ә. Утыз Имәни нәселенең шәҗәрәсе // Безнең мирас. – 2023. – №12. – Б. 32.
[43] Зәйниева Г. Кол Мөхәммәднең шигъри иҗаты..., 2006. – Б. 9.

Нигъмәтулла Солтанбәковның «Мәүлид» әсәре, исеменнән үк аңлашылганча, Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган көненә зур хөрмәт йөзеннән иҗат ителгән. Автор аны язганда төрле чыганакларны: госманлы төрек телендәге «Мөхәммәдия» әсәренең аңлатмасы-шәрхе – «Фәрхер-рух» китабын, шулай ук «Дәлаилел-хәйрат» шәрхе булган «Кара Даут» әсәрен һәм «Раудел-фаикъ» китабын тәрҗемә итеп кулланганын белдергән. Шулай ук «Алты бармак» (авторы – госманлы төрек галиме Мөхәммәт Чокрыкчызадә) әсәрен дә файдаланган. Солтанбәков әсәрнең башында ук әһәмиятен билгеләп:

Мәүлид гыйззәт итәек,
Мәҗалисләр кыйлаек,
Сәдакалар вирәек
Рухычөн Рәсүлуллаһ,

– дип язган. Ул бөек пәйгамбәрне олылау-данлау бәйрәменең татар җирлегендәге торышын болай дип тасвирлаган:

Русия күбе калалар
Фил-җөмлә мәүлид укыйлар.
Һичнәрсә белми салалар,
Гафилләр бары мәүлидтән.

Бу дүртьюллыктагы «калалар» сүзенә ул өстәмә рәвештә «Казан, Эстәрлетамак, Тройски кебиләр» дип искәрмә биргән. Автор шулай ук җыен бәйрәмен бик олылаган хәлдә, мәүлидкә тиешенчә әһәмият бирелмәвен тәнкыйтьләгән.

«Иказел-әүляд» җыентыгын гомуми сыйфатлаганда, аны балаларына үгет-нәсихәтләр һәм тезмә вәгазьләр дип атарга мөмкин. «Иказел-әүляд»ны кызларына багышлавын Н.Солтанбәков кабат-кабат искәрткән. Ул аларга «кызларым», шул ук мәгънәдәге «бәнат», «бәнатым», «бәнатләрем» дип һәм «әүлядым» (балаларым), «әүлядларым» дип тә язган. Әлеге җыентыкның ахырындагы 62б–70а кәгазьләрендә, «Фил-җөмлә мариз хәлемне бәян» дип исемләп, автор үзенең авыру хәленә бәйле катлаулы язмышын тасвирлаган. Анда язганнарына охшаш эчтәлектәге моңзарлары «Шәехзадә мәрсиясе»нең ахырында, шулай ук «Мәүлид» дип исемләнгән китабында да (38а–41а кәгазьләрдә) бар. Алар турыдан-туры кабатлау рәвешендә булмасалар да, эчтәлекләре бик охшаш. Нигъмәтулла мулла үзенең аянычлы һәм гаять читен

хәлләрен җәмәгате Бибитаибә абыстайга багышлаган мәрсиясендә күп тасвир кылган. Аларның кабатланган урыннары булса да, бу китапта мәрсия текстларын кыскартмыйча биргәнлектән, авторның кызганыч моң-зарлары да үзе язган рәвештә урын алды. Никадәрле авыр хәлдә яткан булса да, ул һич кенә дә үз язмышына рәнҗү белдермәгән. Бары тик «Мөбарәкзадә мәрсиясе»ндә генә үзенә багышланган юллар юк.

Автор үзенең гөнаһлары-хаталары өчен тәүбә кылган, язганнарын укучы кешеләрдән догалар өмет итүен даими кабатлаган.

Башка шигъри әсәрләрендә авторның «газиз дустларым», «нәзмым укучы», «кардәш», «диндәш» кебек мөрәҗәгать иткән урыннары да очрый.

Авторның «6674т» шифрлы кулъязмасындагы «Гафу кыйлып бу гасыйны» дип башлана торган күркәм шигъри догасы Һибәтулла Каргалый әсәрләренә аваздаш дияргә мөмкин. Шул ук җыентыгындагы «Кыйла күргел догаңызны» тексты да нәфис һәм әлеге ике шигыре татар мөнәҗәтләрен хәтерләтә.

Гомумән, Нигъмәтулла Солтанбәковның бай һәм күпкырлы иҗаты, һичшиксез, татар әдәбияты тарихын баета. Газиз гомеренең кырык елга якын өлешен урын өстендә яткан килеш, авыр хәлендә язган Нигъмәтулла Солтанбәковның шәхси каһарманлыгы хөрмәтенә аның әсәрләре, һичшиксез, өйрәнелергә тиешле. Аның барлык әсәрләрен дә тәфсилләп тикшереп, бәлки, диссертация дәрәҗәсендә өйрәнүчеләр дә булыр әле. Ихтимал, бабасы Колмөхәммәт иҗаты белән чагыштырып өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерер. Колмөхәммәтнең бер әсәре «Иказ тәрҗемәсе» дип аталганлыгы, ә Нигъмәтулла мулланыкы «Иказел-әүляд» дип исемләнгән булуы ук – иҗади уртаклыкларга ишарә итә.

Бу китапта Нигъмәтулла Солтанбәковның утыз ел эчендә – 1895–1925 еллар арасында иҗат иткән шигъри әсәрләре туплап бирелде. Гомуми исәп белән әйткәндә, барлыгы 1138 шигъри строфасы (дүртьюллыгы) китапка керде.

Солтанбәковның мәрсияләре – иң күләмле әсәрләре (бөтенесе бергә 735 строфа) булганлыктан, аларга тәфсиллерәк тукталу зарур.

## Мәрсияләре

Нигъмәтулла хәзрәтнең безгә билгеле беренче мәрсиясе үзенең бертуган энесе Шәехзадәгә (1853–1894) багышлап 1895 елда язылган. Гомуми күләме ягыннан ул 91 строфадан (дүртьюллыктан) тора. Уфа өязенең Олуг Күл[44] авылында имам булып торган Шәехзадә Мөхәммәтсафа улы гаиләсен, шәкертләрен, йорт-җирләрен калдырып, Шәехгаттар исемле улы белән бергә, мөселманнар өчен изге урыннарның берсе булган Димәшкъкә күчеп киткән. Аның максаты мөһаҗирләргә имамлык итү булган. Мәрсиядә Шәехзадәнең маршруты тасвирланган. Аның ватаннан киткән вакыты әйтелмәгән. Тик, шулай да, Истанбулга көчле зилзиләдән соң өч көн үткәч (димәк, 13 июльдә) барып җиткән дигән мәгълүматка караганда, ерак сәфәргә июнь ае уртасында чыкканлыгы аңлашыла. Тарихтан билгеле булганча, 1894 елның 10 июлендә Мәрмәр диңгезендә көчле җир тетрәгән, Истанбулда һ.б. калаларда 1349 кеше һәлак булган, биналар җимерелгән.

Шәехзадә Искешәһәрдән 60 чакрым үткәч – Кызыл Чишмә дигән урында – 41 яшендә кинәттән вафат булган. Аның җеназасын укыган Эстәрлебашның Әхмәтситдыйк хәлфә дә бер атнадан ваба авыруыннан үлеп киткән. Бу хәлләрне агасы Нигъмәтуллага Шәехзадәнең улы Шәехгаттар Искешәһәрдән язган хатында хәбәр иткән.

Мәрсиядә Шәехзадәнең гаять диндарлыгы, Чистайдагы Мөхәмматзакир ишан мөриде булганлыгы, һәр елны Чистайга – остазы янына килеп йөргәнлеге тасвирланган. Автор ишан хәзрәткә энесе белән икесе бергә барганлыкларын да язган. Нигъмәтулла Солтанбәков мәрхүм энесенең «урынын җәннәттә насыйп ит» дип, ихлас догаларын белдергән. Мәрсиянең ахырында автор үзенең авыр хәлдә ятуын тасвир кылган.

Бу мәрсиядә Шәехзадәнең еракка күчеп китүенең сәбәбе төгәл әйтелмәгән булса да, нияте – мөһаҗир мөселманнарга имам булу диелгән. Халкыбызның мөһаҗирлек тарихыннан билгеле булганча, Россиянең төрле губерналарында яшәгән мөселман татарлар көчләп чукындырудан хәвефләнеп, 1890 нчы елларда Госманлы

[44] Хәзерге Башкортстанның Кырмыскалы районындагы Олыкүл авылы.

империясе җирләренә төркем-төркем күчеп киткәннәр. Андый хәвефкә күпгасырлык золым һәм XIX гасырның II яртысында рус империясенең руслаштыру сәясәте сәбәпче булган. 1877–1878 еллардагы рус-төрек сугышы чорында кискенләшкән эчке сәясәт, мөселманлыкка кайткан «яңа керәшен»нәрне эзәрлекләү, 1891 елда мөселман руханиларына рус телен белүне мәҗбүри итү турындагы фәрман, татар балаларын рус мәктәпләренә бирдертү һ.б. чаралар мөселман динен тоткан халыкның бер өлешен мөһаҗирлеккә этәргән[45]. Татарларның Төркиягә беренче мәртәбә күпләп күченүе 1893 елда булган. Ул елда Россиядән (шул исәптән, Уфа һәм Стәрлетамак якларыннан) өч меңләп төрки-татар солтан җиренә һиҗрәт иткән[46]. 1894 елда да анда күчеп китүчеләр шактый булган. Ул чорда Шәехзадә юл тоткан Димәшкъ шәһәре Госманлы империясе карамагында булган.

***

Н.Солтанбәковның бүтән бер җыентыгында Түбән Ушмы авылының тирән белемле һәм гаять инсафлы-диндар Һадиулла хәзрәткә багышлап язган мәрсиясе сакланган. Кызганыч ки, бу мәрсиянең башы һәм ахыры билгеле түгел. Аның сакланган хәтле текстында (барлыгы 63 строфа) автор Һадиулла хәзрәтнең 1868 елда имамлык мәншүре (указы) алып, үз вазифасында зур тырышлык белән хезмәт куйганлыгы, балалар укытканлыгы турында язган. Аның ягымлы-шәфкатьле, күркәм холыклы, тирән белемле, вәгазь-нәсихәтләре үтемле булганлыгын тасвирлаган. Һадиулла хәзрәт «безнең өчен күзге кебек, караңгылыкны таратучы иде» дип бәяләнгән. Ул күп еллар (40 еллап) гыйлем өйрәтү белән шөгыльләнгән.

Автор Һадиулла хәзрәтнең катлаулы дини мәсьәләләргә җавап таба алуын сокланып язган. Башка муллалар андый түгел дип борчылуын белдергән. Нигъмәтулла мулла үзе дә Һадиулла хәзрәт белән аралашканын, аның белән дини мәҗлесләрдә бергә булганын, гыйлеменнән өлеш – читен мәсьәләләр белән мөрәҗәгать

[45] История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. VI: Формирование татарской нации. XIX – нач. XX в. – Казань, 2013. – С. 587–589.
[46] Кәримуллин Ә. Төркиядә «Казан» журналы // Казан утлары. – 1997. – №2. – Б. 156.

итеп, файдалы җаваплар алганын да әйткән. Инде ул вафат булганнан соң дини мәҗлесләрдә гәзит-мәзит, роман, диләнкеләр турында сүз куерталар дип, тәнкыйтьләп тә алган.

***

Күләмле бер мәрсия Мөбарәкзадә исемле, 20 яшендә вафат булган яшь егеткә багышланган. Бу әсәрнең автор куйган төгәл исеме билгесез. Аны мәрсия дип атавыбыз шартлы гына икәнлеген дә искәртик. Ул татар бәетләренә охшаш, әмма эчтәлеге буенча поэма дип тәгаенләнергә хаклырак.

Текстның башы юк, уртасында да берничә бите сакланмаган. Сакланган хәтле өлеше 247 строфа (дүртьюллык) күләмендә. Мәрсия, бәетләргә хас рәвештә, лирик геройның монологы рәвешендә – Мөбарәкзадә исеменнән хикәяләнгән. Ул үзенең бала вакытында мәдрәсәдә укыган чагыннан башлап, кичергән хәлләрен бәян иткән, әти-әниләреннән бәхиллек сораган һәм гафулар үтенгән.

Мөбарәкзадә 9 яшеннән Түнтәр мәдрәсәсенә укырга барганын, нинди дәресләр укыганын, яшь балага мәдрәсә тормышы, андагы тәртипләргә (дөресе – тәртипсезлекләргә) күрә, бик авыр булганлыгын тасвирлаган. Түнтәрдә укыган еллары һәм остазлары кем икәнлеге әйтелмәсә дә, аның XIX гасыр ахырыннан укый башлаганлыгы аңлашыла, ә ул вакытта мәдрәсә җитәкчесе Ишмөхәммәт Динмөхәммәт улы булган. Мөбарәкзадә мәдрәсәдә өлкәнрәкләрнең һәм хәлфәләрнең яшь шәкертләрне хезмәтче урынына җәберләү-интектерүләрен бәян иткән. Төрле эш-йомыш үтәп йөреп, дәресләрен белми калганлыктан, хәзрәтнең камчысы белән сугып кычкыртуы да әйтелгән[47].

[47] Иске мәдрәсәләрдә хөкем сөргән гадәтләр турында татар әдипләренең әсәрләрендә, күпсанлы истәлекләрдә дә шактый язылган. Монда соңгырак вакытта матбугатта басылган бары тик берсен – педагог, журналист, дәреслекләр авторы һәм тәрҗемәче Харис Фәйзи-Чистапулиның (1871–1933) автобиографиясендәге юлларны искә төшереп үтәбез. Ул үзе укыган Чистай мәдрәсәсен тасвирлап болай дип язган: «Карт шәкертләр... яшь шәкертләргә ата-аналарыннан килгән азыкны ашап торалар, яшь шәкертләрдән самавыр кайнаттырып, аш пешертеп, су ташытып файдаланалар иде. Яшь шәкерт хәлфәнең барлык хезмәтен башкара иде» (Харис Фәйзи. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. – 2024. – №1. – Б. 10).

Җәфалар чиккәннең соңында Мөбарәкзадә үзе дә өлкән шәкерт һәм хәлфә булган. Патша Николай Икенченең 1905 елгы Манифесты игълан ителеп, хөррият җилләре тәэсирендә өлкән шәкертләр һәм хәлфәләр үзара киңәшеп, Түнтәр мәдрәсәсендәге тәртипләрне үзгәртү максатында программа төзегәннәр. Анда шәкертләрнең бертигез булуы, бер-берсен җәберләмәскә, кул күтәрмәскә, үз эшләрен бүтәннәргә кушмаска тиешлеге һ.б. эчке тәртип шартлары, шулай ук укылуы зарур һәм кирәксез фәннәр әйтеп язылган. Программаны төзеп, үтенеч белән дамелла хәзрәткә мөрәҗәгать иткәннәр. Дамелла исә, каны кайнап, укып та тормыйча, гаеплеләргә җәза бирү эмәленә керешкән. Хөсәен исемле хезмәтчесе белән мәдрәсәгә кереп, язган кешеләрне җыеп, сүгеп-яманлап, суктырган. Хезмәтчесе рәхим-шәфкать күрсәтмәгән, әлбәттә. Мөбарәкзадә бу хәлне шәригатькә дә, канунга да каршы гамәл дип, бигрәк тә, мужик кулыннан шәкертләрнең суктырылуына ризасызлыгын белдергән. Хөсәен бу текстта «палач, нәҗес, кабахәт, дуңгыз, ахмак, шакшы» кебек сүзләр белән сыйфатланган. Суктырылган шәкертләр бу хәлдән соң үзләренә монда яхшы караш булмаячагын күзаллап, Бубый мәдрәсәсенә китәргә карар кылганнар. Алар төнлә шәкертләр йоклаганда, елый-елый китеп барганнар.

Бубыйга баргач, фатирга урнашулары, мәдрәсә шәкертләрен барып күргәч гаҗәпкә калулары, хәзрәт белән әңгәмәләре, андагы мәдрәсә тәртипләренең, укыту-белем бирүнең камил һәм яхшы дәрәҗәдә булуы тасвирланган. Бубый мәдрәсәсендә тырышып белем алып имтихан кылынгач, югары дәрәҗәгә ирешеп, шәһадәтнамә алганнар. (Әсәрдә Бубый хәзрәтенең исеме язылмаган булса да, аның Габдулла Нигъмәтуллин-Бубый булганлыгы билгеле).

Мөбарәкзадә Түнтәрдән Бубыйга китүен үз вакытында әти-әнисенә белдермәве һәм рөхсәтләрен алмавы өчен бик күп гафу сүзләре белән үтенгән. Ул үзе белдермәсә дә, этиләренә хәбәрнең ирешкәнен искәрткән. Түнтәрдәге мәсхәрәдән соң хәтта Себергә, Амур буена китәрлек дәрәҗәгә төшкәнлекләрен әйткән. Аның «яныгызга – өйгә кермичә Бубыйга киттем» дигән сүзләреннән төп ватанының Түнтәрдән Бубыйга барышлый юл уңаендагы төбәк икәнлеге аңлашыла. Мөбарәкзадә үзенең Бубыйга китүен белем

алу өчен булып, «фәхеш йортына, трактирга яисә башка бер яман эшкә китмәдем» дип тә өстәгән. «Анда барудан күп файда алсак та, сезнең алда гаепле-гөнаһлы булдык» дип гасабиланган, гафу үтенгән, догаларын өмет иткән. Бу мәрсия ахырынача, гүя, Мөбарәкзадә сүзләре кебек хикәяләнгән.

Мәрсиядә Мөбарәкзаданең үлем сәбәбе ачык итеп әйтелмәгән. Шулай да, «сезе кыйлубән мән әза, мәрызга улдым мөбтәля» (сезне җәфага салып, авыруга дучар булдым) дигән сүзләреннән үлем сәбәбе – эти-әнисенең ризалыгын алмаганлыгы өчен ифрат хәсрәтләнүеннән килеп чыккан дип тоемларга мөмкин. Әтиләренең шелтәсен бик авыр кабул иткәнме, яисә үзе чиктән тыш хәсрәткә төшкәнме – анысы билгесез.

Нигъмәтулла Солтанбәков һәр шигъри текстында исемен автор буларак күрсәткән булса да, Мөбарәкзадәгә багышланган әсәрдә үзен белдермәгән. Хәлбуки, мәрсия авторы нәкъ менә ул булганлыгында һичбер шик юк. Чөнки шигъри төзелеш үзенчәлекләре һәм өслүбе Нигъмәтулла хәзрәт иҗат иткән әсәр икәнлеген ачык белдерә. Әлеге тексттагы тасвирлардан авторының заманы өчен искергән мәдрәсәгә тискәре карашы һәм яңача-тәртипле мәдрәсәгә зур ихтирамы күренеп тора. Яшь килеш якты дөньядан киткән Мөбарәкзадә өчен аның чиксез ачынуы һәм тирәнтен әрнүләре дә ихласлы.

Бубый (Иж-Бубый) мәдрәсәсенең җәдитчә укытуга күчеп, эчке тәртипләре дә үз чорына күрә алдынгы һәм үрнәк буларак, XX гасыр башына зур шөһрәткә ирешкәнлеге билгеле. Бу мәдрәсәнең даны татар дөньясында киң танылып, анда башка мәдрәсәләрдән (кадимчә тәртипләр хөкем сөргән Түнтәрдән һәм хәтта Оренбургтагы җәдиди «Хөсәения»дән дә) төркем-төркем шәкертләр килеп, укуларын дәвам иткәннәр.

Мөбарәкзадә мәрсиясендә тасвирланган хәлләр үз чорындагы татар матбугатында да язылган. Казан шәһәрендә нәшер ителгән «Әл-Ислах» газетасының 1907 елгы 12 ноябрь санының (№6) 8 битендә «Мәдрәсә хәбәрләре» рубрикасында «Габдулла» имзасы белән басылган «Мәдрәсәи Түнтәрия» исемле мәкаләдә болай диелгән: «Үткән кыш шәкертләр, мәхдүмнәрнең иттифакы илән, ислах кирәк, менә әүвәлән безнең китапларны: «Гакаид» укыганнарга бәрабәр «Мөхтәсар» да укытыла барсын, башкасына

дәхи башка китаплар арттырылсын дия сөйләнә башлагач, менә бервакыт бу вакыйганы хәзрәтемез ишетә дә, тиз генә мәдрәсәгә кереп, егерме дүрт шәкертне яткыздырып, аркаларыны үзенең дворник малаеннан суктырта. «Ислахны без үз өстемезгә аламыз» дигән мәхдүмнәремез бу эшләрне барысын шәкертләргә аударып, аның өстенә, «безнең бу тугрыда аслан дәхелебез юк» дип, бөтенләй инкяр итәләр. Инде бу сәнә мәдрәсәгә шәкертләр җыелып җитә башладылар. Ләкин хәлфәләр күренми: кайсы мөгаллим булып киткән, кайсы Истанбулга киткән...»

Газетада язылганга караганда, Түнтәр мәдрәсәсендәге вакыйга 1906–1907 елларның кышында булган. Шул ук «Әл-Ислах» газетасының 1907 елгы 3 декабрь (№9) санының 9 битендә «Татар угылы»имзасы астында чыккан «Түнтәр мәдрәсәсе» хәбәрендә болай язылган: «...мәдрәсәнең матди җәһәте бераз яхшы булса да, эчендә ике тиенлек тәртип вә ислах юктыр. Үткән ел шәкертләр бераз аңлап, ислах таләп кылсалар да, бер яктан фикерсез аталары манигъ булганлыктан, икенче – Ишмидән төрле харикыльгадә җәберләр күреп, рабутнигенә кыйнатырга чаклы йитешкәч, әлбәттә, туктап торырга мәҗбүр улдылар. Аталары фикерле булганнары икенче мәдрәсәгә китеп, калганнары теләртеләмәс килсәләр дә, укулар һаман әүвәлгечә йөзләп кешегә бер хәлфә, һәфтәдә бер-ике эләгеп калган дәрес...». Әлеге язмада да Мөбарәкзадә мәрсиясендә сөйләнгән вакыйга күздә тотылган.

Иж-Бубый мәдрәсәсенең ул вакыттагы җитәкчесе Габдулла Нигъмәтуллин-Бубый әлеге хәлне искә алып болай дип язган: «...1907 елда ун-унбиш шәкерте безгә күчеп килгән өчен бик нык ачуы кабарган Түнтәр Ишминең ләгънәтләре хисапсыз булды»[48]. Бу юллардан аңлашылуынча, Түнтәр шәкертләренең Бубыйга килгән вакыты 1907 елның башында булган.

Мәрсия текстында һәм газета язмаларында Түнтәр шәкертләрен суктырган коралның нәрсә (таякмы, камчымы) булганлыгы төгәл әйтелмәгән. Алдарак хәзрәтнең кулында камчы булуы турында да искәртелгән иде. Шулай да, «Әл-Ислах»тагы «Түнтәрдә» дип исемләнгән бер хәбәрдә театр уены оештырган 5 шәкертне дамел-

[48] Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: тарихи-документаль җыентык / төз.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: «Рухият», 1999. – Б. 42.

ла хәзрәт «өенә чакырып, артыш таяк илә бик нык кыздырган»[49] дигәнгә караганда, Мөбарәкзадәләр вакыйгасында да суктыру коралы таяк булгандыр дип фаразларга мөмкин.

Җәдитчелекне дошман иткән Түнтәр дамелласы Ишмөхәммәт хәзрәтнең шикаятьләренә илдәге империячел сәясәт тә кушылып, 1911 елда Иж-Бубый мәдрәсәсе хөкүмәт тарафыннан ябылган, җитәкчеләре һәм мөгаллимнәре кулга алынып, хөкем ителгән. 1912 елның май аенда булган әлеге сәяси хөкемгә шаһит сыйфатында Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев тә чакырылган. Ул судьяның соравына каршы җавабында мондый сүзләр әйткән: «Безнең яктан аларда шәкертләр бар. Минем үземнең унлап шәкертем китте анда. Шунда барып юлдан чыктылар, йөзләре кара. Шул шәкертләр миңа кергәлиләр. Сөйләштерәм мин аларны. Алар барысы да чеп-чи кызыл. Барысы да кяфер»[50]. Ишмөхәммәт мулланың бу сүзләрендә күздә тотылган «унлап шәкертем китте» дигәне белән Мөбарәкзадә мәрсиясендә хикәяләнгән вакыйга – бер үк икәнлеге аңлашыла.

Түнтәр дамелласының язып бирелгән таләп-теләкләрне укып та тормыйча, гасабиланып киткәнлеген алдарак әйтеп үткән идек. Бубый мәдрәсәсе ябылган чорда Ишмөхәммәт хәзрәтнең үз фикердәшләре дә аның «гасаби авыру» икәнлеген әйткәннәр[51]. Түнтәрнең башка бер имамы – Нәҗип Түнтәри авылдашы Ишмөхәммәт мулла турында болай дип язган: «Мәгълүматы, үткенлеге белән бәрабәр бик холыксыз, ачуланучан, ачуын озакка сузучан, ачу вакытында эш кылучан, кеше гаебен эзләүне, үч алуны яратучан булганга, бер дә кирәксез зарарлы эшләр кылып ташлады... Соңгы елларда ысулы җәдидә һөҗүмен ифрат арттырып, зур фетнәләргә сәбәп булды»[52].

Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрен багышлаган Мөбарәкзадә кемнең улы булганлыгы һәм кайсы төбәк кешесе икәнлеге әйтелмәгән. Бу текст белән иң әүвәл танышканда ук, Мөбарәкзадә – мәрсия авторының туган-кардәшләреннән берсенең улы яисә Нигъмәтулла хәзрәтнең танышларыннан, якын-тирә төбәктәге

[49] «Таләбә». Түнтәрдә // Әл-Ислах. – 1908. – 25 март (№24). – Б. 12.
[50] Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе..., 1999. – Б. 74.
[51] Шунда ук. – Б. 145.
[52] Мөхәммәтнәҗип хәзрәт язмасы // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2003. – №1/2. – Б. 53–54.

берәр имамның улы булгандыр дигән уй туган иде. Н.Солтанбәков тарафыннан 1895 елда язылган нәсел шәҗәрәсен карап-укып чыккач, анда Мөхәммәтсафа мулланың бер улы (Нигъмәтулланың бертуган энесе) Сахибзадә булып, аның бер улы Мөбарәкзадә исемен очраткач, мәсьәлә ачыкланды. Әсәр багышланган егет нәкъ шул булганлыгында шигебез калмады. Өстәвенә, Мөбарәкзадә дигән кеше исеме, гомумән, сирәк очрый. Шәҗәрә сызымында Сахибзадә исеме янында «Буҗи Астында мулла, мәншүрле» дип теркәлгән. Димәк, Сахибзадә Солтанбәков хәзерге Кукмара районындагы Аш-Буҗи авылында имам булып торган. Башка чыганаклардан Сахибзадә Мөхәммәтсафа улының (1863–1930)[53] бу авылда 1887–1930 нчы елларда имам булып торганлыгын белдек[54]. Аш-Буҗи зиратында аның кабере дә билгеле икән. Сахибзадә Солтанбәков авыл халкының хәтеренә бик белемле һәм таләпчән булып кереп калган, аны бик хөрмәт иткәннәр.

Сахибзадә мулла улы Мөбарәкзадә якынча 1890 ел тирәсендә дөньяга килеп, 1910 нчы елларда вафат булгандыр. Аш-Буҗи авылының безне кызыксындырган еллардагы метрика документлары архивларда бөтенләй юклыгыннан һәм булганнарының да тулы түгеллегеннән (битләре җитми һәм ерткаланган), бу мәсьәләне төгәл ачыклый алмадык.

Аш-Буҗи авылы тарихына багышланган альбомда язылганга караганда, ул авылда 1905 елда искергән мәчет бинасы урынына яңаны төзү мәсьәләсе кузгатылган һәм аның Түнтәр авылы имамы Ишмөхәммәт Динмөхәммәт улы акчасына төзеләчәге белдерелгән. Яңа мәчет 1906 елда төзелгән[55]. Менә шундый – Ишмөхәммәт мулла акчасына мәчет төзү кебек мөнәсәбәтләрне

[53] Фәрит Солтанбәков китабындагы шәҗәрә сызымында Сахибзадә мулланың яшәгән еллары 1850–1912 дип ялгыш күрсәтелгән (Солтанбәков Ф. «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...»..., 2001. – Б. 141). Китаптагы шәҗәрәдә Сахибзадә мулланың Мөбарәкзадә исемле улы язылмаган булуы аның күптән дөнья куйганлыгы һәм онытылганлыгы, шулай ук балалары калмаган булуына бәйле. Н.Солтанбәков 1895 елда төзегән шәҗәрәдә Сахибзадәнең дүрт баласы: Мөбарәкзадә, Маһисәрвәр, Мөхибулла, Шәехгаттар исемнәренең өчесе (Маһисәрвәр, Гаттар, Мөхиб) Ф.Солтанбәков китабындагы сызымга туры килә. Тик анда, әйткәнебезчә, Мөбарәкзадә теркәлмәгән һәм Камил (1900–1942) исеме өстәлгән.
[54] Вәлиев Ф. Аш-Буҗи авылы: тарихи-энциклопедик альбом. – Казан, 2017. – Б. 39.
[55] Шунда ук. – Б. 43.

белгән килеш, Нигъмәтулла Солтанбәков Мөбарәкзадә мәрсиясендә үзен автор итеп күрсәтеп, хәсрәтле энесенең гаиләсен тагын да борчуга салырга теләмәгәнлеген төшенергә читен түгел. Һәрхәлдә, без шундый фикердә.

***

Әдипнең иң күләмле (334 дүртьюллык) мәрсиясе – җәмәгате Бибитаибә Могтәмидшаһ кызына багышланган.

1924 елның 26 декабрендә, җомга көнне, Бибитаибә абыстай мәҗлескә барган җирендә, көндезге сәгать өчтә кинәттән вафат булган. Көтелмәгән бу вакыйга Нигъмәтулла хәзрәт өчен бик зур фаҗигагә әйләнгән. Үзен 34 ел буена сабый бала урынына караган, тәрбияләгән, киңәшчесе булып гомер иткән абыстайны кинәт югалту аңа гаять авыр тәэсир ясаган. Мәрсиянең бер өлеше абыстайның мәҗлестәшләре исеменнән тасвирланган. Алар Бибитаибә остабикәнең көтелмәгән үлеменә елашып, балаларга һәм үзләренә дин-иман сабаклары укытканын, вәгазь-нәсихәтләр кылганын, шәфкатьлелеген сөйләп үткәннәр. Аннары «Абыстай кәляме» (сүзләре) дип аталган бүлекчәдә Бибитаибә абыстайның балаларга сабак өйрәтүе тасвирланган.

Бу мәрсиянең яңа бүлекчәсе «Җомга үтеп, шинбә көндәге хәл» дип исемләнгән. Көне буе өйләренә хушлашыр өчен хатын-кызлар килеп елашулары, хәзрәтнең ялгыз калуы турындагы сүзләре – гомумән, андый вакытта була торган гадәттән тыш авыр мохит хикәяләнгән. Хатыннарның «Абыстай иде юаныч, ул китте, хәзрәт кызганыч...», «Сиксән бишкә яше җиткән, дус-ишләре дә ташлап киткән, абыстай да ташлап киткән...» дип елашканнарын ишетептыңлап яткан Нигъмәтулла мулла үзе дә күз яшьләрен койган. Тексттагы «Хатын-кызлар дидеке кәлям» дигән бүлекчәдә абыстай белән хушлашу сүзләре һәм авторның үз халәте:

Алар егълыйлар, мән аглыйм,
Сабырымы кыйла алмыйм.
Такылтыйлар – барын аңлыйм,
Бөркәнеп ятамын даим,

– дип язылган.

Абыстай өчен дога-теләкләр, Аллаһы Тәгаләгә ялварулар һ.б. теркәлгәннән соң «Зәгыйфьнең хатын-кызлара илтимас

кәляме» дип аталган бүлекчәдә автор хатын-кызлардан абыстай өчен бәхиллекләрен үтенгән. «Абыстайда хакыгыз калган булса, әйтегез – үзем бирим, кыямәт көнгә кичектермәгез» дип мөрәҗәгать иткән.

Мәрсиянең чираттагы бүлекчәсе «Якшәнбә көндә булган хәл» дип исемләнгән. Анда мәрхүмәне соңгы юлга озату, дога сүзләре күп язылган. Аннан соң автор абыстайның ничек итеп үзен тәрбия кылганын, инде кем карар дигән хафа-борчуларын бәян иткән. «Аның тик кыйлган тәрбия кыйлалмас миңа бер кемсә...», «Миңа кыйлган тәрбиясе язылмый меңнән берсе...», – ди. Хәзрәт, инде хәзер кем тәрбия кылыр дип, тәмам гаҗизлеккә төшкән. 1891 елның май аенда бу хәлгә тарыганнан соң абыстай үзен даими тәрбияләгәнен искәрткән.

Нигъмәтулла мулла Бибитаибә абыстайның 75 яшендә вафат булуын, аның белән 55 ел гомер кичергәнлекләрен, балалары күп булганын да теркәгән.

Мөшфикам карады, бичара,
Нә кыйлыйм? Китте... Юк чара,

– дип өзгәләнгән җаны-бәгъре көйгән автор.

Бу мәрсиясен Нигъмәтулла Солтанбәков «әүлядларым әүлядлара» (балаларымның балаларына), ягъни оныкларым өчен яздым дигән. Шунда ук ул мәрсиясен «Бу такмакны укымаңыз, дога кыйлыгыз даими» дип тә куйган. «Күземнән агадыр җәшем, сиксән биштә хәзер яшем» дип, елый-елый язганлыгын искәрткән. Шул сәбәпле озак язганлыгын да белдергән:

Озак яздым көндез-көндез,
Болыт булса, күрмидер күз.

Шагыйрьнең менә бу очракта «болыт» дигәне караңгы болытлы көн дип аңлашылса да, әллә ул күз яшьләренең куе болыт кебек өелүен күздә тотканмы дигән сорау да туарга мөмкин. Гомумән, бу мәрсиядә һәм башка әсәрләрендә авторның, гүяки, берничә мәгънәне күзаллагандай тасвирлары тагын да бар.

Бибитаибә мәрсиясенең ахырында Нигъмәтулла Солтанбәков 1927 елның апрелендә төгәлләнгәнлеген теркәгән. Бу дата безгә мәгълүм булган нөсхәнең күчерелгән вакытын белдерә. Чөнки әлеге дәфтәр иң беренче язган нөсхәсе түгел. Чынлыкта, әлеге мәрсия 1925 елда иҗат ителгән.

## Шигърияте

Нигъмәтулла Солтанбәков үз әсәрләрендә төрле иҗади алымнар кулланган: кабатлаулар, рефреннар, чагыштырулар, омонимнар һ.б. Аның төрлечә шигъри үлчәмнәрдә иҗат иткән булуы да игътибарга лаек. Бер үк исем-атама астындагы, бер үк темага багышланган әсәрләрендә дә ул бишәр, җидешәр һәм сигезәр иҗекле шигъри үлчәм-калыпларны кулланган. Шулай ук «Иказел-әүляд»та 11 иҗекле шигыре дә бар. Мәсәлән, аның «Мәүлид», «Иказел-әүляд» әсәрләренең кульязмаларында һәм Мөбарәкзадәгә багышланган мәрсиясендә төрле үлчәмдәге текстлар аралаш урын алган. Н.Солтанбәков бишәр иҗекле кыска үлчәмдә дә күп язган. Борынгы әдәбияттагы татар авторларында бишәр иҗекле шигъри үлчәм булса да, бик сирәк кулланылгандыр. Һәрхәлдә, андый үлчәм белән XVIII гасырда язылган ике мәрсия тексты гына безгә билгеле[56]. Татар халык авыз иҗатында исә бишәр иҗекле шигъри үлчәм «Сак-Сок бәете»нең электән килгән вариантына хас. Татар әдипләре тарафыннан андый үлчәмле шигырь үрнәкләре XX гасыр башында Г.Тукай, Дәрдмәнд һ.б. авторларның әсәрләрендә очрый. Мәсәлән, Тукайның «Балкан көйләре», «Елның дүрт фасылы», «Җир йокысы», Дәрдмәнднең «Кыш көннәре» шигырьләрендә.

Автор язган омонимнардан «кара» сүзен кулланган мисал:

Каләмнән төшмидер кара,
Чалкан ятып язып кара!

Һадиулла мулла мәрсиясендә әлеге хәзрәтне «җимешләрен өзәр өчен башын да бөгәләр, өстенә дә менәләр, ботакларын аералар, таш һәм таяклар аталар» дип, мул җимеш бирә торган агач белән чагыштыруы да кызыклы.

Аерым строфалар эчендә автор эчке рифмалар да кулланган. Мәсәлән, «чәшемнән агызып җәшем» (күземнән агызып яшем) һәм «Шәехзадә мәрсиясе»ндәге:

Булып фирак – мөсафир,
Китеп ерак – мөһаҗир...

---

[56] XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия / төз. М.Әхмәтҗанов. – Казан: «Дом печати» нәшр., 2006. – Б. 229–230; Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар..., 2021. – Б. 127–131.

шулай ук «Иказел-әүляд»тагы:

Вафа кыйлмас, җәфа кыйлыр,
Сафа кыйлмас, хафа кыйлыр.
Бәка кыйлмас, һәба кыйлыр...

һәм шулай ук:

Кыйлып ихсан, сәне инсан,
Вирде ислам, дәхи иман...

– кебек шагыйранә юллары шактый тәэсирле.

Шигъри сәләте көчле булган бу шәхес строфаларның (шигъри дүртьюллыкларның) ахырларында, гадәттә, рәдифләр, рефреннар – кабатланып килгән гыйбарәләр кулланган. Шулай ук строфа ахырлары бер төрле үк хәрефкә тәмамланган рифмадаш сүзләрдән торганын да күрәбез. Шигъри текстларының күбесе «а, а, а, б» рәвешендә рифмалашкан. Шигъри үлчәмнәренең төрлелеге һәм рефреннар җәһәтеннән караганда, Нигъмәтулла Солтанбәковның иҗатында борынгы дәверләрдән үк төрки шигърияттә кулланылган алымнар дәвам иткән. Ягъни, Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Өмми Камал, Мөхәммәт Чәләби һәм башка бихисап авторларның иҗатларына һәм, һичшиксез, XIX гасыр татар әдипләреннән Һибәтулла Каргалый, Гали Чокрый кебек суфыйчылык тарафдарлары булган сүз осталарының әсәрләренә аваздашлык Н.Солтанбәковның «Иказел-әүляд» дип исемләнгән шигъри җыентыгында дүртьюллык строфа ахырлары «өчен» сүзе белән төгәлләнгән шигыре бар. Мондый рәдиф куллану, борынгы дәверләрдән үк килгән. Мәсәлән, ул XII гасырның мәшһүр суфи шагыйре Әхмәт Ясәвинең Мөхәммәт пәйгамбәр вафатына багышланган хикмәтендә үк кулланылган[57]. Андагы дүртенче юллар, мисал өчен мондый рәвештә: «Бабасыдин ятим булып калмак өчен». Шундый ук рәдиф башка авторларда да очрый. Мәсәлән, XV гасыр әдибе Өмми Камал шигырендә, «Бакырган китабы» дип аталган җыентыкта XVII гасыр шагыйре Кол Гобәйдинең бер шигырендә «өчен» рәдифе кулланылган. XVII гасырда яшәп иҗат иткән Мәүла Колый хикмәтләрендә шулай ук «өчен» кулланып язылганы бар.

---

[57] Диване хикмәт гаусел-васыйлин хәзрәти солтанел-гарифин Хуҗа Әхмәд бине Ибраһим бине Мәхмүд бине Ифтихар Ясәви. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1896. – Б. 226–227.

Нигъмәтулла хәзрәт иҗат иткән мәрсияләрдә тасвири уртаклыклар һәм охшашлыклар, әлбәттә, күренә. Җәмәгате Бибитаибә абыстайга багышлап язган мәрсиясе аеруча сагышлы. Бу җәһәттән татар шагыйрьләреннән Габдерәхим Утыз Имәнинең 1798 елда вафат булган хатыны Хәмидәгә, Һибәтулла Каргалыйның 1851 (1852) елда дөньядан киткән хәләл җефете Хаҗивафага атап язган мәрсияләре билгеле. Солтанбәков мәрсиясендәге строфа ахырларында «Мәхрүм калдык, абыстаем», «Ни хәл кыйлыйк, абыстаем» кебек юллардагы «абыстаем» рефрены XIX гасыр татар шагыйре Габделҗәббар Кандалый иҗатын да хәтерләтә.

Бибитаибә абыстайга багышлаган мәрсиясендә автор, «утыз дүрт ел ятам» дип, үзенең 1891 елда майның ахыргы көнендә авыру булып калганын әйткән. Нигъмәтулла хәзрәт үзен «зәгыйфь мулла», «чак күрә күзем» дип, күзлек белән дә күрмәвен һәм яткан килеш каләм тотып тырышса да, куллары калтыраулы булганга, язулары начар килеп чыгуын, аны башкалар танымавын әйтеп язган. «Ятубән сезләр чалканый, язып караңыз язуны...» дип тә искәрткән. Шигъри текстларының күбесендә (ахыргы юлларында) ул үзен Нигъмәтулла дип, шул ук мәгънәдәге «Алла нигъмәте» дип тә еш язган, яки «Әбелфатих» (ягъни, Фатихның этисе) рәвешләрендә, төрлечә белдергән. Иң күп очракта үзен «зәгыйфь» дип атаган. Борынгы төрки-татар әдәбиятыннан килгән гадәт буенча, әсәр авторының үз-үзен кимсетүле «фәкыйрь», «кол», «гөнаһлы» «зәгыйфь» дип атавы белән бергә, Нигъмәтулла Солтанбәков, чынлыкта, үзенең физик кимчелекле – сырхау хәлен дә күздә тоткан. Ул үзенең электәге сәламәт вакытларын искә алып, «Югары Ушмы имамы идем», «гыйззәттә идем, хөрмәттә идем», «хәзрәте идем, хәсрәте чиктем» дип тә сагышланган.

Н.Солтанбәков әсәрләренең кайбер үзенчәлекләре кульязмаларының тасвирламаларына багышланган мәкаләдә әйтелде.

Шагыйрьнең иҗатын гомуми рәвештә бәяләп, «сагыш-моң китабы» дияргә, ә мәрсияләреннән башкасын «шигъри вәгазьнәсихәтләр» дип сыйфатларга мөмкин.

## Әсәрләрнең теле

Солтанбәков әсәрләренең теле мәсьәләсендә кыскача кайбер фикерләрне белдереп үтәбез. Гомумән, ул иҗат иткән шигъри әсәрләрнең теле борынгыдан дәвам итеп килгән төрки-татар шигъриятенә якын телдә язылган дип алдарак әйтеп үткән идек. Ләкин шул ук вакытта, бик гади тасвирлары да бар. Мәсәлән, «Бибитаибә мәрсиясе»ндә:

Илле биш ел гомер сөрдек,
Бала-чагалар үстердек,
Фәкыйрьлек-байлыклар күрдек,
Мәшәкать чикте ул даим.

«Мөбарәкзадә мәрсиясе»нең башлангыч өлеше шактый гади һәм җиңел тел белән язылган.

Шигъри әсәрләрдә госманлы төрек теленә якын *у, баша, безә, сезә, анлара, күрмәз, улды, улмыш, улмаз, шәһәрә (ул, башка, безгә, сезгә, аларга, күрмәс, булды, булмыш, булмас, шәһәргә)* рәвешләрендә язылган сүзләр шактый. Шулай ук, «аныңлә, парахутлә» дип, «илә» (белән) бәйлеген сүзгә ялгап язуны да күп кулланган. Текстларда «иде» ярдәмче фигыле сүзләргә еш кына кушылып язылган, мәсәлән, *хәзрәтде, булмышде (хәзрәт иде, булмыш иде*). «Килде, китте» һ.б. шундый сүзләрне автор «кәлде, кәтде, кәлмеш, кәтмеш» дип теркәгән. Текстларда *мәнга, сәнга, анга, коруг, тулуг, кечек (миңа, сиңа, аңа, коры, тулы, кече)* рәвешләрендәге архаик язылышлар да аз түгел. Болар исә иске татар китаби теле тәэсирендәге XIX гасыр татар әдәбиятына хас гомуми күренешнең чагылышы.

Авторның бу китапта басылган әсәрләрендә ике дистәләп рус һәм Европа сүзләре дә очрый. Алар: *гәзит, губерна, давай, диләнке, забут, крипеч (крепость), купис, мөнафис (манифест), мужик, найумный, парахут, пушты (почта), програм, рабутник, роман, сабранҗа, трахтир* һ.б. Андый сүзләрнең күбесе «Мөбарәкзадә мәрсиясе»ндә язылган.

Солтанбәков иҗат иткән әсәрләрдә «кыйлаем, көтәем, күндерәем, караек, бакаек, язаек» рәвешендә теркәгән сүзләре борынгы әдәби әсәрләрнең язма теле традицияләренә иярүеннән килгән. Борынгы төрки-татар теленең андый үзенчәлекләре Нигъмәтулла Солтанбәков туып-үскән җирлеккә – Мама-

дыш ягы татарлары сөйләменә хас булмаган. Аның бабасы Колмөхәммәт тумышы белән Урал тарафыннан булса да, «караек, язаек» рәвешле сөйләшү, бәлки, гаиләләрендә кулланылгандыр дип фаразласак та, Нигъмәтулла үзе һәм әтисе имам була торып, бөтен авыл халкыннан аермалы сөйләшмәгәннәрдер.

Нигъмәтулла Солтанбәковның бу җыентыктагы әсәрләрендә күп кенә кала һәм авыл исемнәре очрый. Мәсәлән, калалар: Әнкара, Бәгъдад, Бохара, Бурса, Искешәһәр, Истанбул, Казан, Керич, Көләче, Лаеш, Минзәлә, Өфе, Ростов, Самара, Саратау, Сарчин, Тройски, Эстәрлетамак, Чистай, Чиястополь, Шам, Истанбул, авыл исемнәре: Аксуфи, Бакрак, Балтач (Лаеш өязендә), Билэтле, Бубый, Бужи Асты, Җамыш, Җәбраш, Җолгыш, Иске Комазан, Карамалы, Каргалы, Киндер Күле, Кормантау, Мерәс, Морт, Муллакай, Олуг Күл, Өскебаш, Таеш, Тәкермән, Түбән Ушмы, Түнтәр, Үтәк, Эстәрлебаш, Югары Ушмы, Яңа Авыл, Яңа Комазан. Болардан тыш, Авыргазы, Ак Идел, Өршәк кебек елга исемнәре дә бар.

## Текстларның
## китапта бирелеше

Нигъмәтулла Солтанбәковның нәсел дәвамчыларында сакланган һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә тупланган автор кульязмалары тәфсилләп өйрәнелеп, җыентык рәвешендә хәзерге заман укучыларына беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Аерым әсәрләре тулаем, ә кайберләре сайланма рәвештә һәм кыскартылып бирелде.

Беренче итеп Н.Солтанбәков төзегән нәсел шәҗәрәсенең исемлек рәвешендәге варианты һәм шигъри «Шәҗәрә» тексты – үз нәселләренең кыскача тарихын тасвирлаган әсәре тулы килеш тәкъдим ителде. Аннары авторның «Мәүлид» әсәренең аерым өлешләре бирелде. Шуннан соң мәрсияләр: авторның бертуган энесе Шәехзадәгә, Түбән Ушмы авылының имамы Һадиулла хәзрәткә, Мөбарәкзадә исемле кардәшенә һәм җәмәгате – Бибитаибә абыстайга багышлап язган дүрт текст тулаем (кульязмаларында сакланган хәтле күләмнәрендә) урын алды. Алардан соң, авторның үз балаларына үгет-нәсихәт рәвешендә язган шигъри вәгазьләре – «Иказел-әүляд» җыентыгыннан өзекләр,

«Гафу кыйлып бу гасыйны...» һәм «Кыйла күргел догаңызны» дип аталган көйле догалары тәкъдим ителде.

Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре, электән килгән гадәт буенча, көйләп укыла торган текстлар буларак язылган. Шунлыктан, ул аларны үзе дә «әбъят» (бәйтләр) һәм «нәзым» дип атаган, хәтта кимсетебрәк «такмак» дип тә әйткән. Көйләп укылу хасиятләрен күздә тотып, бу җыентыкта хәзерге татар язуында басмага хәзерләнгән текстларның шактый гына дүртьюллыклары ахырларындагы рифмалашкан сүзләрдә соңгы иҗекләренең «ы» һәм «е» хәрефләре «и» хәрефе белән белдерелде. Билгеле булганча, «ы» һәм «е» авазлары гарәп язулы иске текстларда бер үк – «йа» хәрефе белән теркәлгән. Элек-электән көйләп укылган әсәрләрдән «Кыйссаи Йосыф», «Бәдәвам», «Бакырган китабы», «Кисекбаш» һ.б., шулай ук күпсанлы мөнәҗәтләрне укучылар юл ахырларындагы «булды, барды, күрде, килде» кебек рифмадаш сүзләрне «булди, барди, күрди, килди» дип әйтүләре буыннан-буынга күчеп килгән. Элекке мәдрәсә белемле өлкән яшьләрдәге укымышлы бабай һәм әбиләрнең шулай көйләп укыганнарын безгә дә яшь вакытыбызда ишетергә насыйп булган иде. Иске әсәрләрне көйләп укуга бәйле аһәңнәрне хәзерге текстологиядә (аерым алганда, «Татар археографиясе» сериясе басмаларында) чагылдыруның мондый хикмәтен, борынгы татар әдәбияты белән кызыксынучы заман яшьләренең төшенеп җитмәгәнлеген исәпкә алып, искәртергә булдык.

Текстлардагы барлык тыныш билгеләре дә безнең тарафтан куелды. Автор кулъязмаларындагы танылмаган кеше исемнәре һәм сүзләр урынына, шулай ук дөрес укылышлары шиклерәк булган сүзләр янәшәсендә җәяләр эчендә сорау билгесе куелды. Кулъязмалардагы төшеп калган сүзләрнең, кушымчаларның һәм хәрефләрнең безнең тарафтан өстәлгәннәре квадрат җәяләр эчендә бирелде. Шигъри ритмика тулылыгы өчен иҗекләр саны таләп итүгә карап, сүз эченә авазлар өстәгәндә түгәрәк җәяләр эчендә яздык, мәсәлән, *хәз(е)рәт* рәвешендә.

***

Китапны басмага хәзерләү дәвамында күрсәткән ярдәмнәре өчен Кукмара шәһәренең Туеш мәхәлләсе имамы Айрат хәзрәт Шәфигуллинга, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директор урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинга, тарихчылар Эльмира Сәлаховага һәм Альбин Вәлиевкә ихлас рәхмәтләремне юллыйм.

# ШӘҖӘРӘ[1]

*I буын*

*1.* [Мөхәммәт]

*II буын*

*2/1.* Уразкилде

*III буын*

*3/2.* Габдулла

*IV буын*

*4/3.* Мөхәммәтшәриф

*V буын*

*5/4.* Солтанбәк (мәзкүр Солтанбәк Мөхәммәтшәриф угылы башкорт казакларына шөҗагатьле сәргаскәр булып хезмәт кыйлмыш дәю мәсмугмыз. Мәзкүр Солтанбәк әүлядыннан илледән зиядә мулла чыккан дәю, Карамалыда һәркемсәгә мәгълүм. Хосусан, Котлыгзаман угылы Габделкаһир әүлядлары һәрберсе Эстәрлебашында тәгаллем алып, күбесе голәма булмышлар. Халә Эстәрлебашында күп хәлфәләр аның әүлядыннан, Карамалыда...)

*VI буын*

*6/5.* Котлызаман (мәзкүр Котлызаманның башкортлара мәһабәтле кантон пумышәге булып ... Ул гасырда ыстаршина – әмирәтлек кабиленнән ... ыстаршина әүлядлары дәю тәкәллем кыйлынадыр. Аллаһу әгъләм)[2]

---

[1] Шәҗәрә исемлекләре авторның туганнарында саклана торган кулъязманың фотокүчермәсе (19–20 нче битләр) буенча хәзерләнде. Автор кулъязмасында схематик сызым рәвешендәге шәҗәрәне монда исемлек итеп тәкъдим иттек. Исемнәр алдындагы шартлы саннар гомуми тәртип буенча язылды, кыек сызыктан соңгы сан – исемнәре теркәлгән кешеләрнең әтиләренең (соңгырак буыннарда кайберләре әниләренең) тәртип саннарын белдерә. Кулъязмадагы танылмаган сүзләр һәм исемнәр урынына күпнокталар яисә сорау билгесе, шулай ук дөрес укылышлары ышанычлы булмаган исемнәр янәшәсендә җәяләр эчендә сорау билгесе куелды.

[2] Котлызаман Солтанбәков 1795–1830 елларда типтәр командасының башлыгы булган (Сулейманов Р., Мулюков Г., Сафин М. На миркитминской земле. – Уфа, 2007. – С. 14).

*7/5*. Колсөләйман
*8/5*. Каһарман
*9/5*. Колмөхәммәт

*VII буын*

*10/6*. Габде[ннәфыйк]
*11/6*. Габделкаһир
*12/6*. Габдеррахман
*13/6*. Габделгалим
*14/6*. Габделхәлим
*15/6*. Габделвахит
*16/6*. Бикбаһир
*17/7*. Камалетдин
*18/8*. Нәриман
*19/9*. Хөснелҗамал
*20/9*. Мөхәммәтгата
*21/9*. Мөхәммәтсафа (әткәмез хәзрәте)[3]
*22/9*. Әхмәдишаһ
*23/9*. Җиһаншаһ
24/9. Сәрвиҗамал

*VIII буын*

*25/10*. Габдеррәфикъ
*26/11*. Габдулла
*27/11*. Габдрахман
*28/11*. Габде[ррәкыйп]
*29/13*. Габдессаттар
*30/13*. Габделвахит
*31/13*. Габделгаффар
*32/14*. Габделфатих
*33/14*. Әмирхан
*34/14*. Бикбаһир
*35/19*. Бибилатыйфа
*36/19*. Бибифәриха
*37/19*. Могыйнетдин
*38/19*. Зыятдин
*39/20*. Мөхәммәтсәхи

[3] Балалары һәм оныклары аерым теркәлгән.

*40/20*. Мөхәммәтзәки
*41/22*. Бибигафифә
*42/24*. Гобәйдулла
*43/24*. Нигъмәтулла
*44/24*. Кәлимулла
*45/24*. Мәхбүбҗамал
*46/24*. Шәмсеҗамал
*47/24*. Гөлҗамал

*IX буын*

*48/35*. Мөхәммәтхафиз
*49/35*. Мөхәммәтзакир
*50/35*. Бибишәргыя (зәгыйфь мулла Нигъмәтулла мәнкүхәсе, мулла Габдессаттар кызы)
*51/36*. Шаһимәрдан
*52/37*. Ризаэтдин
*53/37*. Гайнелхәят
*54/37*. Гаян
*55/38*. Сахибзадә
*56/38*. Зиннәтулла
*57/38*. Шәехзадә
*58/38*. Бибирокыя
59/39. Мөхәммәтсабир
*60/39*. Мөхәммәттаһир
*61/39*. Мөхәммәтшакир (мөһаҗир мулла Шәехзадә кызы Шәрифелҗамалны мәнкүх)
*62/39*. Мөхәммәтзакир
*63/40*. Имаметдин
*64/40*. Гайнанетдин
*65/40*. Җәлалетдин
*66/40*. Фәттахетдин
*67/41*. Бибирокыя
*68/41*. Шәмсемөхәммәт
*69/41*. Бибинәкыя
*70/41*. Хаҗимөхәммәт
*71/41*. Шәмсемөхәммәт
*72/42*. Әсма
*73/42*. Хөсна

*74/42*. Гарифулла
*75/43*. бер кыз
*76/45*. Гайнелҗамал
*77/45*. Бәдигыльҗамал
*78/46*. Солтанмәхмүт
*79/46*. Шәрифелҗамал
*80/46*. Шәехгаттар (бөрадәрем...)

...тәҗәссес кыйлып яздым. Бәгъзеләренең исемнәрене камил белмәдекем сәбәпле, тарых кыйлдым.

Әүлядларыма тәзкирә булсын дәю, ... истилка ятып яздым мин – зәгыйфь мулла Нигъмәтулла мулла Мөхәммәтсафа угылы Солтанбиков

## МӘЗКҮР СОЛТАНБӘК УГЫЛЫ КОЛМӨХӘММӘТНЕҢ УГЫЛЫ МӨХӘММӘТСАФА ХӘЗРӘТ ӘҮЛЯДЛАРЫ

*VII буын*
*1*. Мөхәммәтсафа[4]
*VIII буын*
*2/1*. Сафиулла
*3/1*. Нигъмәтулла (Югары Ушмы[да мулла иде, мәншүрле])
*4/1*. Маһиҗамал (Таулар(?) мулласында, мәншүрле)
*5/1*. Хөҗҗәтулла (Югары Ушмыда мулла, мәншүрле)
*6/1*. Шәехзадә ([Олуг Күлдә мулла], мәншүрле)
*7/1*. Зөлҗамал (Морт мулласында, мәншүрле)[5]
*8/1*. Гарифулла (Югары Ушмыда мөәзин)
*9/1*. Бибимөнирә (Яңа Авыл, мулла ...)
*10/1*. Мотыйгулла (Таеш[6] авылында мулла, мәншүрле)
*11/1*. Мөхәммәтһади (Кормантауда ...)

[4] Моннан алда бирелгән шәҗәрә исемлегендә 21/9 саны астында теркәлде.
[5] Алабуга районы Морт авылының «Яңа зират»ында Зөлҗамал абыстай Мөхәммәтсафа мулла кызының кабер ташы хәзергәчә сакланган. Ул 85 яшендә, 1934 елның 4 гыйнварында вафат булган. Ташъязмасы Морт авылы мәзине Мөхәммәтзакир Мөхәммәтшакир улы тарафыннан ясалган.
[6] Таеш (Тайыш) – хәзерге Башкортстанның Гафури районындагы авыл.

*12/1*. Бибиситдыйка (Иске Комазанда, гавам)
*13/1*. Бибимәхтүмә (Яңа Комазанда, гавам)
*14/1*. Сахибзадә (Бужи Астында мулла, мәншүрле)
*15/1*. Тәхави[7]

*IX буын*

*16/2*. Бибирокыя
*17/2*. Шәмсемөхәммәт
*18/2*. Бибинәкыя
*19/2*. Хаҗимөхәммәт
*20/2*. Шәмсемөхәммәт
*21/3*. Гыйззеҗамал
*22/3*. Гыйззекамал
*23/3*. Бибифәрхия
*24/3*. Гыйззениса
*25/3*. Бибимәфтуха[8]
*26/3*. Бибивагыйзә
*27/3*. Бибитаифә
*28/3*. Миһриҗамал
29/3. Мөэминә
*30/3*. Бибикәримә
*31/3*. Мөхәммәтфатих[9]
*32/3*. Мөбарәкҗамал
*33/3*. Гөлрух
*34/3*. Фәрхерух
*35/3*. Нурелфуад
*36/4*. Мәгъсүм
*37/4*. Шәмсемөхәммәт
*38/4*. Мирзакасыйм

---

[7] Тулы исеме Тәхаветдин, Югары Ушмыда 1908 елдан мәзин булган.

[8] Мамадыш районының Көмешкүл (Биләтле) авылы зиратында хәзергәчә сакланган бер кабер ташында мондый юллар бар: «...Бу кабердә Мәфтуха – Югары Ушма мулла Нигъмәтулла Солтанбиков кызы, Минһаҗетдин мөәзин җәмәгате... 1914 нче елда 6 нчы майда 42 яшьтә дөньядан үтте». Әлеге ташъязма Морт авылы (хәзерге Алабуга районында) мәзине Мөхәммәтзакир Мөхәммәтшакир улы тарафыннан ясалган. Кабер ташының тулы тексты һәм фоторәсеме басылды: Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2015. – Б. 71.

[9] Югары Ушмыда 1907 елдан имамлык иткән.

*39/4*. Мөхәммәткәшшаф
*40/4*. Котлыәхмәт
*41/4*. Фәтхелкадир
*42/4*. Гөлхөррәмия
*43/5*. Бибимәнзүмә
*44/5*. Габделхак
*45/5*. Лотфулла
*46/6*. Шәрифелҗамал
*47/6*. ?
*48/6*. Шәехгаттар
*49/6*. ?
*50/6*. ...елҗамал
*51/7*. Мөхәммәтзакир
*52/7*. Бибигазизә
*53/7*. ?
*54/7*. Шәмсенур
*55/7*. Фәрхинур
*56/7*. Гафифә
*57/7*. ?
*58/8*. Бибигайшә
*59/8*. Бибифәриха
*60/8*. Бибигайшә
*61/8*. Бибикәшифә
*62/8*. Мөнәүвәршаһ
*63/8*. Сөнгатулла
*64/8*. Зиннәтулла
*65/8*. Бибигазизә
*66/8*. Мөхәммәтзакир
*67/8*. Сәхиулла
*68/8*. Бибигафифә
*69/8*. ...улла
*70/8*. Гайнелхәят
*71/10*. Лотфулла
*72/10*. Хөбберижҗаль
*73/10*. Бибирокыя
*74/10*. Сәхиулла
*75/10*. Гаяс
*76/10*. Өммелхәяр(?)

*77/11*. Бибиситдыйка
*78/12*. Рабига
*79/12*. Әминә
*80/12*. Әюп
*81/12*. ?
*82/12*. ...ифә
*83/13*. Мөхәммәтгали
*84/13*. Җәгъфәр
*85/13*. Бибитаифә
*86/13*. Мәгъмүрә
*87/14*. Мөбарәкзадә
*88/14*. Маһисәрвәр
*89/14*. Мөхибулла
*90/14*. Шәехгаттар
*91/15*. Өммегөлсем

*X* буын[10]

*92/22*. Мөхәммәтшәриф
*93/22*. Бибикәримә
*94/25*. Гобәйдуллаҗан
*95/25*. Бибимәгъсүмә
*96/25*. Мөхәммәтзәки
*97/26*. Бибигамилә(?)
*98/26*. Бибимөкәррәмә
*99/26*. Мирзакасыйм
*100/27*. Бибисара
*101/28*. Таҗимөхәммәт
*102/28*. Котлыәхмәт

Мөмкин кадәре әнсабларымызны тәҗәссес кыйлыб яздым мин – зәгыйфь мулла Нигъмәтулла мулла Мөхәммәтсафа угылы Солтанбиков. 1895, X/12.

Мәрхүм әткәмез Мөхәмәтсафа хәзрәтнең 94 зөррияте китабәт кыйлынды. Вафатлары китабәт кыйлынмады. Мәҗмугы – бер йөз ун зөррияте мәгълүмем. Мәзкүр әүлядлары ... күбе ... дога ... шәрифләре ... өмидем.

[10] Бу буындагылар шәҗәрәдәге IX буын исемнәре астында язылсалар да, алар аерым исемнәргә тоташтырылмаган. Шунлыктан, алдагы буын кешеләренә нисбәт итү төгәл булмаска мөмкин.

# ШӘҖӘРӘ

Югары Ушмы мулла Мөхәммәтсафа
хәзрәтнең әнсаблары шәҗәрәсе
(би-кадәрил-имкян китабәт кыйлынды)[1]

Мирза Бакиев нәселеннән
Мирзалар Ушмысында
Рахманкол мирза әүлядлары
    Гани улмыш бихисап.
Җөмләсеннән аның берсе –
Хәнәфиядер исеме.
Мәсҗидләр һәм мәдрәсәләр
    Бина кыйлмыш ул карап.
Күп карьяләр мулласының
Аның[2] булмыш бинасы,
Һәм күбенең либасы –
    Инфак кыйлмыш бихисап.
Бик күп йирләрә малик[3],
Нәчә забут кәзалик[4].
Булмай һичкем мәшарик –
    Булмыш әмваль бихисап.
Гайре мирзалар улмыш[5],
Һиммәтләре күп кыйлмыш.
«Мирзалар Ушмысы» дәю
    Мөсәммә булмыш хитап.

---

[1] Текст автор туганнарында саклана торган кулъязманың 1–10 нче битләре фотокүчермәсе буенча хәзерләнде.
[2] Кулъязмада бу сүзнең өстенә «Хәнәфиянең» дип искәрмә язылган.
[3] Бу сүзнең өстендә «Хәнәфия» дип язылган.
[4] Бу сүз өстендә «малик» дип искәртелгән.
[5] Бу юлның өстендә «Югары Ушмыда» дип искәртелгән.

Мәзкүр гасырда, әлбәт,
Имамы Мәхмүт хәзрәт[6]
Галим, фазыл булып һиммәт,
        Дәрес алмыш күп тулляб[7].
Аслый ватаны Җолгыш[8] карья,
Каргалыдан[9] кайтканда –
Сәфәрендә Мәхмүт хәзрәт
        Эчмеш әҗәли шәрап.
Мәзкүр Хәнәфия бай
Җәмигы әһле әүлядын[10]
Тәрбия кыйлып, нәфәка виреп,
        Лязим кыйлмыш һәм әсваб[11].
Әһлиясе[12] Рәхимә абыстай
Гарәп, фарсы гыйльменнән
Кызларына тәгаллем виргәч,
        Галимнәр алмыш сорап[13].
Хәнәфия бай тәрбиядә
Үз кызлары тик кыйлып,
Туен кыйлып, әсбап виреп,
        Күндермеш барын карап.
Түбән Ушмы мөдәррисе
Әмирхан хаҗида берсе,
Кыйлып гадати дәрсе
        Һәр фәннән виреп җавап.
Аслы башкорт Әмирхан хаҗи[14]
Түбән Ушмы мөдәррисе,

[6] Бу юл өстендә «Югары Ушмыда» дип язылган.
[7] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «шәкертләр» дип язылган.
[8] *Җолгыш* – хәзерге Кукмара районындагы Иске Йорт (Йолгыш) авылы.
[9] *Каргалы* – хәзерге Оренбург өлкәсендәге Татар Каргалысы авылы күздә тотылган.
[10] Бу юлның өстенә «Мәхмүт хәзрәтнең» дип искәрмә язылган.
[11] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «киемнәр» дип язылган.
[12] Бу сүзнең өстендә «Мәхмүт хәзрәтнең» дип искәртелгән.
[13] Бу сүзнең өстендә «никахлап» диелгән.
[14] Бу шәхес турында язылган: Фәхреддин Р.Асар. Т. 1 / төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 115–116.

Мәхмүт хәзрәт кызы Гайшәне
Никах кыйлмыш ул сорап.
Һиҗрәт кыйлып Ушмыдан[15]
Варып Җәбраш[16] авылына,
Нәчә җыллар тәгаллем вирмеш,
Анда ул мәдфүн тораб[17].
Аслый ватаны Үтәк[18] карья –
Эстәрлетамак өязе.
Рожуг кыйлмыш Әмин – угылы[19],
Белмәдем борын сорап[20].
Түбән Ушмыда бер угыли
Галим, фазыл, илһами[21]
Әхмәтҗан хәзрәттер нами[22],
Анда мәркаде тораб.
Бибизөһрә Хәнәфия кызыны
Никах кыйлып бер угылы,
«Әдрәсче Мөхәмматҗан» дәю мәшһүр,
Казанда кыйлмыш иксаб.
Сөбханкол хәзрәт мәнкүхәсе
Бибифатыйма абыстай

[15] Бу юлның өстендә «Әмирхан хаҗи» дип искәртелгән.
[16] *Җәбраш* – хәзерге Алабуга районындагы Иске Юраш авылы. 1826 елгы архив документында язылганча, Әмирхан Кучкар улы Иске Юраш авылында мулла булып торган.
[17] Бу сүзнең өстендә «анда» сүзенә «Җәбраштa» дип, «мәдфүн» сүзенә «Әмирхан хаҗи» дип искәрмәләр язылган.
[18] *Үтәк* – хәзерге Башкортстанның Гафури районындагы авыл
[19] Бу юл өстендә «Үтәккә» дип искәртелгән.
[20] Бу юл өстендә «исемене, Әхмәтҗан сани» дип язылган.
[21] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «мәшһүр» дип язылган.
[22] Әхмәтҗан Әмирхан улы кабер ташының тулы тексты һәм фоторәсеме басылды: Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре..., 2015. – Б. 99. Вафаты 1812 елда дип язылган әлеге кабер ташы соңрак – XIX гасырның икенче яртысында ясап куелган. Үзендә кем тарафыннан язылганлыгы күрсәтелмәсә дә, сәнгати эшләнеше буенча ул Хөҗҗәтулла Солтанбәков язган ташларга бик якын. Әхмәтҗан Әмирхан улы турында мәгълүмат басылган: Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б. 259; Фәхреддин Р. Асар. Т. 1 ..., 2006. – Б.78-79. Ш.Мәрҗани китабында вафат елы – 1813, Р.Фәхретдиндә – 1814 дип басылган.

Биләтле[23] карья мазарында
Мәдфүн булмышлар тораб.
Фатыйма абыстай Биләтледә,
Камил карчык булганча,
Вәгазь әйтеп, тәгаллем вирмеш
Тәфтиш кыйлып һәм карап.
Гайнелҗамал, Шәрифелҗамал[24],
Бибимәфтуха – кызлары,
Җамалетдин, Гыймадетдин[25]
Камалетдин – бар әхбаб.
Җамалетдин хәз(е)рәте
Бохараның мөдәррисе,

---

[23] *Биләтле* – хәзерге Мамадыш районындагы Көмешкүл авылы.

[24] Бу исемнәр өстендә «Фатыйма абыстай әүляды» диелгән һәм өстәп «Бибигайшә, Хәсән, Хөсәен» исемнәре язылган. Гайнелҗамал исеменнән кәгазь читенә сызыклар белән күрсәтеп аның балалары язылган: 1) Ризаэтдин, 2) Мөхәммәтзариф, 3) Миңлесафа, 4) Гайнелхәят, 5) Шәргыя, 6) Мөбарәкшаһ, 7) Бибигафифәбану, 8) Бибифәрихәбану, 9) Әхмәдишаһ, 10) Гаяс, 11) Хөснелхәят, 12) Шәмселбәдәр.

[25] Бу юлда исеме язылган Җамалетдиннең каберенә – Чиләбе өлкәсендәге Троицк шәһәренең көнбатыш тарафындагы мөселман зиратында 2,5 метрга якын биеклектәге мәһабәт ташъязма урнаштырылган. Аның турында мәгълүмат һәм рәсеме Венер Усмановның «Тарихый ядкәрләр» китабыннан (5-нче китап: мусульманские эпитафии г. Троицк. – Эстәрлетамак, 2013. – Б. 364-367) алынды. Ташъязма истәлекнең алгы ягындагы тексты тәрҗемәсе: «Бу кабер дамелла Җамаледдин бине мулла Сөбханколныкы. Аның төп ватаны һәм туган җире – Казан губернасы Мамадыш өязенең Биләтле авылы. Яшь вакытында заманының мәшһүр галимнәреннән төрле фәннәр өйрәнде. Аннан соң Бохарага барып, зур дәрәҗәле галимнәр хезмәтенә кушылды, гыйлемнәр үзләштерде. Мирза Олугбәк мәдрәсәсендә шәкерт һәм мөдәррис булганнан соң, төп ватанына ата-анасы һәм кардәш-туганнарын күрергә кайтты. Аннары Бохарага юнәлгәч, Троицкидагы дүртенче мәчетнең төзелеп беткән чагына юлыгып, анда яшәүче байларның соравы буенча шул мәчеткә имам булды һәм анда миладиұ 1892 елның 23 гыйнварында, һиҗри 1309 елның 5 рәҗәбендә вафат булганчы дәрес өйрәтте. 75 яшендә иде». Әлеге кабер ташының тулы тексты һәм фоторәсеме басылды: Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре..., 2015. – Б. 168.

Бу юлның өстендә ике исем арасында «Мәхмүд» дип өстәп язылган һәм аның балалары белән оныклары сызыклар белән ялгап кәгазь читендә теркәлгән: Бибифатыйма (аның балалары: Гайнелҗамал, Шәрифелҗамал, Бибимәфтуха, Җамалетдин, Мөхәммәдетдин, ...мөхәммәтмирза, Мөхәммәтшәриф, Билал (аның балалары: Маһруйҗамал, Гайнелкамал), Бибигайшә (аның балалары: Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан, Бибифатыйма, Әхмәтҗан, Мөхәммәтәмин), Бәдигыльҗамал (аның балалары: Хөснижамал, Мөхәммәтгата, Мөхәммәтсафа, Җиһаншаһ(?), Сәрвиҗамал).

Соңра Трускуйда мөдәррис –
        Анда мәркаде тораб.
Мирза Мөхәммәтшәриф ишан
Халә Трускуйда имам,
Фатыйма абыстай әүляды
        Йиде – мәҗмугы хисап.
Угылы[26] Билал хәзрәт
Киндер Күле[27] авылында
Имам булып, карый булып,
        Эчмеш әҗәли шәрап.
Кызы[28] Маһруйҗамалның
Минзәләнең өязе
Тәкермән мулласы Әхмәтҗан
        Никах кыйлмыш һәм сорап.
Аксуфи[29] Әхмәт хәзрәтнең
Могыйнетдин (угылына)
Кызы Гайнелкамалны
        Вирмеш һәм урынын[30] әсбап.

***

Тарих мең дә сигез йөз
Ике йә өченче сәнә
Колмөхәммәт хәзрәтне
        Мирзалар алмыш сорап[31].
Дамелла Мөхәммәтрәхим
Бине Йосыф әл-Ашытый
Мәдрәсәсеннән укып чыкмыш[32],
        Һәр фәннән виреп җавап.

---

[26] Бу сүзнең өстендә «Мәхмүт хәзрәтнең» дип искәртелгән.
[27] *Киндер Күле* – хәзерге Башкортстанның Чакмагыш районындагы авыл булса кирәк.
[28] Бу сүзнең өстендә «Билал хәзрәтнең» дип искәрмә язылган.
[29] *Аксуфи* – хәзерге Кукмара районындагы Битләнгур авылы.
[30] Бу сүзнең өстендә аңлатмасы «илне» дип («мәхәллә» мәгънәсендә) язылган.
[31] Бу юлның астында «Югары Ушмы мәдрәсәсенә» дип искәртелгән.
[32] Бу сүзнең өстендә «Колмөхәммәт хәзрәт» дип язылган.

Мәзкүр Мәхмүт хәзрәтнең
Кызыны кыйлмыш никах[33],
Бәдигыльҗамал абыстай
        Дәюлер исеменә җавап.
Тарих мең дә сигез йөз дә
Уникенче елында
Хәмәлнең унбишендә
        Нәзым кыйлмыш бу китап[34].
Колмөхәммәт хәзрәте
Ибне Солтанбәк аты,
Язмыш мәзкүр әбъяты[35]
        Тәрҗемә кыйлып китап.
Югары Ушмы илендә
Булып даим дәресендә[36],
Булмыш галим гасырында,
        Язмыш даим күп китап.
Тасныйфы: «Тәгърифел-вилдан»,
Кәзалик «Мөһиммес-сыйбиян»,
Вә һәм «Тәгаллемел-ихван»,
        Ошбуныңлә[37]– дүрт китап.
Гаять күп булмыш яран,
Бары мөсәлләм хәйран[38].
Күп имам чыкмыш гаян –
        Мәгъдүд дәгел һәм хисап.
Утызынчы сәнәсе[39]
Югары Ушмы карьясе

[33] Бу сүз өстендә дә «Колмөхәммәт хәзрәт» диелгән.
[34] Бу юлның өстендә «Колмөхәммәт хәзрәте» һәм «Иказ тәрҗемәсе» дип язылган.
[35] Бу сүзнең өстендә «Иказны» дип искәртелгән.
[36] Бу сүзнең өстендә «Колмөхәммәт хәзрәте» дип язылган.
[37] Бу сүзнең өстендә «Иказ илә» дип искәртелгән.
[38] Бу юлның өстендә «Колмөхәммәт» һәм аның кызы «Хөсниҗамал» исемнәре язылып, кәгазь читенә сызыклар белән ялгап Хөсниҗамалның балалары һәм оныклары теркәлгән: Бибилатыйфа (аның балалары: Мөхәммәтхафиз, Мөхәммәтзакир, Бибишәргыя), Бибифәриха (аның улы Шаһимәрдан), Могыйнетдин (аның балалары: Ризаэтдин, (?), Бибигаян, Зыяэтдин (аның балалары: Сахибзадә, Зиннәтулла, Шәехзадә, Бибирокыя).
[39] Бу юлның өстендә «Мең дә сигез йөздә» дип язылган.

Мәдрәсәләр көллесе
        Харикъ улмыш һәм харап.
Һиҗрәт кыйлмыш хәзрәте[40].
Пәракәндә шәкерте.
Куеп гыйззәт-хөрмәте
        Башкорта китмеш карап[41].
Аксуфи карья имамы
Мирза Әхмәди[42] хәзрәте
Хөсниҗамал (кызыны)
        Никах кыйлмыш ул сорап.
Хөсниҗамал абыстай,
Тәмам карчык булганча,
Тәгаллем вireп, вәгазь кыйлып[43],
        Эчмеш әҗәли шәрап.
Әүлядлары[44]: Бибилатыйфа,
Бибифәриха абыстай,
Могыйнетдин, Зыяэтдин –
        Сыйбиянга үгрәтмеш китап.
Әхмәди хәзрәт урынына[45]
Габдессаттар хәзрәте
Имам булып, Бибилатыйфаны
        Никах кыйлмыш һәм сорап.
Лаеш өязе Балтачта
Габдеррахман хәзрәте
Бибифәриха абыстайны[46]
        Никах кыйлмыш ул әхбаб.

---

[40] Бу юл өстендә «Югары Ушмыдан» дип искәртелгән.
[41] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт хәзрәт» дип язылган.
[42] Бу исемнең өстендә «Бикиев» дип искәртелгән.
[43] Бу юлның өстендә «Аксуфида» дип язылган. Әлеге авылның зиратында Нигъмәтулла Солтанбәков тарафыннан ясалган, ике кешегә куелган кабер ташы бар, аның алгы ягында 1843 елда 45 яшендә вафат булган «мулла Әхмәд Габделхаликъ угылы Бикиев», икенче ягында 1885 нче елда 75 яшендә үлгән хатыны «Хөсниҗамал дамелла Колмөхәммәт кызы» исемнәре язылган (Һадиев И., Мәрданов Р. Кукмара төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2014. – Б. 34).
[44] Бу сүзнең өстендә «Хөсниҗамалның» дип искәртелгән.
[45] Бу сүзнең астында «Аксуфида» дип язылган.
[46] *Балтач* – хәзерге Балык Бистәсе районындагы авыл. Әлеге авылның зиратында Нигъмәтулла Солтанбәков тарафыннан ясалган бер кабер ташы бар, анда

Мөхәммәтгата, Әхмәдишаһ
Һәм Җиһаншаһ – угыллары[47],
Сәрвиҗамал (кызы) һәм –
Бары китмеш бергәләп[48].
Урынына калмыш[49] угылы
Мөхәммәтсафадыр намы,
Югары Ушмы имамы[50] –
Анда мәркаде тораб.
Ике угылы[51] сахибе михраб
Урынында, гаҗизләр, җавап.
Берсе мәгъзул һәм харап[52],
Берсе сагъ, мисле гораб[53].
Тукыз угылы, биш кызы[54]
Һәм ике мәнкүхәсе
Калмышлар сагъ барысы[55] –
Уналты, кыйлсаң хисап.
Сафиулла, Нигъмәтулла,
Маһиҗамал, Хөҗҗәтулла,
Шәехзадә, Зөлҗамал –
Бәдигыльҗамал[56] әүляды җавап.
Гарифулла, Бибимөнирә,
Кәзалик Мотыйгулла,
Мөхәммәтһади, Бибиситдыйка
Дәюлер исеменә хитап.

---

«мулла Габдеррахман Габделхаликъ угылының әһлиясе, Аксуфи авылында мулла Әхмәди кызы Бибифәрихәбану, 28 яшендә» дип язылган, елы билгесез (Усманов В., Гариф Н. Балык Бистәсе районы эпиграфикасы. – Казан, 2023. – Б. 7).

[47] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт хәзрәтнең» дип искәртелгән.

[48] Бу сүз өстендә «башкортка» дип язылган.

[49] Бу юл өстендә «Югары Ушмыда» диелгән.

[50] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт» дип язылып, кәгазь читенә сызыклар белән ялгап аның алты баласы теркәлгән: Хөсниҗамал, Мөхәммәтгата, Мөхәммәтсафа, Әхмәдишаһ, Җиһаншаһ, Сәрвиҗамал

[51] Бу сүзнең өстендә «Мөхәммәтсафа хәзрәтнең» дип язылган.

[52] Бу юлның өстендә «Нигъмәтулла» дип искәртелгән.

[53] Бу юл өстендә «Хөҗҗәтулла» диелгән.

[54] Бу юл өстендә «Мөхәммәтсафа хәзрәтнең» дип язылган.

[55] Бу юлның өстенә «вафаты бәгъдендә» (үлгәннән соң) дип искәртелгән.

[56] Бу исем өстендә «әнкәләре» дип һәм астында «Габделмәҗит кызы» дип язылган. Һәр баласының исеме өстендә 1–6 саннары теркәлгән.

Бибимәхтүмә, Сахибзадә,
Кәзалик һәм Тәхави –
Әнкәләре Бибифатыйма[57],
        Сигез әүляды хисап.
Колмөхәммәт хәзрәти
Әһле әүлядилә тәкый[58],
Күрмеш сәфәр михнәти,
        Тапмыш максудын сорап[59].
Эстәрлетамак өязе
Карамалы карьясе,
Анда ирмеш мәүлиде[60],
        Карары күрмеш савап.
Авыргазы буйлары[61]
Һәр илнең имамнары
Сормышлар мөшкелләре –
        Варына вирмеш җавап[62].

***

Казан йирендә тәгаллем алмак
Колмөхәммәт хәзрәте
Сәбәп булмыш бер чабата,
        Көлмешләр анда карап.
Тәклиф илә әхләре[63]
Кыйлмышлар аңа әмре:
«Яса, – диеп – чабата!»
        Шөруг кыйлмыш ул егълап.

[57] Бу исем өстендә «Йосыф кызы» дип язылган һәм һәр баласының исеме өстендә 7–14 саннары теркәлгән.
[58] Бу юлның өстендә «һиҗрәт кыйлган хәлдә» дип язылган.
[59] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт» һәм аның улы «Мөхәммәтсафа» исемнәре язылып, кәгазь читенә сызыклар белән ялгап Мөхәммәтсафаның 14 баласы теркәлгән: Сафиулла, Нигъмәтулла, Маһиҗамал, Хөҗҗәтулла, Шәехзадә, Зөлҗамал, Гарифулла, Бибимөнирә, Мотыйгулла, Мөхәммәтһади, Бибиситдыйка, Бибимәхтүмә, Сахибзадә, Тәхави.
[60] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт хәзрәтнең» дип искәртелгән.
[61] Бу юл өстендә «Су исеме, Өршәккә койганча» дип язылган.
[62] Бу юл өстенә «Колмөхәммәт хәзрәт» дип теркәлгән.
[63] Бу юл өстендә «тәклиф» сүзенең мәгънәсе «көчләп» дип һәм «әхләре» сүзенеке «туганнары» дип искәртелгән.

Алып җүкә пычакы,
Чөшле илә калыбы,
Киндерәсе, җүкәсе –
        Тәмам кыйлмыш ул ясап.
Куеп җүкә тезенә,
Кайтармыш җүкә буена.
Күрелмеш ул әхләренә –
        Көлмешләр бары карап.
Чабатасы үлчәнмеш –
Аршын ярым ул булмыш!
Бары истиһза кыйлмыш –
        Гарьләнмеш анда харап.
Башкорт казакларына
Сәр(и)гаскәр Солтанбәк,
Аның угылы Колмөхәммәт
        Нәчек белсен ул ясап?!
Кыйлып барчасындин гарь[64],
Газем кыйлмыш ул фирар[65],
Казан йиренә кәлеп,
        Тәгаллем улмыш бихисап.

***

«Хөббел-ватан мин әл-иман»
Дәю, кәтмеш башкорта.
Карар кыйлмыш бераз әйям
        Карамалыда карап.
Һиҗрәт кыйлмыш, андин сагъ
Варып карья Кормантаг[66],
Мөдәррис һәм булып шагъ,
        Мәркаден[67] белгел сорап.
Кормантагда Ишнияз
Хәзрәт имеш. Кыш та яз
Дәрес әйтмеш, анда баз
        Эчмеш әҗәле шәрап.

---

[64] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт хәзрәт» диелгән.
[65] Бу юлдагы «газем» сүзе өстендә «касд» (максат) дип, һәм «фирар» сүзе өстендә мәгънәсе – «качмакны» дип теркәлгән.
[66] *Кормантаг* – хәзерге Башкортстанның Гафури районындагы Кормантау авылы.
[67] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «каберен» дип язылган.

Колмөхәммәт хәзрәти
Җеназада булмыш тәкый,
Шәкертләр, гавам шәкый
    Алмышлар аны[68] сорап.
Мәдрәсә тулуг тулляб
Дәрсә ултырмыш сорап.
Укып гыйбарәт-китап,
    Булмышлар канигъ җавап.
Гыйльме нәхү, гыйльме мантыйк
Һәм кәзалик фәраиз,
Гыйльме фикъһ һәм тәфасир,
    Кәзалик гыйльме хисап[69].
Һәм ушандак фарсыйдан
«Гөлстан» һәм «Гөлбостан»
Һәм «Морадел-гарифин»[70]
    Дәрсене алмыш күп тулляб[71].
«Мәснәвий»и Мәүләви,
«Мәсләке»[72] һәм фарсыви –
Дәрес алмыш һәрбери
    Хифыз кыйлып һәм карап.
«Сахих Мөслим», «Сахих Бохарый»
Вә гайре һәм әхадис –
Һәрбереннән укылып,
    Дәрес алмышлар китап.
Күп шәкертләре җыймыш,
Дәрес-тәгаллем вирмеш,
Нәчә мөдәррис чыкмыш
    Һәр фәннән виреп җавап.
Ул тарафның голәма
Анда булмыш таләбә,
Әгъниялар – гораба,
    Тәгаллем алмыш бихисап.

[68] Бу сүз өстендә «Колмөхәммәт хәзрәтне» дип искәртелгән.
[69] Бу юл өстенә «укылмыш» (укылган) дип язылган.
[70] Бу китап исеме өстендә аның авторы «Аллаһыяр Суфиның» дип искәртелгән.
[71] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «шәкертләр» диелгән.
[72] Бу китап (тулы атамасы – «Мәсләкел-мөттәкыйн») исеме өстендә «Суфи Аллаһыярның» дип авторы күрсәтелгән.

Мөфти хәзрәтнең гадәт –
Даим сормыш риваять.
Булса мөшкел гыйбарәт
        Җибәрмеш язып җавап.
Мәдех әбъяты язмыш[73],
Сабранҗага күндермеш –
Имтиханы шул булмыш,
        Тәхсин кыйлмышлар карап.
Булса гәр мөшкел кыйсьмәт
Сабранҗа язмыш, әлбәт.
Тәмам кыйлмыш ул һиммәт,
        Муафыйк кыйлып китап.
Гайре низаг булса әһәм[74]
Фасыйл кыйлмыш[75] аны һәм.
Хилаф кәлеп, ормый дәм,
        Салмыш риваять-китап.
Нәчә рисалә язмыш,
Моназарә күп кыйлмыш,
Бары мөсәлләм булмыш
        Вireп заһир ул җавап.
Утыз Имән Габдеррәхим
Хәзрәт илә һәм аның
Моназарә кыйлышып,
        Рисалә язмыш – китап.

***

Габдеррәхим хәзрәти
Башкорт имеш ул тәкый.
Өршәк[76] буе Мерәс[77] карья
        Мәүлиде ирмеш савап.

[73] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт хәзрәте» дип искәртелгән.
[74] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе «бик кирәкле» дип язылган.
[75] Бу юл өстендә «фасыйл кыйлмыш» сүзтезмәсенең мәгънәсе – аермыш (аерган) дип искәртелгән.
[76] Бу атама өстендә «су исеме» дип искәртелгән.
[77] *Мерәс* – хәзерге Башкортстанның Дәүләкән районындагы авыл.

Әүлядлары рожуг кыйлмыш
Мерәс дигән карьягә,
Сәфәремдә тугры кәлдем,
        Миһман булдым – бу җавап.
Күп сүзләре сораштым,
Китапларыны күрдем.
Гаять вак язмыш, сордым –
        «Бер җилддә нәчә китап?»
«Даим пиядә йөрмеш,
Китапларын йөкләмеш,
Агыр булмасын дәю,
        Язмыш», – дип бирде җавап.

***

Бәдәндә гәрчә касыйр,
Барчасы димеш «тәкъсыйр».
Кәлмешләр булып насыйр,
        Хезмәт кыйлмышлар сорап.
Сайд-шикярә рәгъбәт кыйлып
Һиммәт җәйнең көнендә
Бераз йөреп, рожуг кыйлып,
        Язмыш даим ул китап.
Халә бик күп китаплары
Кәнд каләмилә язмышы:
Нәхү, мантыйк, хашияләр
        Вә гайреләре бихисап.
Төфәң-ука маһир булып,
Ак Иделнең буенда
Күндереп баз – үрдәк-казы
        Шикяр кыйлмыш бихисап.
Мәдрәсәләр, йортлары
Ак Иделнең ярында,
Даим тотмыш сәмәкләре
        Талиблар илә аулап.
Тәгаллем кыйлып кыйгыр, лачын
Күндереп вә хушлара,

Болындай хаузларындин[78]
Чыкарып вирмеш кәлляб[79].
Хосусан, Ак Идел буе
Гаять ирер ул ләтыйф.
Аккош, торна вә гайре вә хуш
Нида кыйла бихисап.
Аның камил һиммәтене
Васфыннан гаҗиз калам.
Бәян-гаян кыйлыр ирсәм,
Азда булыр бер китап!
Галим, фазыл булып һиммәт
Камил булмыш ул гайяр.
Шәкертләр һәм гавамнар
Хәүфә кыйлмыш бихисап[80].
Колмөхәммәт хәзрәте
Эчмеш әҗәл ширбәте,
Кормантагда төрбәте,
Ирҗигый ирешеп хитап.
Мәркаден кыйл мөнәүвәр,
Шәмс-ү-Камәрдин әнвәр,
Мөзәйян һәм мөҗәүһәр,
Сөалә виреп җавап.
Каберен кыйлгыл бостан,
Ирешеп рих-ү-рәйхан.
Йийеп нигъмәте әлван,
Нуш кыйлып ләзиз шәрап.
Һәркем кыйлырса дога –
Кабул кыйл аны, Хода,
Рәхмәтеңә кыйл лика
Йа, Гафур-у, йа, Ваһһаб!
Кабул кыйлып хәсәнати,
Мәхү кыйл сәйеати,

[78] Бу сүзнең өстендә «күлләрдин» дип язылган.
[79] Бу сүз өстендә мәгънәсе – «этләр» диелгән.
[80] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт хәзрәттән» дип искәртелгән.



*«Шәҗәрә» әсәре*

Вирең фәүзе нәҗати[81]
    Вәхшәтләрдән һәм газап.
Дөхүл кыйлып җәннәтә,
Васыйл кыйлгыл гыйззәтә,
Күргәз дидар хәзрәтә[82],
    Кыйлып бәшарәт хитап[83].
Кыйлмышлар соңра имам[84]
Углыны – Әхмәдишаһ нам,

[81] Бу юл өстендә «фәүзе нәҗате» сүзтезмәсенең мәгънәсе – «хәляс» (котылу) дип язылган.
[82] Бу сүзнең өстендә «Колмөхәммәт» дип искәртелгән.
[83] Бу юл өстендә «Сәламүн кауләм мир Раббир Рахим» дип язылган (Коръәннең «Йәсин» сүрәсендәге 58 нче аять, мәгънәсе: «Рәхимле булган Раббыдан сүз белән сәлам»).
[84] Бу сүзнең өстенә «Кормантагда» диелгән.

Гомере һәм улмыш тәмам –
    Эчеп ул әҗәл шәрап.
Мәзкүр Ишнияз хәзрәтенең
Бибисафия (кызыны)
Никах кыйлмыш Әхмәдишаһ[85]
    Хәзрәте алмыш сорап.
Калмыш бары бер кызы[86] –
Гафифә исме-җисме.
Ходаның бөйлә кыйсьме –
    Куелмыш[87] җөмлә әсбап.
Никах кыйлмыш кызыни[88]
Виреп йорт һәм илени,
Үзенә һәм шәрик кыйлып,
    Алмыш Сафиулланы сорап[89].
Ибне Сафа – Сафиулла
Анда[90] һәм булмыш мулла.
Кыйлмыш тәкъдире Алла –
    Ул да һәм мәдфүн тораб[91].
Калып Хаҗимөхәммәт угылый[92]
Кыргызлара вирә тәгълими,
Шимди дәгел мәгълүми –
    Улмыш кем сахиб михраб.
Колмөхәммәт хәзрәтенең
Угылы Мөхәммәтгата
Имам булып Җамышка
    Анда мәркаде тораб.

---

[85] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт» һәм улы «Әхмәдишаһ», аның кызы Бибигафифә исемнәре язылып, кәгазь читенә сызыклар белән ялгап Бибигафифәнең 5 баласы теркәлгән: Бибирокыя, Шәмсемөхәммәт, Бибинәкыя, Хаҗимөхәммәт, Шәмсемөхәммәт.
[86] Бу юлның өстендә «Әхмәдишаһ хәзрәтнең» дип искәртелгән.
[87] Бу сүз өстендә «Бибигафифәгә» дип искәртелгән.
[88] Бу юл өстендә «Әхмәдишаһ» дип язылган.
[89] Бу юл өстендә «әткәсе мулла Мөхәммәтсафадан» дип искәртелгән.
[90] Бу сүзнең өстендә «Кормантагда» диелгән.
[91] Бу юл өстендә «Кормантаг мазарында» дип искәртелгән.
[92] Бу сүзнең өстендә «Сафиулланың» дип язылган.

Аның угылы Мөхәммәтсәхи
Ак Иделнең буенда
Бакрак дигән карьядә[93]
        Карары күрмеш савап.
Мәншүре юк, үзе имам
Кәсеп-кяре һәм аның –
Кыйгыр, лачын һәм базы[94]
        Тәгаллем кыйлыр ул асрап.
Төфәң алып һәр йаумдә,
Күндереп һәм базыны –
Ризык аның даим ләхем
        Алып вә хуш, бихисап.
Шикяр кыйлып сәмәке,
Таба сатып сәмәне.
Тәмам житә чәй-шикәрә,
        Әүлядына һәм әсбап.
Сайд-шикярә рәгъбәт кыйлып
Һәм хозурда гомере,
Җәмегъ кыйлмый әмвале
        Гобрәте кыйлмый хисап.
Кечек угылы Мөхәммәтзәки
Мөхәммәтгата хәзрәтнең
Алып мәншүр, Муллакайда[95]
        Хайван асрый бихисап.
Гайре кәсебе күп улып,
Салабаш[96] һәм салдырып,
Гыйлеме яхшы, үзе яхшы –
        Бәхетен вирмеш Ваһһаб.

---

[93] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт» һәм аның улы «Мөхәммәтгата» исемнәре язылып, кәгазь читенә сызыклар беләν ялгап Мөхәммәтгатаның 2 улы һәм оныклары теркәлгән: Мөхәммәтсәхи (аның балалары: Мөхәммәтсабир, Мөхәммәттаһир, Мөхәммәтшакир, Мөхәммәтзакир, Мөхәммәтзәки (аның уллары: Имаметдин, Гайнанетдин, Җәлалетдин, Фәттахетдин). Бакрак – хәзерге Башкортстанның Гафури районындагы авыл.

[94] Бу сүз өстендә «карчыга» дип язылган.

[95] *Муллакай* – мондый исемдәге авыллар хәзерге Башкортстандагы берничә районда бар.

[96] Бу сүз өстендә аңлатмасы – «мунчала» дип искәртелгән.

Колмөхәммәт хәзрәтенең
Кызы Сәрвиҗамалны
Эстәрлетамак каласының
        Куписы алмыш сорап.
Сәлим угылы Хәлимгә[97]
Никах кыйлмыш ул аны.
Гөруһыннан әгъния
        Булмыш әмваль бихисап.
Гобәйдулла, Нигъмәтулла,
Кәлимулла – угыллары[98],
Мәхбүбҗамал, Шәмсеҗамал,
        Гөлҗамал – белдекем җавап.
Һәрберенең әүлядлари
Белмәдем исемнәри
Нәчек белим анлари –
        Мәгъдүд дәгел һәм хисап.
Белдекем кадәр яздым,
Сезләрә игълам кыйлдым.
Белмәдекеме куйдым,
        Кәрәк ирсә, бел сорап!
Бу мәзкүрләр бәгъзе вафат,
Калмыш әүляды бигаять.
Багышла укып айат
        Әрваха – нәфгы бихисап.
Һичкем калмыйдыр бәка –
Әҗәл тотадыр җака,
Һәркеме кабрә тыка,
        Ахырда кыйлып харап.
Имди монлар кәтделәр,
Безә нәүбәт куйдылар,
Фикер кыйлсаң – гыйбрәтләр
        Үзеңез әүляил-әлбаб.

[97] *Сәлим угылы Хәлим* – мәшһүр Рәмиевләр нәселенең вәкилләре.
[98] Бу юл өстендә «Колмөхәммәт» һәм аның кызы «Сәрвиҗамал» исемнәре язылып, кәгазь читенә сызыклар белән ялгап Сәрвиҗамалның 6 баласы һәм оныклары теркәлгән: Гобәйдулла (аның балалары: Әсма, Хөсна, Гарифулла, Нигъмәтулла, Кәлимулла, Мәхбүбҗамал (аның балалары: Гайнелҗамал, Бәдигыльҗамал, Солтанмәхмүт), Шәмсеҗамал (аның балалары: Шәрифелҗамал, Шәйхегаттар), Гөлҗамал.

Бөйлә белдекем һаман
Сезләрә кыйлдым бәян.
Белгәннәрә ул гаян,
        Яздым белдекем җавап.
Яздым кыйлып тәзкирә,
Иҗмалән бу мәзкүрә.
Багышла, укып сүрә
        Әрваха – ирешер савап.
Яздым бөйлә әбъятым,
Белсен дәю әүлядым,
Кәзалик әкарибләрем –
        Укысалар бу китап.
Назыймы Аллаһ нигъмәти
Язды ошбу әбъяти.
Сездән гозер-хаҗати –
        Дога кыйл! Кыйлма гыйтаб.
Тәмам кыйлдым әбъятым,
Яздым сезә китабым.
Онытмаңыз, бәнатым,
        Дога кыйлың бихисап!
Өмид кыйлам догаңыз,
Зәгыйфе онытмаңыз,
Мәхрүм кыйлып эткәңез,
        Бәгъремне кыйлма кәбаб!

***

Мәхрүм булып җөлүстән,
Кәзалик һәм мәсҗидтән
Һәм ушандак мәҗлестән,
        Ятамән мәгъмүм егълап.
Бишенче җыл истилка
Ятам зәгыйфь, юк лика.
Әбъятым куйдым бәка –
        Дога кыйлыңыз, әхбаб!
Һаман да риҗам – сихәт,
Өмидем өзмим, әлбәт.

Рәхимем кыйлыр шәфкать
        Колына, үзе Ваһһаб.
Ятамән булып гаҗиз,
Зәгыйфьмән, булмыйм фаиз.
Сихәт вирәрсән җаиз,
        Рәхимем, Раббел-әрбаб!
Әкәл-шәрап истилка,
Казаи хаҗат истиһза,
Фирашымда мотлака
        Укып намаз һәм китап.
Гаять ирдем гыйззәттә,
Даим булдым хөрмәттә.
Имди хәсрәт-михнәттә
        Мәгъмүм ятамән егълап.

# [МӘҮЛИД][1]

Сәвеп җөмлә мәхлукый,
Тәгъзыйм кыйла мәүлиди,
Безләр исә мәхрүми
Гафләт илә йоклагач.
Безләр исә гафилмез,
Мәүлид тәгъзыйм кыйлмыймыз,
Нәчек өммәт дәюрмез,
Мәүлидене оныткач?
Җыен йитсә, хөрмәт өй,
Яки җитсә сабантуй,
Бары тайяр, гүя туй,
Мәҗалис тәмам кыйлгач.
Мәүлид булса, юк инфак,
Җыен җитсә, күп кунак,
Буламыз камил мөштак[2],
Мәүлид җитсә, без мохтаҗ.
Җыенда әнваг тогъян,
Мәүлидтә укылмый Коръән,
Дөнья-ахирәтә солтан
Өммәтме без, оныткач?
Җыен – бәйрәме шайтан,
Кыйлына әмваль вәйран,
Күбесе көфер-тогъян,
Шайтана табигъ улгач.
Мәүлид җитсә юк хәер,
Күбесе була фәкыйрь,

[1] «Мәүлид» әсәренең аерым өлешләре Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «2687т» шифры белән саклана торган кулъязма истәлектән кыскартылып, 12а–13а, 18а, 18б, 34б–39б, 40б–41а кәгазьләреннән алынды.
[2] Кулъязмада бу юлның өстенә «җыенда» дигән сүз өстәлгән.

Кая мәүлиде тукыр,
        Хәтта хотур кыйлмагач?
Нәчә көн ашап-эчеп,
Йөри сәкран-сугышып,
Мәүлид йитсә тырышып
        Шәвагыйльдә, хәтта ач.
Җыен йитсә [гәр], күп нас,
Тектерә әнваг либас[3],
Мәүлидә сәдака тапмас,
        Ихласы һич улмагач.
Олуг-кечек барчаси,
Ясый олуг мәҗлеси[4],
Сөрүр ула көллеси
        Шайтан бәйрәме кыйлгач.
Нәдер мәүлид – белмиләр,
Бер пул сәдака бирмиләр,
Зикр-ү-тәсбих димиләр,
        Хәтта салават димәгәч.
Бер китапта күренми –
«Җыен фазыйләт» диелми,
Аслан мөҗтәһид язмый,
        Шайтан пөр, аның булгач.
Җыены тәгъзыйм ихлас,
Мөкиббән барчасы хас[5],
Гүя булганнар хәляс,
        Каһәре фикер кыйлмагач.
Җыенда йөри хозур,
Мәүлиде кыйлмый хотур[6],
Кая гыйззәт[7]? Кыйла хур!
        Һич илтифат кыйлмагач[8].

---

[3] Бу юл өстенә «хөрмәтләп» дип язылган.
[4] Бу сүз өстенә «җыенда» дип искәртелгән.
[5] Бу юл өстенә «җыенда» диелгән.
[6] «Кыйлмый хотур» сүзләре өстенә «хәтерә килтерми» (хәтергә китерми) дигән мәгънәсе язылган.
[7] Бу сүз өстенә «мәүлиде» дигән искәрмә теркәлгән.
[8] Бу сүз өстендә «мәүлидә» диелгән.

Сөрүр[9] кыйлып шайтани,
Тәхкыйрь кыйлып мәүлидни,
Дөнья-ахирәт солтани[10]
Нә дәюр бөйлә булгач?
Дәюрме ул: «Өммәтем»[11],
«Хөрмәтең юк мәүлидем[12],
Кыйламмы шәфагатем[13],
Һичбер тәүкыйр[14] кыйлмагач»?
Бераз фикер кыйлыңыз,
Бөйлә безем фигылемез,
Нәчек өммәт дәюрмез[15],
Мәүлид тәгъзыйм кыйлмагач?
Камил төзи өс-баши[16],
Хәзерли әнваг аши,
Куюбән мөһим эши[17],
Фискъ-у-фәсадта булгач.
Хәтта бер хәтәр күрсә:
«Нәзеремдер[18] җыен йитсә,
Бер тәкә суям, үссә,
Бу хәтәрдән котылгач»[19].
Ата-ана кызганыч,
Кыйлынмыйдыр дога һич[20],
Җыен йитсә куаныч[21],
Газиз бәйрәм дип белгәч.

---

[9] «Сөрүр» сүзе өстенә «шад» дип, мәгънәсе язылган.
[10] Бу юлның өстенә «рәсүлемез галәйһиссәлам» дип искәртелгән.
[11] Бу сүз өстенә «безләре» (безне) дигән искәрмә теркәлгән.
[12] Бу сүз өстенә «дисә» дип өстәлгән.
[13] Бу сүз өстенә «сәнгә» (сиңа) дип искәртелгән.
[14] «Тәүкыйр» сүзенең өстендә мәгънәсе «тәгъзыйм» (олылау, хөрмәтләү) дип теркәлгән.
[15] Бу сүз өстенә «рәсүлә» (пәйгамбәргә) дип искәртелгән.
[16] Бу сүз өстенә «җыенда» дип язылган.
[17] «Мөһим эши» сүзләре өстенә «хаҗат эшне» дип искәртелгән.
[18] Бу сүз өстенә «хәвеф кыйлып» дигән искәрмә өстәлгән.
[19] Бу юлның өстендә «җыен хөрмәтләп» дип искәртелгән.
[20] Бу сүз өстенә «рухлара» (рухларга) дигән искәрмә теркәлгән.
[21] Бу юл өстендә «әрвахны оныта» дип искәртелгән.

Мәүлид йитсә, дия: «Ач,
Әһле гыял ялангач[22]»,
Сукрана дәю: «мохтаҗ» –
        Бөйлә дир мәүлид булгач.
Нәчә көннәр мөкаддәм,
Җыен хөрмәт дәмбәдәм,
Мәүлид йитсә бирер һәм
        Инфак кыйлмый, кызгангач.
Мәүлид йитсә – юк хөрмәт,
Җыен йитсә – күп нигъмәт.
Кичә-көндез дәвамәт
        Әнваг фәсады кыйлгач.
Дәю: «Эшләр каладыр,
Бары кәрәк буладыр», –
Дәю, мәүлид куядыр,
        Мәхәббәте улмагач.
Кыйлып шайтан дәгъвәте,
Улдыкмы Рәсүл өммәте?
Кылыйк фикер гыйбрәте,
        Нәчек без бөйлә булгач.
Сәвекле Рәсүл хәзрәт,
Җәмигыга аңа рәхмәт,
Хода хәбибе, әлбәт,
        Без һәм өммәте мохтаҗ[23].
Хәя кыйлың Рәсүлдин,
Мәхрүм калма мәүлиддин,
Бәнатләрем, нәзымымдин
        Укып, гыйбрәт күзең ач.
Елда бу бер бәйрәм зур,
Китаплардан карап күр,
Ниязлә шәфагать сор,
        Шафигымыз ул булгач.
Әүлядларым, белеңез,
Мондин хисса алыңыз,

---

[22] Бу сүз өстенә «тузган» дип өстәлгән.
[23] Бу сүз өстенә «шәфагатенә» дип язылган.

Мәүлид кыйлмый калмаңыз,
        Бөйлә хөрмәтле булгач.
Зәгыйфь Нигъмәтулла гафил,
Куең бер көн шәвагыйль,
Гыйбрәт алгыл сән камил,
        Мәүлид сәү, өммәт булгач.

***

Русия күбе калалар[24]
Фил-җөмлә мәүлид укыйлар.
Һичнәрсә белми салалар,
        Гафилләр бары мәүлидтән.
Безем карьяләрдән гавам,
Җәмигъ гафил, кәл-һәвам,
Имамнар димиләр дәвам,
        Камил вәгазьлә мәдхеннән.
Нәдер ул мәүлид – белмиләр,
Мәсҗедә җәмегъ улмыйлар,
Фазыйләтен ишетмиләр,
        Мәхрүм калалар мәүлидтән.
Кыйлаек тәгъзыйм мәүлидни,
Тәрк кыйлмаек һич ани,
Кыйлыйк әнваг әгъмалени,
        Мөмкин кадәр тәсаддыктан.
Беләек кадерен мәүлидни,
Җылда бу бер бәйрәм көни,
Кыйлыйк шат Рәсүл рухыни,
        Булдыксә кәрамәтеннән.
Нәчек без дәюрмез өммәт,
Мәүлиде кыйлмый һич хөрмәт,
Нәчек көтәрмез шәфагать,
        Хәтта дими салаваттан.
Беләек кадерене безләр!
Ишеттең дидекем сүзләр?

---

[24] Бу юлның өстендә «Казан, Эстәрлетамак, Тройскуй кебиләр» дигән искәрмә теркәлгән.

Кыйл һәм гыйззәт-хөрмәтләр,
        Олуглардан-кечекләрдән.
Таныйм ди Рәсүл өммәтне,
Белән тик[25] ата-ана әүлядне,
Хөрмәт кыйлганы[26] мәүлидне,
        Мәгълүм безә хәдисеннән.
Тиеш безә ае[27] гыйззәт,
Ля әкаль бер көн кыйлыйк хөрмәт,
Кадер кыйланнардан гыйбрәт
        Алубән, кыйлыйк гыйззәттән.
Ислам йирендә олуг-кечек,
Гафил улмыйлар һәрнәчек,
Йийәр алар нигъмәте чөчек,
        Куәтчә[28] кыйла зыяфәттән.
Бәнатләрем, ишетеңез,
Мәүлидтән мәхрүм калмаңыз,
Вәгазем сезә, белеңез!
        Имәс гайрә кәлямемнән.
Зәгыйфь Нигъмәтулла сән һәм,
Сәнгә бу бик ирер әһәм,
Гафил калып йиймәгел гамь,
        Кыйлың ингам-у-ихсаннан.

***

Без һәм диямез өммәт,
Риҗамыз һәм шәфагать,
Кая безем мәхәббәт[29],
        Мәүлидендә вирми аш?
Сияһ улыб кальбемез,
Аслан фикер кыйлмыймыз,
Мәүлид тәгъзыйм кыйлмыймыз,
        Җаизме безем мәгаш?

---

[25] Бу сүзләр өстенә «бөйлә таныйм» (шулай таныйм) дигән искәрмә теркәлгән.
[26] Бу сүз өстенә «беләмен» дип язылган.
[27] Бу сүз өстендә «утыз көне» дип искәртелгән.
[28] Бу сүз өстендә «кодрәте кадәр» дигән аңлатма язылган.
[29] Бу сүз өстендә «рәсүлә» (пәйгамбәргә) дип искәртелгән.

Кани ихлас гыйбадәт?
Ни юк бездә тилавәт,
Һаман садир шәкавәт,
　　Фикер кыйлаек, кардәш!
Коруг дәгъва сүземез,
Сөннәтләрен кыйлмыймыз,
Нәчек өммәт булдык без,
　　Чыкмый күздән катрә җәш?
Нигъмәтемез кызганып,
Зыяфәт тәрек кыйлып,
Рәсүлемез онытып,
　　Сәдака кыйлмый локмә аш?
Кош-корт белде кадрени,
Тәгъзыйм кыйлды мәүлидни,
Хак хәбибе Рәсүлни,
　　Мәдехлә бөктеләр баш.
Мәүлидене юк тәгъзыйм,
Рухына юк һич тәкрим,
Нәчек өммәтмез сәлим?
　　Кальбемездер каты таш.
Нәчек кыйлалар тәгъзыйм,
Бере-береннән газыйм,
Бераз кыйлам мән нәзым,
　　Кабул кыйлсаңыз, диндәш?
Белмимез мәүлиде һәм
Сәдакамез юк бер дирһәм,
Белсәк бүген бик әһәм,
　　Белә кадерен таг-у-таш.
Хөрмәт кыйл мәүлиде бик,
Рәсүле ул хөрмәт тик,
Шәфагатә кыйлма шик,
　　Заһир ул, гүя, Кояш.
Өмид кыйлсаң шәфагать,
Әмеренә кыйл итагать,
Даим дигел салават,
　　Зыяфәт кыйл, йийдер аш.

Тәмам ае бәйрәмдер,
Әҗер хәддән бирәндер,
Шиксез, тәгъзыйм тиештер,
Беләкадрен таг-у-таш.
Хосусан, сез, кызларым,
Укыңыз нәзымнарым,
Тәнбиһем, вәгазьләрем,
Күрең күз өстендә каш!
Гаҗиз, зәгыйфь Нигъмәтуллаһ,
Сән дә инфак кыйл Лилләһ,
Тәгъзыйме Рәсүлуллаһ,
«Шәфагать» – дәю, чыкар җәш.

***

Гафил калма мәүлидтән,
Мәхрүм калма әҗердән,
Алың хаз бу нәзымнән,
Кальбең улмаса кара таш.
Нәзым кыйлып китабәт,
Риҗа кыйлдым шәфагать,
Мәлямәт кыйлма хиҗаләт,
Гоюбләрем кыйлып фаш.
Язылды «Фәрхер-рух»тан[30],
Бәгъзе «Кара Даут»тан[31],
Кәзалик «Раудел-фаикъ»тан,
Тәрҗемә кыйлдым, кардәш.
Сезләрә дип, кызларым,
Китабәт кыйлдым нәзым,
Бераз мәүлид вәгазем
Белдекемчә кыйлдым фаш.
Ятып истилка дәвамәт,
Гаять мөшкел китабәт,
Кыйлсалар һәм мәлямәт,
Ятарсән һәм бөгеп баш.

[30] «Фәрхер-рух» атамасы өстендә «Мөхәммәдия шәрхе» дип искәртелгән.
[31] «Кара Даут» атамасы өстендә «Дәлаилел-хәйрат шәрхе» дигән искәрмә язылган.

Гоюбләрем гафу кыйл,
Мәлямәттән хәляс кыйл,
Рәхим кыйлып, дога кыйл,
    Бу зәгыйфькә сез, кардәш?!
Зәгыйфь кальбе мөнкәсир,
Җәмигъ хәлдә ул хәсир,
Нәчә ел ятмак гасир[32],
    Мәгъзүр, мәгъмүм, түгеп җәш.
Кыйлың зәгыйфькә шәфкать,
Риҗам – догаңыз, әлбәт,
Гозер кыйлып китабәт,
    Укысаңыз сез, кардәш.
Ятам мәхрүм сезләрдин,
Риза булың безләрдин,
Агып җәшем күзләрдин,
    Сезләрә ул бары фаш.
Белеңез мәнем бәнат[33],
Сезә хас яздым әбъят,
Рухыма укың[34] айат,
    Каберемдә булыр юлдаш.
Куйдым сезә тәзкирә,
Багышла укып сүрә,
Мәдфүнмән ялгыз күрә,
    Куеп әүляд һәм кардәш.
Нәзым кыйлдым китабәт,
Тәмам кыйлдым мән, әлбәт.
Кыйлмаңызлар мәлямәт,
    Бу зәгыйфе сез – кардәш!
Мәшәкъкать илә яздым,
Кызларым, сезә нәзым,
Тәнбиһем вә вәгазем,
    Әхвәлем сезләрә фаш.
Күрмидер һич сул күзем,
Калтырый һәм әлләрем,

---

[32] «Гасир» сүзенең өстендә «агыр» (авыр, читен) дигән мәгънәсе теркәлгән.
[33] Бу сүз өстенә «кызларым» дип, мәгънәсе язылган.
[34] Бу сүз өстенә «багышлап» дип өстәлгән.

Бозыла хөруфләрем,
Укучыга бары фаш.
Миладия тарих мең дә
Тукыз йөз тукыз елда,
Июльнең унтукызында
Нәкыль кыйлдым[35] галәл-фираш.
Һиҗрия мең дә өч йөз дә
Егерме йиде елында,
Маһы рәҗәп ундүртендә,
Кызларыма мәнкуль фаш.
Каләмдин төшми кара,
Истилка язып кара!
Яздым мән форсат ара,
Эчем пошып, чыкып җәш.
Егерме җылым тәмам,
Ятамын зәгыйфь дәвам,
Гозер, ниязым, риҗам –
Догаңызы дин кардәш.

***

Китап карадым,
Бәгъзе сүз яздым,
Кылубән нәзым,
Сезә, кызларым.
Кыйсса күрдем күп,
Каюсы бик хуп,
Бәгъзе бик мәргуб,
Тәрҗемә кыйлдым.
Нәзар кыйл – китап,
Күрең – бихисап,
Торма аптырап,
Бәгъзене яздым.
Укып сүзләрем,
Минем кызларым,

[35] «Нәкыль кыйлдым» сүзтезмәсенең өстендә «күчердем» дигән мәгънәсе теркәлгән.



*«Мәүлид» китабыннан*

Һәп вәгазьләрем
        Сезләрә куйдым.
Яздым тәзкирә,
Әткәндән сезә,
Күзеңез күрә –
        Укың, кызларым!
Максуд нәзымнән
Һәм вәгаземнән,
Һәм барыңыздан
        Дога өмидем.
Укубән сезләр,
Дога кыйлыңлар,

Һич онытмаңлар,
　　Дәюбән яздым.
Куюбән җиһан,
Китсәм[36] нагяһән,
Сезләрә гаян[37]
　　Сүзләрем куйдым.
Нәчек мәнем хәл,
Кыйлмадым әгъмаль,
Әмвалем вәбал[38]
　　Туле әмәлем.
Өмидем – рәхмәт[39]
Кыйлыр дип, әлбәт,
Вирер дип җәннәт[40]
　　Рәхим, Рахманым.
Калыр сүзләрем,
Кыйлынган нәзмым
Сезә вәгазем
　　Әүрака яздым.
Кыйлып китабәт,
Бераз хикәят,
Укыңыз әбъят,
　　Мәнем кызларым.
Мәүлиде яздым,
Кыйлубән нәзым,
Шиксез, вәгазем,
　　Тәнбиһ һәм кыйлдым.
Мәүлиде кадре,
Чиксездер әҗре,
Җәннәттә сәйре[41],
　　Хөрмәтә Рәсүлем.

[36] Бу сүз өстенә «дөньядан» дип өстәлгән.
[37] «Гаян» сүзенең өстендә «заһир» (ачык, билгеле) дип искәртелгән.
[38] Бу юл өстенә «җәмыг кыйлган» (җыйган) дигән искәрмә язылган.
[39] Бу сүз өстендә «Ходаның» дип искәртелгән.
[40] Бу сүз өстенә «риҗам» (өметем, теләгем) дигән искәрмә теркәлгән.
[41] Бу сүз өстендә «булыр» дип искәртелгән. *Сәйре* – йөрүе, гизүе.

Кыйлаек сөннәт[42],
Дәюп салават,
Кыйлыр шәфагать[43],
　　Дәеп: «Өммәтем!»
Рәсүле хуплап
Мәүлиде зурлап,
Дияек егълап:
　　«Дигел – Өммәтем!»
Бу газыйм дәүләт,
Кадрен бел, әлбәт,
Мәүлидтә нигъмәт,
　　Бәшәр, әхләрем.
Тойыйк шәвагыйль[44],
Калмаек гафил,
Булаек гамил,
　　Мөэмин кардәшем.
Кыйлмаек нифак,
Кыйлаек инфакъ,
Рухына мотлак,
　　Рәсүл әкрәмем.
Рәсүл мәүлиде,
Бераз язылды,
Нәзым кыйлынды
　　Вәгазь-тәнбиһем.
Мәнем сез бәнат,
Укыңыз әбъят,
Мәүлиде морагать[45],
　　Сөек кызларым.
Мәүлидә гыйззәт,
Гаять күп хикмәт,
Шөбһәсез шәфкать
　　Безә, кызларым.

---

[42] Бу сүз өстенә «рәсүлнең» дигән искәрмә теркәлгән.
[43] Бу сүз өстенә «безләрә» (безгә) дигән искәрмә язылган.
[44] Бу сүз өстенә «бер көн» дигән искәрмә теркәлгән.
[45] Бу сүз өстенә «кыйлмак» дип өстәлгән.

Халә сез сихәт,
Кадерен бел, әлбәт.
Гыйззәтле өммәт
Кыйлды Сөбханым.
Мәндән ал гыйбрәт –
Нәчә ел сихәт
Китүбән, әлбәт
Ятам фирашым.
Ирдем мән имам,
Каумемә дәвам,
Диердем кәлям,
Кыйлып вәгазем.
Олуглар-кечек
Күрделәр нәчек,
Дидем һәрнәчек
Дыңлап кәлямем.

Кабул кыйлдылар,
Мотыйг булдылар[46],
Хөрмәт кыйлдылар,
Дәеп: «Хәзрәтем!»
Дәюбән: «Хәзрәт!»
Кыйлдылар гыйззәт,
Шөбһәсез, әлбәт,
Кыйлып кадерем.
Риза кыйлдылар,
Хөрмәттә анлар,
Нәчә җыл монлар,
Шөбһәсез, каумем.
Кыйлдылар миһман,
Инфак һәм ихсан[47],
Ярлыка Сөбхан,
Рәхим, Рахманым!

[46] Бу юлның өстендә «каумем» (халкым) дип искәртелгән.
[47] Бу юлның өстендә «кыйлдылар» дип өстәлгән.

Күрдекем гыйззәт,
Мөшкел китабәт,
Раббым, кыйл рәхмәт!
　　Гафуың деләрәм.
Кыйламән дога:
«Гафу кыйл, Хода
Барын[48] ярлыка?!»
　　Бу – мөнаҗатем.
Кадрем иде зур,
Күп кыйлдым хозур.
Имди ятам хур –
　　Бу халә төштем.
Ирдем мәсҗидтә[49],
Булдым мәҗлестә...
Халә хәсрәттә,
　　Мәгъмүми булдым.
Һәр көн зыяфәт[50],
Йөрдем дәвамәт,
Йийеп күп нигъмәт,
　　Шөкер кыйлмадым.
Кулым тоттылар,
Кабул кыйлдылар...
Имди куйдылар,
　　Ятам ялгызым.
Сихәтем кәтте,
Мәнсәбем бетте,
Шатлыкым үтте,
　　Мәгъзул һәм булдым.
Каумемә мәгъкуль
Идем мән мәкъбүл...
Имди мән мәгъзул,
　　Ятамән мәгъмүм.
Һичберен белмим,
Бересен күрмим.

[48] Бу сүз өстенә «каумеме» дигән искәрмә теркәлгән.
[49] Бу сүз өстенә «сихәттә» (сәламәт вакытта) дигән искәрмә теркәлгән.
[50] Бу сүз өстенә «йөрдем» дип өстәлгән.

Раббымнан телим
	Сихәт булмакым.
Яздым әбъятым,
Бу мөнаҗатым,
Виргел хаҗәтем,
	Казый әл-хаҗатем!
Назыйм сахибе,
Әбел-Фатихы,
Югары Ушмы
	Имамы идем[51].
Тәмам әбъятым,
Кыйлдым, бәнатым,
Гозер-хаҗатем,
	Дога өмидем.
Тарихы мең дә
Һәм тукыз йөз дә
Тукызынчы елда
	Мәнкуль әбъятым.
Июль унтукызынчы,
Якшәнбә киче,
Зәгыйфь кятибче
	Мәгълүмем куйдым.
Тарих һиҗрия
Һәм мең өч йөз дә
Егерме йидедә
	Сәнәдә күчердем.
Маһы рәҗәптә
Һәм ундүртендә,
Якшәнбә көндә
	Тәмам кыйлмакым.

---

[51] Бу сүз өстендә «сихәтемдә» (сәламәт чагымда) дип искәртелгән.

# [ШӘЕХЗАДӘ МӘРСИЯСЕ]

Мөһаҗир мулла Шәехзадә
мулла Мөхәммәтсафа угылы Солтанбәк хакында[1]

Мөхәммәтсафа хәзрәтенең
Шәехзадә һәм угылы
Өфе өязе Олуг Күлдә
 Имам иде ул әхбаб.
Мәшһүр булып ул тарафта,
Мәдрәсә бина кыйлып,
Вәгазь әйтеп, тәгаллем виреп,
 Бераз җыймыш ул тулляб.
Тарих мең дә сигез йөз
Туксан дүртенче сәнә[2]
Һиҗрәт кыйлып, Шама[3] дип,
 Барыны кәтде ташлап.
Илени һәм өени,
Ике мәдрәсә шәкертени –
Куеп китмеш барыни.
 Озатмыш бары егълап.
Мәгъмүр иде бостани,
Әнваг тулуг әзһарни,
Гайре мәтаг-әмвальни –
 Барыны кәтде ташлап.
Әүлядларилә мәган
Кәлде сәфәрендә фәрхан.
Бәхилләшеп, күрешеп,
 Барымыз калдык егълап.

---

[1] Текст автор туганнарында саклана торган кульъязманың 11–17 нче битләре фотокүчермәсе буенча хәзерләнде.
[2] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «елда» дип язылган.
[3] Бу сүзнең өстендә «Шам шәрифә» (Димәшкъкә) дип искәртелгән.

Парахутлә Казандин
Төшмеш анлар Самара[4],
Саратавы[5] һәм кичеп
        Сарчингә ирешкән түләп[6].
Сарчиннан Көләче[7] үтеп
Һәм Растуфа[8] ирешеп,
Мән зәгыйфькә мәктүб язмыш –
        Әхвәлен[9] белдек карап.
Һәм Керичә ирешеп,
Азов диңезе кичеп,
Чиястопольдә[10] бер атна
        Тормыш вапуры[11] карап.
Фартунадан[12] сәламәт
Бәхре Сияһы[13] кичеп,
Зилзиләдән[14] өч көн соң
        Исламбула кермеш әхбаб.
Бик күп йортлар ватылып,
Нәчә манара екылып,
Шул сәгать һәм ут чыкып
        Күп адәм булмыш харап.
Бераз әйям тәфәррежлә
Шәһре тамаша кыйлып,
Гаҗәепләре күреп,
        Сәфәренә китмеш карап[15].

---

[4] Бу атама өстендә «шәһәр» дип искәртелгән.
[5] Бу атама өстенә дә «шәһәр» дип язылган.
[6] Бу юлдагы «Сарчингә» (Царицын) атамасы өстендә «шәһәр» диелгән һәм «түләп» сүзенә карата «парахут хакыны» диелгән.
[7] Бу атама өстендә «шәһәр» дип язылган. Күрәсең, Калач-на-Дону каласы күздә тотылгандыр.
[8] «Растуф» (Ростов) атамасы өстендә «шәһәр» дип искәртелгән
[9] Бу сүзнең өстендә «Шәехзадәнең» дип язылган.
[10] «Чиястополь» (Севастополь) атамасы өстенә «шәһәр» дип язылган.
[11] Бу сүзнең өстендә «олуг парахут, кораб» дигән аңлатмасы теркәлгән.
[12] Бу сүз өстенә «каты дулкын» дигән аңлатмасы язылган.
[13] Бу атаманың өстендә «Кара диңезне» диелгән.
[14] Бу сүзнең өстендә «Исламбулда» (Истанбулда) дип язылган.
[15] Бу юлның өстендә «Шәехзадә» диелгән.

Исламбулы сагъ үтеп,
Бәхре Мәрмәрә кичеп,
Бурса[16]шәһәрә ирешеп,
    Искешәһәр китмеш сорап.
Искешәһәрдән алтмыш чакрым
Үтеп Бәгъдад тарафа,
Кызыл Чишмә дигән йире
    Карары күрмешләр савап.
Мөһаҗирләрә имам булу
Шәех касдында икән...
Кәлеп мәүт фөҗьәтән[17],
    Эчмеш әҗәли шәрап.
Ун көн микъдары йөреп,
Мөкаддәр ризкын йийеп,
Әһле әүляд ятим куеп,
    Ирҗигый ирешмеш хитап.
Кырык бердәде яше,
Акарде даим җәше[18].
Кәрәк карый, кәрәк җәше[19]
    Эчәр әҗәли шәрап.
Булып фирак – мөсафир,
Китеп ерак – мөһаҗир.
Вирең максудын әҗер,
    Дәфтәрен мәмлү савап.
Олуг шәһәр Искешәһәр,
Өяз дәгел, губерна.
Крипечле һәм бик мәгъмүр,
    Мазарында ул тораб.
Анатули дигән йирдә,
Әнкарадан[20] бер тараф
Мөһаҗирләр көллесе
    Ватан тотмышлар карап.

---

[16] Бу атама өстендә «олуг шәһәр» дип искәртелгән.
[17] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «аңсыздан» (кинәт) дип язылган.
[18] Бу юл өстендә «Ходадан куркып» диелгән.
[19] Бу юлның өстендә «һәркем» дип искәртелгән.
[20] Бу атама өстендә «олуг шәһәр» дип язылган.

Ул мөһаҗир Шәехзадә
Әййүл егерме өчендә
Ахирәтә һиҗрәт кыйлмыш,
Калмыш әүляды егълап.
«Вә ма тәдри нәфсүн
Би-әйи ардин тәмүт» каулечә
Гаять тәгъҗил сәфәр кыйлды[21],
Аслы мәэхузә тораб.
Икенче хакыйкый һиҗрәт
Шәехзадә кыйлмыш, әлбәт,
Әһле әүлядына хәсрәт
Вакыйг улмыш бихисап.
Тәнзиһ-ү-тәлкыйне кыйлып,
Җеназасын укымыш
Эстәрлебаш мөһаҗир
Әхмәтситдыйк хәлфә карап.
Соңра Әхмәтситдыйк хәлфә
Йөрмеш сәламәт бер атна.
Ирешеп ваба мәразы,
Вафат улмыш ул әхбаб.
Ислам йиренә рәгъбәт кыйлып,
Касд кыйлды [ул] һиж(е)рәт
Шөһәда дәрәҗәсен, әлбәт,
Табып ул, булмыш мөсаб[22].
Мән зәгыйфькә мәктүб язмыш
Хәятында Шәехзадә.
Искешәһәрдән Шәехгаттар
Җибәрмеш пуштыга түләп.
Алып мәктүбе укып,
Белдек аның вафатын.
Укып тәрҗигъ аятен,
Дога кыйлдык без егълап.

[21] Бу юл өстендә «Шәехзадә» диелгән.
[22] Бу юлдагы «ул» сүзенең өстендә «Шәехзадә» дип искәртелгән һәм «мөсаб» сүзенең мәгънәсе – «мәэҗүр» (әҗерле, саваплы) дип язылган.

Кыйлып горбәт ихтыяр,
Кыйлды һиҗрәт бәхтияр[23].
Булып һиммәт әһле яр,
　　Һәркем күрмешләр әхбаб.
Әһле әүляды рожуг кыйлып[24]
Ирешмешләр сәламәт,
Халә анлар башкортта,
　　Белмәдем хәлен сорап.
Насыйп булса күрермез,
Барын һәм сорашырмыз,
Шәехгаттар (угылы) кәлер
　　Дәеп ятам мән егълап.
Ундүрт туган көллесе,
Шәех тик юк бересе!
Үзе галим, үзе мәрд[25],
　　Гаҗиз дәгелде – җавап.
Мәнем ул мохлис әхи,
Булмас аның тик дәхи.
Гаять ул ирде сәхи[26],
　　Горбәте кыйлмый хисап.
Тәвәккәле там иде,
Гадате инфак[27] иде,
Җәмгы әмваль дәгелде,
　　Тормады һич аптырап[28].
Тарикатьтә нәкышьбәнди,
Дахил[29] Чистай хәзрәтә,
Әзкяр илә даим мәшгуль,
　　Иҗтиһады бихисап.
Хәтта мөсафир хәлендә
Кыска төннең эчендә

[23] Бу сүзнең өстендә «Шәехзадә» дип искәртелгән.
[24] Бу юлның өстендә «Олуг Күлгә» диелгән.
[25] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе «шөҗагатьле» (батыр, гайрәтле) дип язылган.
[26] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «җумарт» дип теркәлгән.
[27] Бу сүзнең өстендә «Лилләһи» (Аллаһ өчен) диелгән.
[28] Бу сүзнең өстендә «ризыкга һәм әмвальга» дигән аңлатма язылган.
[29] Бу сүз өстендә «Шәехзадә» диелгән.

Әүвәбин һәм тәһәҗҗедне
        Һич куймады ул әхбаб.
Ишрак дөха намазыни,
Кәзалик әүрадларыни,
Тәэхирсез укып барыни
        «Дәлаилел-хәйрат»ы карап.
Ләйлләре кыйлып исһар,
Укып Коръән һәм әзкяр,
Кыйлып тәүбә игътизар,
        Дога кыйлырде егълап.
Кыйлса кемсәлә җөлүс,
Булырде хуш ул мәҗлес.
Һәм кемсәдин булып ус,
        Ләтафәттә һәм җавап.
Бәян кыйлып гаҗәеп[30],
Сүзләгәне ля рәеб[31]
Һичкем алмаеп гаеп,
        Симагъ кыйлдылар егълап.
Булмаган тик зикердә
Күренер иде заһирдә.
Зикер, фикер батыйнда
        Мәшгуль иде бихисап.
Белдермәсде зикрени,
Сүзләрде хуш сүзени,
Салып шәфкать күзени
        Һәркемәде ул әхбаб.
Һәр җыл кәлде башкорттан
Мөхәммәтзакир хәзрәтә,
Нәчә дәрәҗә моракабәдә
        Зикер кыйлды ул әхбаб.
Ифтира[32] дәгел сүзләрем –
Белдем күреп күзләрем.
Бергә булып сәфәрләрем,
        Әкәл-ү-шәраб һәм хаб.

---

[30] Бу юл өстендә дә «Шәехзадә» дип искәртелгән.
[31] «Ля рәеб» сүзләренең өстендә мәгънәсе – «шиксез» дип язылган.
[32] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «буш» диелгән.

Иҗтиһадын камил белдем,
Ханәдә һәм мәган булдым[33].
Сәфәрдә һәм хәзәрдә
Тәҗәссес кыйлдым бихисап.
Сүзләп-көлеп мәҗлестә,
Егълар иде мәсҗидтә,
Ләйлләрдә җөлүстә,
Булмай гафләттә хаб.
Дәюр иде җөмлә сер,
Кыйлмас иде һич сәтер,
Кыйлып гафләтдин сәһер,
Белерде хәлем сорап.
Төнлә тәһарәт алып,
Бу зәгыйфе уйгатып,
Тәһәҗҗедне һәм укып,
Дога кыйлырде егълап.
Имди кемгә бакаем,
Зәгыйфь нәчек бараем[34]?
Мәгәр сабыр кыйлаем,
Юлдаш кыйл йаумел-хисап!
Юк аның тик туганым
Һәм хозур ултырганым.
Ярлыкагыл Гофраным,
Кыйлма каһәр һәм газап!
Имди аның тик булмас,
Эзләсәм дә табылмас,
Кыйлам догам илтимас –
Нәҗат кыйл йаумел-гыйкаб!
Кәтде ул бездин ерак,
Без дә һәм калдык фирак[35].
Каберен кыйл нур-чырак,
Ачып җәннәтдин әбваб.

---

[33] Бу юлның өстендә «Чистай Мөхәммәтзакир хәзрәт мөсафирханәсендә» дип язылган.

[34] Бу сүзнең өстендә «зиярәтенә» дип искәртелгән.

[35] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «аерылып» диелгән.

Кабул кыйлып хәсәнати,
Гафу кыйл сәйеати,
Вирең фәүзе нәҗати,
        Әһвальләрдән һәм хисап.
Каберен кыйл гөлбостан,
Ирешеп рихе рәйхан,
Кыйлгыл маэвасын җинан,
        Күстәрмә аслан газап.
Анда варып каберенә
Зиярәт кыйлмак мөхаль,
Кыйлсалар да мәляикләр
        Фәүж-фәүҗ бихисап.
Шәфагатен мөяссәр кыйл
Зәгыйфә [иде] ул сәрвәр,
Безә нисбәтән җәүһәр,
        Гүя без әхҗәр-тораб.
Гыйбадәтлә мөрүр кыйлды,
Тәгаллемлә һәм гомере,
Әмре мәгъруф, нәһи мөнкәр
        Кыйлып ул шәйхә вә шаб.
Мәсҗидендә, мәҗлесендә
Даим кыйлды нәсихәт.
Халис Лилләһ кыйлырде,
        Дәгел гафләттә хаб.
Бергә булдым дәвамәт,
Һич күрмәдем кабахәт.
Гайре кемсә димәс, әлбәт,
        Тәҗәссес кыйлдым бихисап.
Даим тугрыде каули[36],
Һичкемнән юкде хәүфи,
Кәрәк әкябир-гани –
        Вирерде хаклык җавап.
Нәчә мирзалар илә
Хилаф кәлеп каулилә,

[36] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «сүзе» дип язылган.

Ахунд Мирсәяф хәзрәт илә
        Булмыш әкъваль[37] һәм җавап.
Нәчә гариза язмышлар,
Сабранҗага салмышлар,
Казыйлар, мөфти[38] хәзрәтенә –
        Вирмеш барына җавап.
Һич булмады ул зәлил,
Кыйлып кауленә дәлил.
Шәех тик булган калил
        Тормас иде аптырап[39].
Аның камил һиммәтене
Дия алмам һичберене.
Ул әтрафта камил мәшһүр –
        Мәгълүм һәр шәйхә вә шаб.
Теле мөләттыйфде кәлям,
Диле[40] закирде дәвам.
Булмасын дәю асам,
        Гаять кыйлды иҗтинаб.
Мәгасый[41] мәҗалисенә
Кермәде һичберсенә.
Вәгазь кыйлып күбесенә,
        Нәһи кыйлырде хурлап.
Без гасыйлары дәхи
Ярлыкагыл, йа, Гани!
Хөрмәтенә ул әхи,
        Кыйлма газап һәм гыйтаб[42]!
Гарасатта кыйл рәфикъ[43],
Рәхмәтә кыйлып гарикъ,
Җәннәт гөруһе фәрикъ
        Насыйп кыйл безә, Ваһһаб!

---

[37] Бу сүзнең өстендә «сүзләр» дип искәртелгән.
[38] *мөфти* – 1886–1915 елларда мөфти вазифасын үтәгән Мөхәммәдьяр Солтанов күздә тотылган булса кирәк.
[39] Бу сүз өстенә «җавапка» диелгән.
[40] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «кальбе» (күңеле) дип искәртелгән.
[41] Бу сүзнең өстендә «гөнаһ мәҗлесләренә» дип язылган.
[42] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «шелтә» дип теркәлгән.
[43] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «юлдаш» диелгән.



*Шәехзадәгә багышланган мәрсия*

Җәннәттә һәм мәган[44] булып,
Даим безгә хозур кыйлып,
Насыйп булып, дидар күреп,
Ирешеп сәлами хитаб.
Гәрчә мәнем күп туган,
Һич юк аның тик[45] унган.
Күбе хилафым кыйлган,
Шәтем кыйлып бихисап.
Ул туганым сагынып,
Күземнән яшь агызып,

[44] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «бергә» дип язылган.
[45] Бу сүзнең өстендә «Шәех тик» дип искәртелгән.

Мәзкүр әбъятым язып,
        Көйде бәгърем бихисап.
Һич онытмыйм, сагынам,
Даим догамны кыйлам,
Кабул кыйлгыл, йа, Мәүлам,
        Мөнаҗатем бу егълап!
Кыйлгыл аңа рәхмәти,
Бу зәгыйфькә шәфкати
Вирең фәүзе нәҗати[46],
        Ачкыл җәннәте әбваб!
Мәнем ул ирде рәфикъ,
Мәнгәде мохлис шәфикъ,
Барчамызны кыйл гатикъ,
        Әһвальләрдән һәм гыйтаб.
Гыйльме илә гамилде,
Мәхәббәтем камилде,
Һәр туганнан фазылде[47] –
        Тордык кәлямен дыңлап.
Имди кемә диям сер?
Кыйлмадым андин сәтер.
Шәфагатен мөяссәр
        Кыйл зәгыйфькә ул әхбаб.
Рия дәгел сүзләрем,
Сагынып егълый күзләрем.
Шәфагатен умарып,
        Йаумә йакумел-хисап.
Язды Аллаһ нигъмәти,
Егълап ошбу әбъяти
Гафу кыйл сәйеати
        Үзең Ваһһаб-у-Тәүваб!

[46] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «хәлясы» (котылу) дип язылган.
[47] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «артык» дип теркәлгән.

***

Ятып истилка дәвамәт,
Гаять мөшкел китабәт,
Кыйлсалар һәм мәлямәт –
　　Ятарсән барын дыңлап.
Бәрагыйс һәм каммалә[48],
Кәзалик һәм кандала
Әкәллиләр әзалә[49]
　　Бу зәгыйфе һәм зәббаб[50].
Ятам – дәвам кашынам,
Тәказа кыйлам хәммам.
Нәчә ай тәмам калам
　　Сияһ әбданым карап.
Мөшкил бонлардин хәляс,
Капансаң да гәр палас.
Чыкып ятсаңде лапас –
　　Рәхәт йоклардең гырлап.
Зәгыйфь хәле мөнкәсир,
Җәмигъ хәлдә ул хәсир[51].
Нәчә җыл ятмак гасир[52]
　　Мәгъзул, мәгъмүм бихисап.
Кыйлың зәгыйфькә шәфкать,
Рижам – доганыз, әлбәт.
Гозер кыйлып, китабәт
　　Сезләрә куйдым әхбаб.
Ятам мәхрүм сезләрдин,
Риза булың безләрдин,
Агып яшем күзләрдин,
　　Гозер кыйлдым мән егълап.
Нәзым кыйлдым китабәт,
Тәмам кыйлдым мән, әлбәт.

---

[48] Бу юлның өстендә мәгънәләре: «бәрагыйс» – «борчалар», «каммалә» – «бет» дип язылган.
[49] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «рәнҗетеп» дип теркәлгән.
[50] Бу сүз өстендә мәгънәсе – «чебеннәр» дип язылган.
[51] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «хәсрәттә» диелгән.
[52] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «агыр» (авыр) дип искәртелгән.

Кыйлмаңызлар мәлямәт[53]
        Бу зәгыйфе сез әхбаб!
Кыйлсаңыз гәр тәрәххем,
Табар рәхәт бу рухым.
Сезә әхвәлем шәрхем
        Гаеп итмәңез, әхбаб!
Ташламаңыз, дустларым,
Кәзалик әкарибләрем,
Шәфкать кыйлың, әүлядым –
        Сезә бу гозер китап.
Кәлер рухым сезләрә –
Рәхим кыйлың безләрә,
Нәзар кыйлып күзләрә,
        Гозер кыйлып һәм егълап.
Өмид кыйлып күп көтсәм,
Көтеп-көтеп буш китсәм,
Нәүмиз каберемә керсәм,
        Дәюп яздым мән егълап.
Фикер кыйлып караңыз,
Зәгыйфе онытмаңыз,
Мәхрүм-мәэюс кыйлмаңыз,
        Дәю яздым бу китап.

[53] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе «шелтә» дип язылган.

# [ҺАДИУЛЛА ХӘЗРӘТ МӘРСИЯСЕ][1]

...
Дәю күр угълына рәгъбәт,
        Һадиулла хәз(е)рәте.
Тарих мең дә сигез йөз алтмыш
Сигезендә мәншүр алмыш,
Һәр юлда тәгаллем вирмеш,
        У Һадиулла хәзрәти.
Тәхминән мән бөйлә диям,
Якыйнән газемлә диям,
Камил яшене һәм белмәм,
        Бөйлә дип язам әбъяти.
Түбән Ушмыда улып имам,
Вәгазь кыйлды каумә дәвам,
Мотыйг иде бары әкъвам,
        Кыйлдылар һәп итагати.
Нәсаихы иде Лилләһ,
Иттифакы фи сәбилилләһ,
Риза булгай иде Аллаһ,
        Кабул булып хәсәнати.
Гамил, галим иде үзи,
Мәкъбүлде һәркемә сүзи,
Һәркеме бакарде күзи,
        Тәрәххем кыйлып шәфкати.
Гомере һәм кыйлды мөрүр[2]
Садир улмады[3] һич шөрүр,

[1] Бу текст Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «6674т» шифры белән саклана торган җыентыкның 34а–38б кәгазьләреннән алынды. Кульязмада мәрсиянең башы һәм ахыры юк.
[2] Бу сүзнең өстендә «укыды» дип язылган.
[3] Бу сүзнең өстендә «гаһедендә» (вәгъдәсендә) дип язылган.

Гавам-хассы иде сөрүр,
У Һадиулла хәзрәти.
Хосем күреп һич йөрмәди,
Һичкемнән гариза вирмәди,
Хаким хозура вармади,
Тәхәммел иде гадати[4].
Кәляме иде нәсаих,
Һакәза улмасде кабаих,
Гүя ул иде мәсабих –
Китәрде җәһлә зольмати.
Ушмы халка иде зыя,
Вәгазе дәгелде рия,
Гавамыннан иде риза,
Кая тапмак бу хәзрәти?!
Вафат идүбән бу хәзрәт,
Күп кемсәгә вакыйг хәсрәт,
Батып нур, каплады зольмәт
Ушмының җәшләре-карты.
Мөсәлләм иде һәр кемсә,
Җавап вирерде, сорылса,
Мөшкил мәсьәлә вакыйг улса,
Тапты китап риваяти.
Түбән Ушмының гавамы
Сагынсалар[5] да, дәвамы,
Тапмаслар бөйлә имамы –
Булыр заманның[6] хәзрәти!
Китабы күп фөнүннәрдән,
Нә әшкял табыла анлардан,
Җавабә кави барыннан,
У Һадиулла хәзрәти.
Дәгелде гафләттә хаб[7],
Нә сорсаң, вирде ул җавап,

[4] Бу юлның өстендә «агыр булса да» дип искәртелгән.
[5] Бу сүзнең өстендә «хәзрәте» (хәзрәтне) дип язылган.
[6] Бу сүз өстенә «ахыр» дип язылган.
[7] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «йокыда» диелгән.

Хата димәс иде, савап[8],
    У Һадиулла хәзрәти.
Нә сорсаң, газбе кәлмәди,
Җавабы вирми куймади.
«Шәвагыйлем вар» димәди,
    Язып вирде риваяти.
Җөръәтлә сордык мөшкилят,
Китаптан язды риваять.
Безә иде гүя миръат –
    Китәрде бездән зольмәти.
Бу хәзрәтде безә дәүләт,
Кадерен белмәдек, әлбәт.
Сәясендә идек гыйззәт.
    Нә кыйлдык? Кыйлды һиҗрәти.
Тәгаллем вирде күп җыллар,
Иман, ислам үгрәнделәр.
Дога кыйлсын даим анлар,
    «Остазым» дәю, хәзрәти.
Димәде: «Без кемә бакаек,
Мөшкилят кемнән сораек?»
Ихласлә дога кыйлаек,
    Укубән руха айати.
Безләре пыракты горбәт[9],
Имди кемдин көтик шәфкать[10],
Мәгәр кыйлса, кыйлыр носрәт[11]
    Өскебашы хәз(е)рәти[12].
Бу әтрафта күп галимнәр,
Заһирда күчә камилләр,
Садир булса гәр мөшкилләр
    Хәл кыйлмыйлар мөшкиляти.

---

[8] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «дөрес» дип искәртелгән.
[9] Бу сүзнең өстендә «гариблеккә» (зәгыйфьлеккә) дип теркәлгән.
[10] Бу юлның өстендә «фикер кыйл» дип искәртелгән.
[11] Бу сүзнең өстендә «безләрә» (безгә) дип язылган.
[12] Бу урында Түбән Өскебаш авылының (хәзерге Кукмара районында) Мөхәммәтнәби хәзрәт Мөхәммәтгали улы күздә тотылган булса кирәк.

Нәби хәзрәт тәхәммелми,
Җавап бирә канәгатьли,
Риваятьләр язып татлый,
　　Сөаль кыйлсак ул хәзрәти.
Димим: «Надан ул муллалар»,
Сорсаң, илтифат кыйлмыйлар,
Горурлар – җавап бирмиләр,
　　Кыйлмыйлар һич морагати.
Сорырдык хәзрәттән Ушмы[13],
Җавап вирерде орышмый[14],
Бакарде китап, эче пошмый[15],
　　Нә кыйлыйк? Кыйлды һиҗрәти...
Галим фазыл улса вафат
Бәкәтил-арду вәс-самават,
Мәляикләре кәмаләт
　　Чигәрләр һәп мосыйбәти.
Диделәр мәүте галимни
«Кә-мәүте галәм» диеп ани,
Безә куйды мосыйбәти,
　　Вә һәм нәүбәте һиҗрәти.
Димеш Рәсүлемез хәзрәт:
«Мәүтел-голәма идәр зольмәт».
Әкъвама ирде гыйбрәт
　　Улды динә ноксанати.
Дине ислам гыйбадати
Кем үгрәтер кәмаләти,
Хәләл-хәрәм фирагати
　　Фәрекъ улмай кәмаләти.
Безә диде, гүя, «чурак»,
Нә кыйлыйк имди? Әлфирак!
Пырагып бези, китте җырак,
　　Кыйлып фиркате шиддәти.
Мәҗалисе әһали Ушмы,
Әүвәлге тик һаман хушмы?

[13] Бу юл өстенә «мәсаиле мөшкел» (катлаулы мәсьәләләрне) дип искәртелгән.
[14] Бу сүзнең өстендә «мөлаем» диелгән.
[15] Бу юлның өстенә «иренми» дип язылган.

Яки мәсаилдән бушмы,
Кыйлышып сәб-кабахәти?
Нә хәл вар? Кыйлды ул һиҗрәт,
Безе бырагып мосыйбәт,
Вакыйг безә дә гамь-хәсрәт,
Кыйлубән бездән һиҗрәти.
Тәрек кыйлмый әүкат хөмес,
Хозур иде аның мәҗлес,
Табылмас, кыйлсак тәҗәссес,
Бөйлә мөттәкый хәзрәти.
Халә улса мәҗалисләр,
Сүзләнә гәзит-мәзидләр[16],
Руманнар вә гайре кәзебләр,
Диләнкеләр зирагати[17].
Сәламәттә ул хәз(е)рәт
Үгрәтер иде гыйбадәт,
Булсалар да дәвамәт
Фәраиз вә ачып сөннәти.
Хуш иде холкы-әфгале,
Кыйлырде ихлас әгъмале,
Хошугъ-хозугълә кәмале,
Гыйбадәте һәр әүкати.
Иде ул камил мөттәкый,
Мәкруһ-шөбһәләрдән тәкый.
Дәгелде әһали шәкый[18]
Иҗтинаб кыйлды гаяти.
Хәзрәте күрде күземез,
Тәҗәссес кыйлыйк үземез,
Аның тигдерми сүземез
Җавап вирмәк ул сәгати.
Мөмкин иде димәк ишан
Дәйүрдең: «Ишан бу – инан!»
Пәрһизкяр иде ул гаян,
Руз-у-шәбде гыйбадәти.

[16] Бу юл өстенә «мәҗлестә» дип искәртелгән.
[17] Бу юлның өстендә «сүзләнә» (сөйләнә) дип теркәлгән.
[18] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «явыз» дип язылган.



*Һадиулла хәзрәт мәрсиясе*

Димәде[19]: «Ирермән мөршид»,
Тәрбия кыйлмады мөрид,
Һәркемсәйә иде Хөршид[20],
Горуб улды[21] фөюзати.
Ноксанаты һичкем җимәс,
Гайбәтенә һичкем төшмәс,
Эзләр ирсәң дә табылмас
Аның тик фазыл мөттәкый.

[19] Бу сүзнең өстендә «хәзрәт» дип искәртелгән.
[20] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «Кояш» диелгән.
[21] Бу сүзтезмәнең өстендә мәгънәсе – «батты» дип язылган.

Гоюбын дәюр хасидлар,
Яки сәб кыйлыр җамидлар,
Вә иллә димәс камилләр,
Ифтира һәр гоюбати.
Мәҗалисендә күп булдым,
Гыйльменнән хазы һәм алдым,
Үземә тәҗәссес кыйлдым,
Әдәп-хилмиде гадати.
Сәясендә идек без дә,
Шөбһәмез юкде гыйльмендә,
Хәл кыйлырде һәр мөшкелдә,
Нә кыйлыйк? Кыйлды һиҗрәти...
Гакыл-холкы камил, аек,
Галимлеге заһир, баек,
Безә нисбәтән ул ахак,
Гүя безләр хиҗарати[22].
Бу хәзрәт дик булу надир
Мәсаилгә иде маһир,
Мәмлү[23] батыйны җәваһир,
Кемнән сорыйк мөшкиляти?
Бәгъзе мулла дисәм җаиз,
Риваять сорылса – гаҗиз[24],
Мәгәр Комазан мулла Фаиз
Аның вар камил кодрәти.
Булса да гәр мөдәррисләр,
Горурлыклә мөвәсвисләр,
Сорырга һәм мәсаилләр,
Кыйлып булмыйдыр җөрьәти.
Усы вардан калдык ятим,
Һәр кемсәгә иде хәлим,
Илаһи, кыйл үзең рәхим,
Аңа кыйлма гокубати!

---

[22] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «ташлар» дип теркәлгән.
[23] Бу сүз өстенә мәгънәсе – «тулуг» (тулы) диелгән.
[24] Бу сүзнең өстендә «җавабә» (җавапка) дип искәртелгән.

Бу хәзрәтнең кыйлу һиҗрәт
Беләнләрә ирер горбәт,
Раушан гөле басты зольмәт,
Ирешеп сәхаб зольмәти.
Димәңез: «Бу сүзең ялган»,
Үзеңезгә дә һәм гаян.
Садирмы кабаих-тогъян[25]?
Күстәр, булса сәйеати.
Бәгъзе муллалар кыйлыр сәб[26],
Хөседтән аңа руз-у-шәб,
Тиеш дәгел сәбләргә һәп,
Үзенә ул зыян катый.
Йимеш агача тияләр,
Баштан бөгеп ияләр,
Хәтта өстенә менәләр,
Кыйлып рәгъбәт сәмарати.
Аералар ботаклари,
Аталар таш, таяклари –
Төшермәк чөн йимешләри.
Бетмидер[27] кадер-гыйззәти!
Усак агача тимиләр,
Кәзалик башын бөкмиләр,
Өстенә дә һәм менмиләр,
Булмагач һич хасияти.
Кабих әлфаз ишелмәди[28],
Кәзб-ү-гайбәт һич димәди,
Камил ул ихтисаб кыйлди,
Хаклыкләде мәкаляти.
Нә дисәңез дә дәюрсез,
Бу хәзрәте табалмамыз.
Кая безем һимматемез?
Күстәрик, булса, мәзияти.

---

[25] Бу юл өстенә «гомерендә» дип язылган.
[26] Бу юлның өстендә «хәзрәте» (хәзрәтне) дип искәртелгән.
[27] Бу сүзнең өстендә «ул агачның» диелгән.
[28] Бу юл өстенә «хәзрәттән» дип язылган.

Килсә ул каю мәҗлесә,
Нә кәлям аннан сордисә,
Кәрәк олуг-кечек кемсә[29] –
Үгрәтерде кәмаляти.
Гакыл илә димәс иде[30],
Аять, хәдис укыр иде,
Китаптан күргәзер иде,
Риваять кыйлып шәфкати.
Дәюрде дәхи кыйсаслар[31],
Мөлаем һәм ләтыйфалар[32].
Шат-хәррәмде самигълар,
Хифыз кыйлып мәкаляти.
Мөшкилләреме күп сордым,
Җавабе шафи һәм булдым[33],
Каюсыны хифыз кыйлдым,
Нәфгы таптым кәмаләти.
Бәрек иде мәнем ихлас,
Шуның чөн нәзым кыйлдым хас.
Җәмигъ вәхшәттән кыйл хәляс[34] –
Кыйлам, Раббым, мөнаҗати.
Әүкате варде дөньяви,
Кәзалик инфак охрави[35],
Күп галим дәгел мөсави[36],
Вәзен кыйлсаң гадәләти...[37]

[29] Бу юлның өстендә «сорса» (сораса) дип теркәлгән.
[30] Бу юл өстенә «җавабы» дип язылган.
[31] Бу сүзнең өстенә «могтәбәр» дип искәртелгән.
[32] Бу сүз өстенә «дәюрде» (әйтер иде) дип язылган.
[33] Бу сүзнең өстендә «алдым» дип искәртелгән.
[34] Бу юлның өстенә «йа, Раббым» диелгән.
[35] Бу юл өстенә «варде» (бар иде) дип язылган.
[36] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «бәрабәр» (тигез) дип теркәлгән.
[37] Кулъязмада кәгазе сакланмаган булуы сәбәпле, текст шушы урында өзелә. Ахыргы кәгазенең түбән өлешендә язылган кустодында (ягъни, киләсе битнең башында булырга тиешле) «Галим улса» дигән сүзләр язылган.

# [МӨБАРӘКЗАДӘ МӘРСИЯСЕ][1]

...Кәтде имди мәҗалем.
Кани күркәм җәмалем?
Бәйан кыйлыйм әхвәлем –
　　Сезә тәзкирәм кала.
Мөбарәкзадә сорый
Изен, димәгә сүзи,
Җәш дүгеп ике күзи,
　　Диям атам-анама.
Сәргезәштәм диялем,
Сабавәттәге хәлем,
Тукыз яшемә ирдем –
　　Мәдрәсәгә вармага.
Гыйнаятеннән Алла,
Дәрсемде «Шәрхе Габдулла»,
Тәвәккәл дәюп Алла,
　　Кәттек Түнтәрә вармага.
Сабавәттә мәдрәсә –
Андин юк агыр нәрсә.
Яшьлектән варып керсә,
　　Ят йир, ялгыз калмага.
Ата-анадин ул фирак,
Мәдрәсә гаять ерак,
Вакыйг улдыгым ыграк
　　Ялгыз аерылып калмага.
Әткәм, мәдрәсәгә салдың,
Мине ялгыз калдырдың,

[1] Бу текст Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «7882 т» шифры белән саклана торган кулъязмадан тулаем күчерелде. Автор кулъязмасының башындагы бер кәгазе сакланмаган.

Әҗанибкә яр кыйлдың,
Тәгаллемнәр алмага.
Мәдрәсә бөйлә икән,
Яшьләр мәҗбүрләр икән,
Иза кыйлалар икән
Олуглары, гаҗәба!
Кушалар әнваг хезмәт,
Яшь шәкерт күрә михнәт,
Кыйлмыйлар икән шәфкать,
Күстәрәләр күп җәфа.
Зәмһәрир кеби кыши
Яшь шәкертләр су ташый,
Пешертә хәлфә аши,
Утын табып җакмага.
Кисәм дисәң, балта юк,
Өскә-башка кием юк,
Кыш әйям була суык...
Тиз пешмәгәч сукрана.
Яшьтән мәдрәсә вармак –
Укырга дәгел сабак,
Мәгәр хезмәтә вармак,
Һәр әйям сугылмага.
Һәр кяр яшьләрә агыр,
Даим куя самавыр,
Таба алмыйчы күмер,
Мескен яшьләр тырыша.
Мескен яшьләр йөгерә,
Суык тиеп, җөткерә,
Китә мужик күмерә,
Егълый-егълый ул кайта.
Әнваг җомыш кушалар,
Йитешмәсәң – сугалар,
Әза-җәза кыйлалар,
Нә чара, яшь бичара?
Ялангач аяга башмак
Киеп җөгерә шак-шак.

Кая сабак укымак?!
Мәгәр хезмәт кыйлмага.
Яшьләр карыны була ач,
Йөгертәләр ялангач,
Нә хәл вар дучар булгач,
Хәлфәләр ора-суга.
Юк анлара димәк «уф»,
Һәр нәфәс кыйлып хәвеф,
Сүгә төкереп, дәю: «Теф»,
Тетри яшьләр хәвефга.
Бер шәе булса кулда
Бере алып ыргыта.
Варсаң аны алырга,
Икенче сугып җыга.
Буш хәл укыла «Игълал»,
Мисле багланган әгълял,
Хәл кыйлырдык без кәмал,
Хата дисәң – сукмага.
Укырга булмый нәүбәт,
Һаман кушалар хезмәт,
Хәзрәт тикшерми хикмәт,
Яшьләр мәҗбүр калмага.
Булам дигәндә кагыйд,
Төшерделәр кавагыйд[2].
Форсат юк кыйлу гаит[3],
Мәҗбүрмез хифыз кыйлмага.
Укырдык хифыз кыйлып,
Карарларде дыңлатып,
Коруг сайгакка тезәнеп,
Сорса җавап әймешга.
Җылан дик кулда камчы,
Бер сүз хата әйганчы,
Вирә камчылә ачы –
Рөхсәт юк һич агъларга.

[2] Бу сүзнең өстендә «дәресенә» дип искәртелгән.
[3] Бу сүз өстенә мәгънәсе – «казаи хаҗәт» дип язылган.

Әләмә кыйлмый сабыр,
Егълар ирсәң әгәр бер,
Көтмәгел аслан хәер,
        Җәзаң чикмәк мотлака.
Яткырубән сайгакка,
Суга акыра-бакыра,
Тәкрар куша укырга,
        Гозер юк бер хатага.
Белдек дигәндә тәртип,
Төштек дәрсенә «Тәркиб»,
Гүя тәфтиш, тик әркиб
        Сәкыйльде укымага.
Рөтбә-рөтбә без мендек,
«Хикмәтел-гайн»ә кердек,
Нәчә җыллар интектек,
        Сәгый кыйлып укымага.
Газиз эткәм, мән яздым,
Әхвәлем игълам кыйлдым,
Бүгенгәчә димәдем,
        Рәнҗемәгез дип мәнгә.

***

Нәчә ел кичкәч,
Олуглар киткәч,
Без олуг калгач,
        Камил төшенгәч,
Мөбарәкзадә
Сезләрә яза,
Җәшен агыза,
        Кәлямен дигәч.
Бераз дияем,
Сезә язаем,
Вакыйг булганым,
        Күп кыен күргәч.
Калмаю коруг
Булдык һәм олуг,
Мәдрәсә тулуг,
        Без хәлфә булгач.

Нәчә ел мөрүр,
Без булдык сөрүр,
Үткәреп гомер,
        Табубән рәваҗ.
Үзгәрде заман,
Без калдык һаман,
Кыйлубән гөман,
        Без фикер кыйлгач.
Әйямнардан бер
Олуглар булып бер,
Кыйлдык без фикер,
        Мәшвәрәт кыйлгач.
Дидек күп җәза,
Чиктек без маза,
Булмаю риза,
        Хәлфәләр кыйлгач.
Чикдеге михнәт,
Зиһендә, әлбәт.
Күрдек дәвамәт
        Без кечек улгач.
Диялем ихлас,
Халә без хәляс,
Имди безләр хас
        Мәдрәсә калгач.
Кыйлаек инсаф,
Ният кыйлып саф,
Кыйлаю хилаф,
        Иттифак кыйлгач.
Әүвәлге гадәт,
Кыйлган дәвамәт,
Куелсын, әлбәт,
        Без фикер кыйлгач.
Кыйлмаю нифакъ,
Кыйлыйк иттифакъ,
Ниятемез мотлак
        Хаклыкта кыйлгач.

Җәзалар нахак,
Күрмәкемез хак,
Бер-берә салмак
 Безә кыйлынгач.
Үтте ул заман,
Кәлде бу заман,
Кыйлаек гөман
 Хөррият килгәч.
Кәлде мөнафис,
Нәзыйфка хәсис[4],
Әксәрә нәфис[5],
 Ихтыяр кыйлгач.
Бу хөррият гамь,
Һәрберә әкъвам,
Улсаде дәвам,
 Мохәйяр булгач.
Имди бу әйям,
Төзик програм,
Иттифакълә там
 Гаһдемез кыйлгач.
Ошбу мәдрәсә,
Булмый вәсвәсә,
Хөррият керсә,
 Һәркемә рәваҗ.
Мөхкәм язаек,
Шартлар куяйык,
Гаһед бозмаек,
 Кулымны куйгач.
Улмасын җәбер,
Олуг-яшьләр – бер,
Ишгаль бәрабәр
 Булсын кыйлынгач.
Кыйлыйк гадәләт,
Хаклыклә халәт,

[4] Бу сүзнең өстенә «бәрабәр» дип язылган.
[5] Бу сүз өстендә «мөнафис» (манифест) дип искәртелгән.

Яшьләрә рәхәт
        Булсын язылгач.
Булсын мөсави,
Ишгальләр бары,
Олуг-яшьләре
        Нәүбәт куелгач.
Кыйлубән хаклык,
Бөйлә без яздык,
Куйдык җәббарлык
        Хөррият улгач.
Яшьләр һәм олуг,
Сабый һәм бөлуг,
Кыйлынсын шөруг,
        Үз кяре улгач.
Кыйлып гадәләт,
Куелсын нәүбәт,
Һәркемә, әлбәт,
        Җәбер булмагач.
Һәркем эшләсен,
Гайрә кушмасын,
Тәклиф улмасын,
        Мохәйяр булгач.
Тәклифсез яшьләр,
Хезмәт кыйлсалар,
Мөхәйяр анлар,
        Анлара рәваҗ.
Эшләр һәр кеши,
Үзенең эши,
Пешерер аши
        Карыны ачкач.
Кую самавыр
Кешечөн авыр,
Кыйлмасын әмер,
        Эчәсе килгәч.
Гайрең улса су,
Сормаенча бу,

Алмасын вөзуэ,
        Җаиз улмагач.
Тәклиф кыйлмасын,
Җәбер улмасын,
Вирсен өҗрәсен,
        Нагозер кыйлгач.
Йөрсә гәр сабый[6],
Тәклифтән гайри,
Вар ихтыяри,
        Улынгач рәваҗ.
Һәр кярдә улыр
Ихтыяр кую
(Кәлтерсә дә су),
        Мохәйяр булгач.
Һәркем дәгел кол,
Аңа дәгел угыл –
Тиермәсен кул,
        Хөррият булгач.
Кыйлса хыянәт,
Гайре җинаять,
Тәфтишлә, әлбәт,
        Исбат кыйлынгач.
Гоюбе кадәр,
Хөкем кыйлыныр,
Җәза вирелер –
        Ул мәгъюб улгач.
Монлардин гайре,
Язылды бары,
Улынып разый,
        Програм төзегәч.
Дәрес укылсын,
Нәху, фикъһ улсын,
Мантыйк куелсын,
        Хаҗат улмагач.

[6] Бу юлның өстендә «хезмәтә» (хезмәткә) дип искәртелгән.

Ысул, әхадистән
Һәм тәфасирдән –
Укылсын барыннан,
        Мантыйк куелгач.
Бөйлә програмны,
Язып исмемез,
Куйдык кулымыз,
        Иттифакъ кыйлгач.
Хәзрәтә яздык,
Кыйлып тәмәллык,
Бөйлә дип хаклык,
        Без фикер кыйлгач.
Гозерлә гаять,
Кыйлдык китабәт,
Дамелла, әлбәт[7],
        Иттифак кыйлгач.
Мәдрәсә тәртип
Булсын лә рәеб,
Кыйлмагыл гаеп,
        Безләр үтенгәч.
Кыйлдык илтимас,
Дамелла рәдд кыйлгач
Һәм газбе килмәс,
        Сорап карагач.
Кыйлдык без рижа,
Таләбә барча,
Кыйлыр дип бәрҗа,
        Илтимас кыйлгач.
Безләрә рәис
Остазымыз нәфис,
Димәс ул: «Хәсис!»
        Бөйлә без соргач.
Кыйлмаса кабул,
Бөйлә калыр ул,

[7] Бу юлның өстендә «кабул кыйлыр» дип язылган.

Эстәмимез җул[8],
Тапмасак рәваҗ.
Хаҗәте сорсак,
Дәелми «ахмак»,
Кабул йә рәдд кыйлмак
Хакимең улгач.
Сорыла хаҗәт,
Рәистән гаять,
Кыйлып китабәт,
Гозере булгач.
Кабул йә кыйла рәдд,
Табылмый дип шарт,
Кыйлмый мәлямәт,
Кабул кыйлмагач.
Бөйлә дип яздык,
Вә һәм күндердек,
Бер җавап көттек
Сөаль кыйлынгач.

***

Ләгаллә хәзрәтемез укыя
Безләрә мәлямәт кыйлмая,
Дәю кыйлыр идек риҗа,
Хөсне занымызде бирия.
Мөбарәкзадә дия: «Әткәм!
Симагъ кыйлың мәнем кәлям,
Шул хәл нә улдыкы игълам
Тәфсил кыйлмак мәнгә кая?
Укып дамелла безем мәктүб,
Безләре белгән ул мәгъюб,
Газебләә укымый, фәһем кыйлып,
Тәхәммел ул кыйлу кая?
Газабыннан кыйлмыйчы сабыр,
Гайрәтеннән кыйлып фәхер,
Гакыйбәт шәрме йә хәер,
Илтифат безә кыйлу кая?

[8] Бу юл өстенә «хакимнән» дип теркәлгән.

Кәлде мәдрәсәгә гайяр,
Рабутниге мәган – тайяр,
Намы Хөсәен мужик әшрар,
Газеблә мәдрәсәгә керде, йа!
Кыйлубән безә мәһабәт,
Күстәреп газбә сәясәт,
Сәб кыйлып вә һәм хәкарәт,
Дәю: «Язылган кемсәләр кая?»
Кәлдек дамелла хозура,
Диде ул нә кәлсә хотура,
Кәтте, язуымыз сора:
«Нәчөн яздың? – дәю, – Кая?»
Тәҗәссес кыйлмаю һичбер,
Газбеннән тетрәю дер-дер,
Безем кәлям симагъ кыйлмаюр,
Дәю: «Фасикълар, мәлгунь, бирия!»
«Ятыңыз – сугам, кыйлам җәза,
Язып кыйлдыңыз мәне әза!»
Хәкарәт кыйлып безе барча,
Бер кәлям димәк форсат кая?
Нәкадәр без гозер кыйлдык,
Рәхименнән мәэюс улдык,
Итагать кыйлубән яттык.
Хөсәенә ди: «Зарб кыйл бирия!»
Вакыйг булды безә бу халәт,
Хөсәен кулында зареб аләт,
Суга башлады бигаять,
Хадиме фасикъ бихәя.
Торубән мужик аяга,
Талиблар ятып сайгага,
Йөзе кара мужик ага
Рәхимсез сукты бихәя.
Сөаль кыйлмый бездән җавап,
Язмактан сормаю сәбәп,
Нәчә таләбә улды мәзруб
Әлендән рабутник бихәя.

Нә шәригать, нә бу канун –
Дучар мужик кулыга бу көн?
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән найумный бихәя.
Гоюбемезә юк дәлил,
Нәчек бөйлә кыйла зәлил,
Нәчә таләбә улды мәзруб,
　　Әленнән, гүя, палашчы бихәя.
Гоюбемезә бер хәдис-аять,
Кыйламы зарбә дәляләт?
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән мужик җаһил бихәя.
Һич әмерә кыйлмадык инкяр,
Нахак җәза күрәмезләр,
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән нәҗес мужик бихәя.
Ишеткән-күргән һич вармы,
Талибләре мужик сугамы?
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән тәмиз мужик бихәя.
Талибләре тәхфифлә хәкарәт,
Мужиккә суктыру вармы аять?
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән кабих мужик бихәя.
Гыйндендә хәзрәтемез Түнтәр
Талибләре найумныйдан кәмтәр.
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән патлис мужик бихәя.
Гыйльме тәхсыйлә Түнтәрә вардык,
Мужиктан сугылырга вармадык.
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән хамә ахмак бихәя.
Хәзрәтә кыйлсак сәркәшйазидан
Суксын үзе, агызып кан.
Нәчә таләбә улды мәзруб
　　Әленнән хинзир мордар бихәя.

Безем сөаль кыйлып язу
Шәригатә мохалифме?
Нәчә таләбә улды мәзруб
Әленнән шакшы мужик бихәя[9].

***

Програма язылган байлар
Сукылмыйчы калдылар.
Җуаш, фәкыйрь шәкертләр
Сугылды бары егълап.
Типкәләп хәзрәт үзи,
Камил суксаде бези,
Димәсдек аслан сүзи.
Суктырды мужикка хурлап.
Сугылып безләр шәдид,
Бай шәкерткә юк тәгъдид,
Дидек: «Булаек бәгыйд,
Юлымызны без карап.
Хәзрәттән юк һич шәфкать,
Кыйлаек безләр һиҗрәт.
Калган шәкердә гыйбрәт
Китү мәдрәсә ташлап.
Торыйк дисәк без монда
Һаман безгә бәддога.
Әйдә, китик Бубыйга,
Ходадин ярдәм сорап.
Торсак та монда әбәд
Һаман безгә дога бәд,
Һиҗрәт кыйлмыйчы лябед», –
Дидек без, камил уйлап.
Торыйк дисәк без Түнтәр,
Һәркем безләрдин көләр:
«Мәзрубләр болар, җүләр!» –
Дәюрләр һәркем хурлап.
Китсәк без мәдрәсәдән,
Мәхрүм булып дәрестән,

[9] Кулъязманың бу урынындагы бер кәгазе сакланмаганлыктан, текстка өзеклек керә.

Гаҗиздек вәсвәсәдән,
Чыгу мәдрәсәне ташлап.
Тәрәддедтә бу көйгә,
Сиррән шәкерт күбегә
Китмәк улдык Бубыйгә,
Биззарур безләр егълап.
Булмасак та китү рат,
Ялладык ахыр пар ат.
Белдертмәскә кыйлып шарт –
Калсын шәкертләр йоклап.
Китәргә улып гайяр,
Сиррән без улдык тайяр,
Дидек бәгъзә биначар:
«Әсбабымыз тор саклап!»
Чыкмага вакыт җитте,
Ямшик һәм килеп керде,
Бәгъзе шәкертләр сизде.
Чыкып киттек без егълап.
Агыр булды бу фирак,
Бубыйга кәттек – ерак.
«Булсакчы кяшки туфрак» –
Дәю кәттек без агълап.
Һаман без яллап кәттек,
Бубыйга варып җәттек.
Сорап фатира кердек,
Тордык бераз аптырап.
Вардык мәдрәсә сорап,
Күрдек шәкертләр – әгъҗәб!
Әнваг лөгатьтән карап,
Укыталар хөрмәтләп.
Хәзрәттән сордык рөхсәт,
Сорашты бездән дикъкать:
«Сәбәп ни кыйлу һиҗрәт?
Түнтәрдән килү әгъҗәб!»
«Ишеттек, – дидек, – тәртип
Һәрбере Бубыйда дип,

Әнваг фәннәр укыла дип,
Бөйлә кәлдек без эстәп».
Рөхсәт вирде кермәгә,
Яхшы урын вирмәгә.
Рөхсәт юктыр йөрмәгә,
Шәраитләрә йөр карап.
Язылган шәраитләр:
Каю сәгать укырлар,
Каю вакыт йөрерләр,
Әкәл-ү-шөруб һәм хаб.
Мәдрәсәгә без кердек,
Һәр фәннең дәрсен сиздек.
Тәртибенә төшендек,
Сөаленә һәм җавап.
Гыйльме һәйәт һәм тәшрих,
Укыдык күп тәварих,
Үгрәндек без һәм «Тәүзыйх»,
Мөсәлләм улды тулляб.
Гыйльме хисап, җәгърафия,
Камил укып һәндәсия,
Гарәбия һәм русия
Лөгатьләрене аңлап.
Һәрбересенә төшендек,
Күрмәенчә сүзләдек,
Сәгатендә тырыштык,
Күп лөгате без сүзләп.
Көн бә-көн артты рөтбә,
Белеп русча, төркийә,
Кадир булып тәкәллемә,
Сөаленә һәм җавап.
Заһир беленде бары,
Мөгаллимнәр сүзләп карый.
Диделәр: «Тәхсин! Ярый!
Бәрәкалла!» – дип хуплап.
Андагы тәртипләри,
Бәяны бәгыйд бари.

Әлхәмде Лилләһ, безләри,
Гыйззәт кыйлдылар хуплап.
Кәлде вакъте имтихан,
Рөтбә-рөтбә куелган,
Һәр фәнгә тәртип булган
Нәүбәтлә бик дикъкатьләп.
Кердек һәрбер нәүбәтлә,
Сөальләрә җаваплә.
Самигълар диде бөйлә:
«Беренче рөтбә яз зурлап!»
Вирделәр намә язып,
Мөһерене һәм басып,
Мөгаллимнәр кул куеп,
«Беренче рөтбә!» – дип, хуплап.
Урысча һәм гарәпчә
Намә вирелде тәртипчә,
«Беренче рөтбә», – дип ничә
Дирделәр камил хуплап.
Намә алдым әлемә,
Хәмед кыйлдым Раббыма,
Ирештем максудыма,
Тәбрик кыйлдылар зурлап.
Әткәем һәм әнкәем!
Бубый тәртип әйтмәем,
Гаҗәепләр димәем,
Имкяне юк мән сүзләп.
Анда укыган кеши,
Шөбһәсез, яхшы эши,
Тәртиплә һәр укыши,
Сәһеллеклә бик әгъҗәб!
«Әткәем, бул сәламәт!
Мәне кыйлма мәлямәт,
Таптым анда кәмаләт», –
Диярмән сәнгә егълап.
Сүземә кыйл игътимад,
Бубыйда камил иҗтиһад

Тәртибә юк һич гыйнад.
        Сәгый кыйлалар – әгъҗәб.
Изен булса газиз эткәм,
Кәзалик мөшфика әнкәм!
Гозер-нияз илә әйтәм,
        Кәлямеме кыйлып игълам.
Дия угылың Мөбарәкзадә,
Сезләрә әхвәлен яза,
Илтифатлә ал нәзарә,
        Диям сезә бераз кәлям.
Сезә[10] димиче юк чара,
Бу мәгъюб угылың бичара,
Вакыйг улынган дучара,
        Биззарур мән диям кәлям.
Симагъ кыйлыңыз сүзләрем,
Түнтәрдән чыкып киткәнем,
Белгәнсез һәм интеккәнем –
        Әбъятым язылган кәлям.
Изенсез мәнем китмәклек,
Дәгелде сезә сәркәшлек,
Сәбәбе улды җәберлек,
        Гафуыңызны гозер кыйлам.
Углыңыза нәләр вакыйг,
Күрдекемез җәза шаигъ,
Сезләр һәм улганчы самигъ,
        Улынганде бары игълам.
Ходай, бу гарьлек төбегә
Лязим без китү Бубыйга,
Хәтта Себерә – Амур буега
        Сәһел китү мужик сугудан.
Биззарур без сабыр кыйлдык,
Мужикы кыйлырдык мамык,
Хәзрәтә морагать кыйлдык,
        Булырде мужик кяре тәмам.

[10] Бу сүзнең өстендә «кәлямем» (сүзләрем) дип искәртелгән.

«Хикмәтел-гайн»ә без кердек,
Нахак сугылдык, сүгелдек,
Мужиктан сугылу гарьлек –
        Фикер кыйлып кара, әткәм!
Бөйлә хур улу таләбә,
Нәҗес мужик кыйлу истиһза
Тәхәммел булырмы? Гаҗәба!
        Мужик сукмакы кыйл ифһам.
Фикер кыйлдым сорау рөхсәт[11],
Белдем һәм хәүфеңез, хәзрәт,
Изен булмадыкым һиҗрәт
        Белүбән, кыйлмадым игълам[12].
Хакыйкый мән идем мәгъзүр,
Дәгел китмәклегем мәгърур,
Кителмәде улып мәсрүр.
        Нәчек сезә кыйлам игълан?
Кыйл-у-каль сезә күп булган
Дәю, мән кыйламән гөман.
Җөрьәт кыйлмыйм кыйлу бәян,
        Тасдыйк улмас мәнем кәлям.
Бәхетем кара булып нагяһ,
Мәгъюб углыңыз руйсияһ,
Кичеңез кыйлдыкым гөнаһ! –
        Игътизар кыйлып ялварам.
Хозурыңыза мән кайтсам,
Аяк кочып рөхсәт сорсам,
Сездән изен югын белсәм...
        Бәлам – Түнтәрдә калу дәвам.
Мөбарәкзадәгә вакыйг бу хәл,
Сезнең рөхсәт кыйлу мөхаль,
Һиҗрәт кыйлдык, калмый мәҗал!
        Гоюбем кичең? Ялварам.
Мәдрәсәдән кыйлып фирар,
Безә улмады һич зарар,

[11] Бу юлның өстенә «сездән» дип язылган.
[12] Бу юл өстенә «сезләрә» (сезгә) диелгән.

Мәгәр сез белдеңез әшрар,
Бәддога кыйлып сез дәвам.
Дәю: «Ләһү мәза ма маза
Лә йәнфагул-хәзәрү галәл-каза»,
Лябед, без булмыйчы риза,
Хикмәтене Ходa Галләм.
Сезләрә гоюбем газыйм,
Гозер кыйлып җәшем агызыйм,
Аякыңыз кочып тәгъзыйм,
Камил агълаю мән кыйлам.
Мөшфикъ улып ата-анам,
Тәгаллем вирдеңез мәнгә,
Газыйм әҗер вирсен сәнгә,
Рәхим кыйлып, сезә Мәүлам.
Биззарур улды китмәкем,
Галиблектән интекмәкем,
Мәгъзүрмән сезә әйтмәкем,
Гафу кыйлыңыз дәюп: «Балам».
Гоюбләреме мән хамил,
Сезләрә мәгъюбмән камил,
Хәмакатлек мәнем җаһил
Рәҗуглә истигъфар кыйлам.
Әгәрчә кәттем Бубыйгә,
Рөхсәтсез бөйлә бу көйгә,
Хозурыңыза керми өйгә,
Кыйлырсыз мәныг дип дәвам.
Бубыйга мәнем китмәкем –
Фахишә йорта китмәдем.
Һаман касдымде тәгаллем,
Әнваг лөгать белү тәмам.
Китмәдем мән трахтиргә,
Яки бер-бер хәсис кяргә,
Хилафмы бу шәригатькә,
Тәгаллемчөн китү, атам?
Бохарада бөйлә гадәт,
Мәдрәсәдән мәдрәсәгә һиҗрәт,

Ислам йирендә күп, әлбәт,
Бөйлә дип кыйлалар игълам.
Качып без Бубыйга вардык,
Дөньяви хаҗәтләр алдык,
Уку-язу кадир улдык
Гарәп, фарси, руси кәлям.
Әнваг лөгатьтән хаз алдык,
Варудан файда күп йолдык.
Ләкин сезә гасый улдык.
Нә кылыйм? Мәгъюб улып калам.
Максудым барысы булды,
Имтихан кабул кыйлынды,
Беренче мәдехнамә вирелде,
Әнваг фән яралып тәмам.
Мәнем максуд улу мәгълүм,
Ләкин сезе кыйлды мәгъмүм,
Хәямнан һәм улам мәгъдүм.
Нәчек сезе риза кыйлам?
Сезе кыйлубән мән әза,
Мәрызга улдым мөбтәля.
Мөбарәкзадә булса бала,
Гаебем кичең, атам, анам?!
Күрәсез – имди мән ятам,
Гыйззәтле атам һәм анам,
Үтенәм – кыйлыңыз ярдәм,
Хәер-дога кыйлып дәвам?!
Яшьлектән өйдә улмадым,
Сезә һич хезмәт кыйлмадым.
Гакыйбәт, мән гасый улдым,
Нә дисәм дә, хәя кыйлам.
Сезә һич улмады файдам,
Мәшәкатем булды дәвам.
Әҗерен вирсәде Мәүлам –
Агълаю кыйламән догам.
Китапларда күп күрәсез,
Тәгаллем нәфгын беләсез,

Һәр хөруфә чиксез аласыз,
Әҗер вирә бихисап Мәүлам.
Әҗерен димәк кыйлам хәя,
Бәян кыйлу мәнгә кая?..
Гомерә укыян хөруф кем сая?
Хисабыны белер Мәүлам.
Әхадисләре күрәсез,
Нәчек дидеген беләсез,
Газыйм әҗере шөбһәсез,
Сезә димәк хәям кыйлам.
Дәгелмән димәгә әхак,
Әдәпсез булу мөхәкъкак.
Хөсне заным кыйлмакым хак,
Галим, фазыл дәю, атам.
Үзең сән галим мөттәкый,
Мәкруһ шөбһәләрдән нәкый,
Китаплар күрәсәз тәкый,
Табасән мәмдух улан кәлям.
Әүляде укытан кеше –
Дөнья-ахирәт изге эше,
Надирдыр аның тиңдәше,
Әҗерләр алмакта тәмам.
Мөбарәкзадә камил хәсир,
Гомере һәм улып касыйр,
Диямән үтенеп: «Тәкъсыйр!
Тәкъсыйратым кичең, атам!»
Гаять тәрбия кыйлдыңыз,
Бу яшь кадәр укыттыңыз,
Мәнем хезмәт күрмәдеңез.
Нә кыйлыйм? Бик хәя кыйлам.
Нә кәлям дисәм мән гаҗиз,
Мар(ы)зымнан улмыйм фаиз.
Әткәм, әнкәм! Сезә җаиз
Гафу кыйлыңыз, дәю «балам».
Бу әхвәлә улдым вакыйг,
Догасыз гомрем үтте заигъ,

Сабавәттән улып балигъ,
Мәшәкъкатем сезә дәвам.
Егермегә иреп яшем,
Хезмәттә улмады башым,
Нәдамәттән ага җәшем...
Онытма мине, зинһар, атам!
Нәчек мән күтәем ярдәм,
Шәремсармән, һаман риҗам[13] –
Мөшфикълар дип атам-анам,
Хөсне заным кыйлам дәвам.
Нә кыйлыйм, кыйлмадым хезмәт,
Нәчек сез дәюрсез: «Рәхмәт!»
Хәямны кыйламән гаять.
Нә йөзлә мән гозер кыйлам?..
Нә кәлям дәюргә белмим,
Каю лисанлә ялварыйм,
Сезе нәчек риза кыйлыйм?
Нә дисәм дә, хәям кыйлам.
Лисанемлә дия алмыйм,
Сезә нәзар кыйлып калыйм,
Имди сез улыңыз салим,
Газизләрем, фирак улам.
Сезнеңлә даим улмадым,
Камил сагынып кичде гомерем,
Кыямәтә дәк сезе сагынырам –
Мөбарәк йөзеңез күрмәм.
Бүген сезә нәзар салам,
Сабахда димәссез кәлям,
Әхсән йөз саргаер тәмам,
Күрер әкъбәх атам-анам.
Бу әүдә мән бүген ятам,
Сабахта кабердә калам,
Димәссез: «Мөбарәк, балам!»
Онытма бик тиз атам-анам.

---

[13] Бу юлның өстенә «сездән» дип язылган.

Сезе кыйлмадым кадр-у-гыйззәт,
Чиктеңез мәнем мәшәкъкать.
Мәнем бу ахыргы мәшәкъкать,
Рәнҗемәңез атам-анам?!
Моннан соң мәне күрмәзсез,
Мәшәкъкатләрем чикмәзсез,
«Мөбарәкзадә» димәссез...
Нисьян мөнсиян мән булам.
Зиһнә калыр шәмаилем
Күркле җәмаль, йөзем-күзем,
Сезә әкъвалем, әбъятым,
Укысаң игътибар, әткәм?!
Бөйлә дип яздым әбъятым,
Кәлүбән мәнем мәматым,
Вактыма укылып кәлямем,
Хотурыңыза килмәк риҗам.
Мөбарәкзадә, ихтимал,
Хотурыңыза кәлер ул хәл,
Фикер кыйлыңыз мәнем әхвәл,
Мөнкатыйг булмас мәнем риҗам.
Сезе мән аслан онытмам,
Риҗамы мөнкатыйг кыйлмам,
Фикер кыйлың атам-анам.
Илтимас – догаңыз дәвам.
Каласыз раушан дөньяда,
Әнваг хәяты кыйлмакта,
Мөбарәкзадә ләхеттә,
Хәйратдин мөнкатыйг дәвам.
Әүлядың сезнең хозурда,
Улырсыз даим хозурда,
Мөбарәкзадә хотурда
Кәлмәсене якыйн беләм.
Нәдамәт бөюте кабер,
Дөньяда кыйлың фәхер,
Мөбарәкзадә ята хофәр
Фирак улып галәддәвам.

Хакепаеңыз улаем,
Илтимас гозер кыйлаем[14],
Ризаңыз рижа кыйлаем,
　　Мәхрүм кыйлма, дәюп: «Балам»?!
Сезе риза кыйлмый китсәм,
Барып каберемә керсәм,
Гарасатта мән сорылсам,
　　Каһәр кыйлып мәнгә Мәүлам.
Җисмеме дәфен кыйлырсыз,
Күп әйям үтми, онытырсыз,
Калан әүлядләр улырсыз...
　　Мөбарәкзадә кабердә дәвам.
Фикер кыйл – нә алып китәм,
Әгъмалем юк, мунис дисәм,
Әткәм-әнкәм дәю әйтсәм,
　　Гоюбемнән хәям кыйлам.
Алып китән шәем кәфен,
Шуныңлә кыйлынам дәфен,
Изен улмас димәк сөхән,
　　Нәчек кабердә мән ятам.
Газизләрем сезе куям,
Сабахта мән мәган улмам,
Илтимаслә гозер кыйлам –
　　Рухыма Коръән укың бер әйям?!
Симаг булмас мәнем сада,
Намым йад кыйлынмас гада,
«Мөбарәкзадә» дәюлмәс нида –
　　Ләхеттә мән мәэюс булам.
Туганнар, гомергә сез бергә,
Йөрерсез бер-берегезгә,
Мөбарәкзадә кәлмәс хотургә,
　　Ләхеттә мән череп ятам.
Мескен әмватлар кызганыч,
Онытып дога булмас һич –

[14] «Рижа кыйлаем» сүзтезмәсе өстендә мәгънәсе – «үтенәем» дип язылган.



*Мөбарәкзадә мәрсиясе*

Хәтта гайдәйн, җомга кич,
Мәэюс улып калам дәвам.
Белмәзсез мәнем әхвәлем,
Рәхим, каһәр кыйлды Раббым,
Нәчек сөалә җавабым,
Кадир йә гаҗиз кыйлды Мәүлам.
Гаеп итмәңез, нә дисәм,
Сабахта ятырам әбсәм,
Тилмереп, сүз дими кисәм
Хәтта «Сәламәт бул!» – дими кәлям.
Ахыр көнем диям кәлям,
Сабахта һәр кярем тәмам,
Күчеп хәйран мәүтә мәнем нам
Калып рухсыз җисмем, эткәм.

Хәятта һәркем кадерле,
Булубән чөчек лисанлы,
Нә кыйлса – була кодрәтле,
Бичара әрваха хәсрәт там.
Әгъмалдин улып мөнкатыйг,
Туганнар һәм улмас нафигъ,
Догасыны кыйлып дафигъ,
Шат-у-хәррәм йөрер дәвам.
Нәчек китапта күренә –
Вафат улып керсә гүренә,
Мөнкир-Нәкир кәлер хозурына
Мәһабәт ятар хөммәлә там.
Сөале «Ма Раббикә?» дип
Вә һәм «Ма нәбийүкә?» дип,
Кәзалик вә «Ма динүкә?» дип.
Кадир кыйл җавапта Мәүлам!
Бәгъзе гасый күрер газап,
Ачылыр бәгъзә җәннәтә баб,
Бостан, бәгъзә хофр-у-нар газап,
Булачак, шиксез, юк кәлям.
Мескен талибә рәхим кыйл,
Тәгаллемә мөгаллим мунис кыйл[15],
Мөждәлә шат-у-хәррәм кыйл,
Һаман шәкерт дәюле рижам.
Яшьлеклә йөрүбән гафил
Дәю[бән] улмадым гамил,
Галим саеп, белдем җаһил,
Үземе алдаюп дәвам.
Яшьлеккә булып әүвәрә,
Хәмакатьлә нәфсә әммарә,
Гафләтлә дөнья гаддарә,
Алдандым, имди нә кыйлам?
Бу халә дөшдем – ни чара?
Нә кыйлсын гаҗиз, бичара?!

[15] Бу юлның өстендә «кабердә» дип искәртелгән.

Мәразы мәүтенә дучара
Рәхим кыйлыңыз – ялварам!?
Гомере мән озын сайдым,
Яшьлектән мәүтем көтмәдем,
Ата-анамы рәнҗеттем.
Риза кыйлмасам, нә кыйлам?
Халә хәтәрем бик газыйм,
Ходаем кыйлмаса рәхим,
Нәчек мән каһәрдән сәлим
Җаваплара дучар булам?
Рәхимнәр әрхәме сәнсән,
Рәхим кыйл бу талибә сән,
Кәләчәкләрем кыйл әхсән,
Гафу кыйл гаҗизең, Мәүлам!
Әкарибтән улам фирак,
Ата-ана кала ерак,
Кабердә улырам туфрак,
Могыйнем мәгәр сән, Мәүлам.
Олуглар кыйлалар әгъмаль,
Хәйратлары кыйлып кәмаль.
Белдем – мән икәнмән әҗһәл,
Яшьлекlә нә алып варам?..
Мәгәр Ходага игътимад,
Нәчек ярдәм кыйлсын гыйбад?
Ата-анага кыйлан гыйнад,
Мөбарәкзадә дәелер нам.
Сәвекле Рәсүл хөрмәтә,
Рәхим кыйл талиб өммәтә,
Васыйл кыйл Раббым, рәхмәтә,
Игътимады сәнгә, Мәүлам.
Ирермән гаҗизин гыйбад,
Нәчек сезә кыйлыйм игътимад?
Хозурыңызда йөзем сәвад,
Нә йөзлә сезә ялварам?
Мөбарәкзадәгә сез рәхим
Кыйлырмысыз? – Ходa Галим,

Хода сезе кыйлсын сәлим,
Рәхимеңез риҗам кыйлам.
Беләм – тиз үк онытырсыз...
Мәнем тик шәкерт күрсәңез,
Хотурә һәм килтерсәңез,
Шәфкать кыйлың, дога – риҗам.
Туганнар булсын сәламәт,
Хезмәт кыйлсыннар дәвамәт,
Фатиха алсыннар, әлбәт,
Мөбарәкзадә улды хам.
Лисанә кәлсә гәр исмем,
Ләхеттә булса да җисмем,
Догадан өмидем кисмим.
Шәфкать кыйлың ата-анам!
«Мөбарәкзадә» дип сорсалар,
Мәнем шәрикләр-шәкертләр,
Диеңез – дога кыйлсыннар
Үтенәм – диеңез, атам?!
Диеңез анлара сәлам,
Мөбарәкзадәнең кәлям,
Риза булсыннар – үтенәм,
Кыямәт куйма интикам.
Дүшәнбә кич тә, атна кич
Догасыз, туган, куйма һич,
Вә һәм гайдәйн, Кадер кич,
Догаңызы кыйлам риҗам.
Сөаль кыйлмыйм кабрә бер шәй,
Кәзалик сормыйм нигъмәт-чәй,
Догадин булмас әкрәм шәй,
Мөбарәкзадә илтимасы там.
Вирер ирсәңез сәдака,
Камил ихласлә, сыйдыклә,
Рухыма багышлап хаслә –
Әҗерен вирер мәнгә Мәүлам.
Сәдакадыр гаять әгъҗәб,
Нәфгы аның ирер гаҗәп,

Әмватнең хәлясә сәбәп
    Әрвахлар илтимасы там.
Һәдия кыйлыныр мәнгә,
Улырам мәсрүр мән, аныңлә
Савабы һәм булыр сәнгә –
    Хисапсыз әҗер вирер Мәүлам.
Махсус һәдия кәлерсә,
Җир анларыма күрелсә,
Фәхерләнерәм күндерелсә,
    Мөбарәк онытылмый дәю там.
Дөньяда кыйлына фәхер,
Вәхшәт бөютедер кабер,
Буланча әйяме хәшер
    Ятар Мөбарәкзадә дәвам.
Нә язсам кәлям хасыйле,
Догадыр аның асылы,
Туганнар, кыйлың ихласлы,
    Мөбарәкзадәгә хас дәвам?!
Хода мәнгә рәхим кыйлып,
Зөнубләрем гафу кыйлып,
Гыйкабыннан нәҗат кыйлып,
    Җәннәт кыйл мәвваме, Мәүлам!
Минемчөн сорыңыз нәҗат,
Насыйп кыйлса иде җәннәт,
Вирүбән әгъля дәрәҗат,
    Дидар күреп, әгъля мәкам.
Мөбарәкзадә бөйлә язди,
Ата-анага кәлями,
Кәзалик һәр тугаными,
    Онытмаска дәю тәмам.
Вә йәбкал-хатт фил-әүрак
Кятибе улса да туфрак,
Мөбарәкзадә улып фирак,
    Тәзкирәм бу атам-анам.

# [БИБИТАИБӘ АБЫСТАЙ МӘРСИЯСЕ][1]

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим

Чиксез хәмедем Аллаһ дияем,
Рәсүлә салаватым күндерәем.
Аль-әсхабләренә һәм
 Зәгыйфьтән күндер, Ходаем!
Илаһым, мәнгә вир ярдәм
Гаҗәеп бер кәлям дияем.
Халә ул вакыйг булды –
 Кыскалыклә мән дияем.
Могтәмидшаһ хәзрәт кызы
Бибитаибә аның исме.
Тәмам улмышы һәм нәфәсе
 Фөҗьәтлә вафат. Нә кыйлаем?
Миладия тарих мең дә
Тугыз йөз егерме дүрт елда
Дикәбер егерме алтыда
 Вакыйг буланны язаем.
Һиҗрия һәм тарих мең дә
Өч йөз кырык өч елда
Җөмадиәл-әүвәл егерме тугызда
 Җомга көн сәгать өч дияем.
Әһлиям Бибитаибә
Чакырылды зыяфәткә,
Өченче әве мәҗлестә
 Әҗәл иреште. Нә кыйлаем?

---

[1] Бу текст Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «3561т» шифры белән саклана торган кулъязма дәфтәрләрнең 1б–28б, 57а, 57б кәгазьләреннән тулаем күчерелде.

Гаять шат иде ул йаум,
Зыяфәтә йөртмеш кавем.
Вәлимә[2] тәгам йигәндә үлем
Фөҗьәт килмеш. Нә кыйлаем?
Дөньядан һиҗрәтә вакыт
Үтмәйме өч-дүрт минут.
Аңсыздан килмеш ул мәүт –
Тәслим рух кылмыш, нә кыйлаем?
Утырган хәл булып фәрех,
Миһманнары кыйлып мәдех,
Вәлимә тәгам кыйлып шәрех
Шул хәл вафат. Нә кыйлаем?
Хатыннар һәм[3] булып хәйран:
«Абыстай, нә булды бу ан?!
Безем бәгъре кыйлма бирьян,
Мәхрүм каламыз, абыстаем!»
Язарга кыйлдым фаразым
Хатын-кыз сүзен кылып нәзым,
Сезә белдердем гарызым
Егълап дидекләрен даим.
«Нә булды сәнга, абыстай,
Дөньядан китәсән бугай?
Каламыз аглаю һай-вай...»
Рәхим кыл абыстайа, Ходаем?
«Агыза кабубән тәгам,
Димәдең безә бер кәлям.
Гаҗәп, нөфусең улмыш тәмам,
Каламыз мәхрүм, абыстаем!
Аслан рәнҗүең беленмәде,
Төсең-битең үзгәрмәде,
Ыңгырашуың ишелмәде,
Сәне бездән алды Ходаем.
Кәефең китеп борчылмадың,
Төсең китеп үзгәрмәдең,

[2] Кулъязмада «вәлимә» сүзенең өстенә мәгънәсе – «күчтәнәч» дип язылган.
[3] Бу сүз өстендә «мәҗлестә» дип искәртелгән.

Бер кәлям безә димәдең –
Бу ни гаҗәп, абыстаем?!
Камил, хозур утырганда
Ава башладың сән анда,
Хатыннар тотындылар шунда,
Ятмаю вафат абыстаем.
Утырдың вәлимә хуплап,
Кунаклар шат кыйлдың зурлап,
Барымыз тордык без тыңлап,
Нә булды сәнга, абыстаем?!»
Мышык-мышык бары егълап
Утырды бары аптырап:
«Китәсән безләре ташлап,
Ни хәл кыйлыйк, абыстаем?
Безләрә идең нур-чырак,
Китәсән сәфәрә ерак,
Имди безләрә әлфирак,
Бәхил бул бездән, абыстаем?!
Бибитаибә абыстай
Сәне бездән алды Ходай.
Халә без аглаю һай-вай,
Каламыз. Сабыр вир, Ходаем?
Безә сән идең мөлаем,
Вәгазь дидең безә даим.
Нә кыйлыйк, алды Ходаем...
Риза бул бездән, абыстаем!
Вәгазь дидең китап карап,
Әнваг нәзым илә барлап
Тәхсин кыйлып, тордык аңлап
Шат кыйлдың бези, абыстаем.
Симагъ кыйлдык олуг-кечек
Кәлямнәрең иде чичек
Сабырымыз кыйлдык ничек?
Китәсән бит, абыстаем!..
Авазың иде гаять саф,
Шәтем кыйлып[4] ормадың лаф.

[4] Бу сүзнең өстендә «безләрә» (безгә) дип искәртелгән.

Димәдең ачу, кәлям хилаф –
        Сабира идең, абыстаем.
Үгрәттең безләрә сабак,
Гадәтең юк иде сукмак,
Ачуың чыкса дидең: «Ахмак»,
        Тәхәммелдең, абыстаем.
Һәр хәлдә сабира идең,
Безе хәкарәт кыйлмадың,
Гоюбемез гафу кыйлдың –
        Шәфкатьледең, абыстаем.
Гыйлем үгрәттең балалара,
Нәсаих кыйлдың нисалара,
Миһербанлы идең анлара...
        Мәхрүм калдык, абыстаем.
Безә сабак үгрәткәндә
Сөялеп тордык янибеңдә,
Ачуың чыкмады шунда –
        Сабира идең, абыстаем.
Үз балаң кеби укыттың,
Барыбызны тигез күрдең,
Белмәяне тәкрар үгрәттең,
        Тырыштың бик, абыстаем.
Үгрәттең безләрә иман,
Намаз шартлары һәм әркян[5].
Тәһарәт, госел, җөнеб булган
        Үгрәттең безә, абыстаем.
Хәез-ү-нифас әхкямени[6]
Белдердең безә барыни,
Фарыз иде белү ани –
        Үгрәттең безә, абыстаем.
Диердең: «Сез олуг булгач
Булырсыз белмәккә мохтаж,
Галәмәтләр заһир булгач
        Госел лязим булыр даим[7].

[5] «Әркян» сүзенең өстендә мәгънәсе – «хөкем-фарызларны» дип язылган.
[6] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «хөкемнәрене» дип искәртелгән.
[7] Бу юл өстендә «сезләрә» (сезгә) диелгән

Булырсыз сезләр ихтилам[8]
Кыйлаем аны һәм игълам...»
(Ләкин язарга оялдым,
Үгрәткән анлара хәлиләм).
«Үгрәттең безә кырык фарыз[9]
Барымыза кыйлып гарыз,
Калдырмадың берен карыз,
Үгрәттең безә, абыстаем.
Үгрәтмәсәң идең безгә,
Йөрер идек нәҗес көйгә.
Газыйм дәүләт белү безгә,
Остазымыз, абыстаем.
Үгрәттең безә кыйлып шәфкать
Безә булды олуг дәүләт.
Нәҗасәттән без сәламәт,
Әлхәмде Лилләһ, абыстаем.
Абыстай, безә нә хаҗәт
Дидең безә, кыйлып шәфкать,
Үгрәттең[10] белеп ганимәт,
Нә зарур безә, абыстаем».

**Абыстай кәляме**

Сабак укырга килдеңез,
Абыстай дәйү барыңыз,
Хаҗәт мәсьәлә ишетеңез,
Сезә камил үгрәтәем.
Бу мәсьәлә булыр зарур
Сезләрә тиз фарыз булыр,
Картайганча кирәк булыр –
Барыңыза үгрәтәем.
Ата-анаңыз үгрәтми,
Ихтимал, үзләре белми.
Сезә үгрәтми чара булмый,
Фарыз кадәре үгрәтәем.

---

[8] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «төшләнмәк» дип язылган.
[9] Бу юлның өстендә «абыстамыз» дип өстәлгән.
[10] Бу сүзнең өстендә «безә» (безгә) дип искәртелгән.

Бу мәсьәлә вакыйг, шиксез,
Күп адәмнән садир чиксез,
Белмәгә сәгый кыйл бик сез
        Тырышыңыз, үгрәтәем.
Белдермәгә мән тырышам[11],
Үгрәнмәсәңез, орышам,
Карышсаңыз, чәчең йолкам,
        Гаять хаҗәт – үгрәтәем.
Балига булырсыз үсеп[12],
Күбегез булырсыз җөнеб.
Хәляс булырсыз коенып[13],
        Тәртибене үгрәтәем.
Сезә госел фарыз булыр
Нәчек пакьлек зарур булыр,
Коенмасаң[14] нәҗес булыр,
        Тырышыңгыз – үгрәтәем.
Мөкәррәмә абыстамыз,
Үгрәтең – белик барымыз,
Гомергә нәзыйф[15] йөрермез –
        Безә[16] хаҗәт, абыстаем.
Госелгә фарыз өч белү:
Агыз-борынга су салу –
Җәмигъ йәрә ирешер су...
        Нәчек кирәк, үгрәтәем.
Госелә шөруг кирәк нәчек? –
Диям кызлар олуг-кечек.
Белмәгә тырыш, һәрнәчек –
        Гомергә хаҗәт булыр даим.
Кулыңнан салың беләзек,
Җуганда[17] тибрәтең йөзек,

[11] Бу юлның өстендә «сезләрә» (сезгә) дип искәртелгән.
[12] Бу юл өстендә «тиз үк» дип өстәлгән.
[13] Бу сүзнең өстендә «госел» диелгән.
[14] Бу сүз өстендә дә «госел» дип язылган.
[15] Бу сүз өстендә мәгънәсе – «пакь» дип искәртелгән.
[16] Бу сүз өстендә «кызлара» (кызларга) дип өстәлгән.
[17] Бу сүзнең өстендә «әбданны» (тәнне) дип искәртелгән.

Коруг калдырмагыл кәндең –
    Мөкаддәм монлары диям.
Истинҗа бәгъдә кулың җу,
Агыз-борынга алың су.
Калдырма гаргарә кыйлу –
    Бөйлә фарыз кыйлган Ходам.
Комганнан баша сал пакь су.
Толымнар сүтүдән мәгъфу,
Чәч төбе калдырма коры –
    Ирештергел суы даим.
Уң тарафтан койгыл су,
Бәдәнләреңне камил у!
«Ин күнтүм җөнүбән фат-таһһару»
    Дәю әмере безә Ходаем.
Камил пакь җу ике аяк,
Аралагыл аяк-бармак,
Ихтимал су керми калмак –
    Дикъкатлә җуыңыз даим.
Аз гына тими калса су
Җәнабәттән котылмый бу.
Камил фарыз ирешү су –
    Мөбаләгълә әмре Ходаем.
Хәез-ү-нифас госелләри
Бөйлә фарыз – белең ани,
Гафил гавам нисалари[18]
    Камил пакь була алмый даим.
Госелә кыйлыңыз дикъкать,
Фарзы гайн белү гаять.
Тимәсә су – җөнеб, әлбәт,
    Нәҗес буладыр ул даим.

***

Фарыз буланы язылды,
Сөннәт әдәпләре калды.

---

[18] Бу юлның өстендә «бәгъзесе» (кайберсе) дип язылган.

Абыстай үгрәткән анлары –
        Белгәнсез хөсне зан кыйлам.
Госелә сәбәп нә улган
Абыстаңыз бәян кыйлган[19].
Сезләрә мән димим гаян –
        Оялмый нәчек язаем?
Абыстаңыз үгрәткән нәчек
Ишеткәнсез олуг-кечек,
Пакь юмак тырыш һәрнәчек
        Әмре безләрә Ходаем.
Күп кемсә буладыр гафил,
Пакь ула алмыйдыр камил,
Үгрәнми калган – ул җаһил.
        Гафу кыйла барын Ходаем.
Үгрәнүне оялмаңыз,
Нәҗес булубән йөрмәңез,
Пакь улып, әҗер[20] алыңыз!
        Пакьләре сәвә Ходаем[21].
Бу мәсьәлә гомергә кирәк
Кирәк ниса, кирәк иркәк.
Пакь улмага тырыш бигрәк –
        Чиксез әҗер вирер Ходаем.
Коенмак булмаса имкян
Тәяммемне кыйлың ул ан.
Госелә тырыш форсат тапсаң,
        Нәҗес улма, пакь йөр даим.

***

«Үгрәттең безә бонлары
Хаҗәтде белү анлары.
Кыйламыз ихлас догалары –
        Рәхмәтә гарикъ кыйл, Ходаем!

---

[19] Бу юлның өстендә «сезләрә» (сезгә) дип искәртелгән.
[20] Бу сүзнең өстендә «савап» дип өстәлгән.
[21] Бу юлның өстендә «Иннә Аллаһә йухиббү әл-мөтәтаһһиринә» дип язылган (Коръәннең «Әл-Бәкара» сүрәсендәге 222 нче аятьтән, мәгънәсе: «Һичшиксез, Аллаһ тәмам чистарынучыларны сөя»).

Вәгазь диден[22] буланча карчык
Мөлаем йөз илә ачык.
Кәлямләрең иде тансык.
        Сагынырмыз, абыстаем.
Ихласлә кыйлдың нәсаих,
Җәмалләрең иде сарих,
Нурлыдең, гүя мәсабих[23]
        Симагъ кыйлдык, абыстаем.
Нә хаҗәт – үгрәттең безә,
Олуг-кечек – барымыза.
Күренмәзсән безем күзә –
        Мәхрүм калдык, абыстаем...»

**Җомга үтеп, шинбә көндәге хәл**

Җомга үтте, шинбә улды
Көн буе хатыннар килде.
Өемә керүбән тулды
        «Күрик – дәю, – абыстаем».
Тәгъзия дәю килделәр,
Тәрҗигъ аять укыдылар[24].
Әфгале хәмидәсен әйделәр
        Аглады ла, дәю «абыстаем».
«Хәзрәт, безә кыйлың рөхсәт –
Пәрдәне ачаек[25], әлбәт,
Күрик абыстамыз?! Рәхмәт!
        Ахыр күрү безем, абыстаем».
Йөзеннән күтәреп пәрдә,
Егълаштылар бары анда
Сабырым кыйлалмыйм анлара,
        Алар егълаганга даим.

[22] Бу сүзнең өстендә «абыстамыз» дип искәртелгән.
[23] Бу сүзнең өстендә аңлатмасы – «кандил» (лампа) дип искәртелгән.
[24] Бу юлның өстендә «Инна Лилләһи вә инна иләйһи раҗигун» дип язылган (Коръәннең «Әл-Бәкара» сүрәсендәге 156 нчы аятьтән; «Без Аллаһы тарафыннан яратылганбыз һәм аның хозурына кайтабыз»).
[25] Бу сүзнең өстендә «йөзеннән» дип искәртелгән.

Тәрҗигъ аять укыдылар,
Мышык-мышык егъладылар.
Зәгыйфькә карап дияләр:
    «Хәзрәтә сабыр вир, Ходаем!
Абыстай, китәсән ташлап,
Хәзрәтемез кала агълап,
Кыйлаек догамыз хаслап
    Рәхим кыйл хәзрәтә, Ходаем?!
Рәхимнәр әрхәме Хода!
Хәзрәтемез ялгыз кала,
Абыстайдан булды җөда,
    Сабыр вир хәзрәтә, Ходаем?!
Абыстай иде юаныч,
Ул китте, хәзрәт кызганыч.
Мосыйбәт[26] вакыйг – юк тыныч,
    Сабыр вир, хәзрәтә, Ходаем!»
Алар егълап диян кәлям
Симагълә сабрым бетә тәмам.
Нөфүсем бетеп, аглыйм дәвам.
    Насыйп кыйл, сабрым, Ходаем!
«Сиксән бишкә яше җиткән[27],
Дус-хишләре үлеп беткән,
Абыстай да ташлап киткән,
    Гамь-хәсрәтлә ятар даим.
Зәгыйфь хәзрәтемез кем карар,
Гаҗиз булып ятар начар,
Аның хәсрәтен кем ачар?
    Калды бичара ул даим.
Абыстай китте, калды хәзрәт.
Вакыйг улып камил хәсрәт.
Ятар даим чигеп михнәт –
    Кызганыч хәзрәтемез даим.
Хәзрәтемез мунисе юк,
Гаять зәгыйфь, җөлүсе юк.

[26] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «кайгы» дип язылган.
[27] Бу юлның өстендә «хәзрәт» дип искәртелгән.

Тәрбиягә абыстай юк,
Мәэюс[28] ятар хәзрәт даим.
Абыстайдаде тәрбиясе,
Ләйл-ү-нәһарда барчасы,
Бәвел, гаит, истинҗасы –
Карады барын абыстаем.
Утыз дүрт ел ята хәзрәт[29],
Урыннан кучалмый, әлбәт[30],
Абыстай кыйлды носрәт[31] –
Нафигаде хәзрәтә даим.
Мөшкел хәл[32] хәзрәтә вакыйг
Зәгыйфьлеге күп кемә шаигъ,
Газиз гомере үтә заигъ,
Рәхим кыйл хәзрәтә, Ходаем!»

***

Шәфкать салса кальбә Мәүлам,
Киленем карар дәю риҗам,
Вә иллә мәхрүми булам[33].
Кемә кушарам мән даим?
Гаурәтемә ирешә нәҗес,
Пакь кыйлу аны юк мунис,
Намаз уку нәчек дөрес?
Мәгъзүрмән кабул кыйл, Ходаем?

***

«Мөшкел хәлләр вакыйг булган[34],
Җәрәхәттән агып эрен-кан,
Абыстай даим тазарткан,
Җирәнмәю, абыстаем.

---

[28] Бу сүзнең өстендә «өмидсез» дип, мәгънәсе искәртелгән.
[29] Бу юлның өстендә «халә 35» (халә – хәзер) дип язылган
[30] Бу юлның өстендә «аслан» (бөтенләй) дип искәртелгән.
[31] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «ярдәм» диелгән.
[32] Бу сүзнең өстендә «әүвәл» дип язылган.
[33] Бу юлның өстендә «карамаса» дип искәртелгән.
[34] Бу юлның өстендә «әүвәлдә хәзрәткә» дип язылган.

Озак ятып хәзрәт чалкан
Буыннар бәгъзесе каткан,
Ике кулы тибрәнмәгән –
        Абыстай караган даим.
Хәзрәтнең булган мөшкел чак
Гаять мәҗрух, булып пычрак,
Абыстай караган ул чак
        Кулы кан, эрен булып даим.
Агызына каптырып тәгам,
Чәйнеклә чәй эчереп дәвам,
Йийдергән-эчергән тәмам
        Мәшәкать чигеп абыстаем.
Хәзрәтемез калды кызганыч,
Абыстай иде юаныч.
Ятар зәгыйфь, булмый тыныч.
        Сабыр вир хәзрәтә, Ходаем!»
Мәзкүрләре дәюп дәвам,
Мышык-мышык егълыйлар тәмам.
Барын ишетеп-белеп ятам –
        Биззарур аглыйм. Нә кыйлаем?..
Хатын-кыз барысы аглый,
Аны ишетеп зәгыйфь егълый,
Нә кыйлыйм – сабырым калмый.
        Лязимдер сабыр кылу даим.
Әфгальләрем такылтыйлар,
Аһ-у-ваһ дәю аглыйлар.
Зәгыйфе дә егълаталар
        Сабырым калмый. Нә кыйлаем?
Диялмыйм анлара кәлям,
Нәфәсләрем бетеп тәмам.
Сабрымы насыйп кыйл, Мәүлам,
        Гамьнәк зәгыйфькә Ходаем!
Егълыйлар күбе сүзләшеп
Симагълә ятам бөркәнеп,
Егълыйм ул хәл сәтер кыйлып,
        Әшкярә була, нә кыйлаем?

**Хатын-кызлар дидеке кәлям**

«Хәзрәт, безә вирең изен[35] –
Күрик абыстамыз йөзен.
Безә юк ишетү сүзен,
Ташлап китте...» Нә кыйлаем?
Хатын-кыз һаман киләләр,
«Абыстай!» – дәю, аглыйлар,
Йөзеннән пәрдә ачалар,
Нәзар кыйлып, дәю: «Абыстаем!
Мөшфика сәвекле абыстамыз!
Сәннән без мәхрүм буламыз,
Олуг-кечек мәхзүн[36] каламыз,
Бәхил бул бездән, абыстаем.
Абыстай, китәсән ерак,
Аглаю каламыз фирак,
Каберең улсын нур-у-чырак!
Догамыз кабул кыйл, Ходаем!
Кыйлдык без әнваг хәмакать[37],
Кыйлмадың бези мәлямәт,
Мәҗалисең иде рәхәт.
Сагынырмыз, абыстаем...
Абыстамыз, аерыламыз,
Сәне аслан күрәлмамыз,
Риза булың – ялварамыз.
Гозеремез аглап, абыстаем».
Алар егълыйлар, мән аглыйм,
Сабырымы кыйла алмыйм.
Такылтыйлар – барын аңлыйм,
Бөркәнеп ятамын даим.
Сәтыр кыйлмак өчен кәлям
Камил иҗтиһадым кыйлам,
Сабырым кыйла алмыйм тәмам –
Заһир була. Нә кыйлаем?

---

[35] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «рөхсәт» дип язылган. Бу дүртьюллык 35б кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.
[36] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «кайгылы» дип искәртелгән.
[37] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «ахмаклык» дип язылган.

«Абыстамыз, фирак буламыз,
Сәннән без мәхрүм каламыз,
Онытмамыз, сагынырмыз,
    Вай, шәфагатьле абыстаем!..
Белмәдек безләр кадреңни,
Кыйлмадык кушкан әмреңни,
Кочакласак та кабереңни,
    Кайтмазсән безә, абыстаем...
Бүген беләмез кадереңни,
Мөнәүвәр кыйлсын кабереңни,
Кыйлыйк ихлас догамызни –
    Каберен бостан кыйл, Ходаем!
Мөнәүвәр, васыйг кыйл кабрене,
Әмн-ү-аман кыйл хәшерне,
Виреӊ әгъля дәрәҗәңне,
    Шат-у-хәррәм кыйл, Ходаем!
Кыйлаек ихлас мөнәҗәт:
Абыстамызны кыйл нәҗат,
Маэвасене[38] кыйлыӊ җәннәт,
    Дидар насыйп кыйл, Ходаем!
Аслан бер күзләр күрмәгән
Колаклар һич ишетмәгән
Һичкем колүбә килмәгән
    Дәрәҗәтә васыйл кыйл, Ходаем!
Кыйлаек догамыз ихлас:
Абыстамызны кыйл хәляс,
Би-хаккы «Сүрәи Ихлас»
    Рәхмәтә гарык кыйл, Ходаем!
Абыстамыза кыйлма газап[39],
Ул мескинә кыйлма гыйтаб[40],
Ачыӊ каберенә рәхмәт баб,
    Рәхәт ятсын абыстаем!
Кабрене Раббым кыйл васыйг,
Мөзәйян һәм улып лямигъ,

[38] Бу сүзнеӊ өстендә мәгънәсе – «урыныны» дип искәртелгән.
[39] Бу юлның өстендә «Йа, Раббәна» (и, Раббыбыз) дип өстәлгән.
[40] Бу сүзнеӊ өстендә мәгънәсе – «шелтә» дип язылган.

Бәшарәтләр улып самигъ,
Сөрүр кыйлгыл абыстаем.
Кабул кыйлып хәсәнати,
Мәхү кыйл[41] һәм сәйеати,
Кыйлыйк ихлас мөнәҗәти,
Камил хозур кыйл, абыстаем[42]!»
Һаман килә яшьләр, карчык,
Пәрдәне кыйлалар ачык,
Бары егълый мышык-мышык
«Әлфирак, – дәю, – абыстаем!
Абыстайдан булдык җөда,
Фазлыңлә, Раббым, бул риза[43],
Барымыз кыйлыйк ихлас дога –
Сөрүр рәхәт кыйл, абыстаем!
Мөәббәд әнваг әсмар ашап,
Хадим сонып әнваг шәрап,
Чиксез тоюр[44] торсын сайрап –
Хозурда кыйл, абыстаем.
Кидер әбданә хөллә назик,
Кулларына төрле беләзек,
Әсабигъларына йөзек –
Мөзәйян кыйл абыстаем!
Мөәббәд ингамлә ихсан
Тәгъзыйм кыйлып гыйльман-вилдан,
Мәмлү әзһар, әсмар[45], бостан
Абыстайга вир, Ходаем!
Әлфирак, абыстамыз, әлфирак,
Керәсән әүвә туф(ы)рак.
Мөзәйян кыйл, Раббым, нур-чырак!
Аерылдык бит, абыстаем...»

[41] «Мәхү кыйл» сүзләре өстендә мәгънәсе – «бетер» дип теркәлгән.
[42] Бу юлның өстендә «Йа, Раббәна» (и, Раббыбыз) дип искәртелгән.
[43] Бу юлның өстендә «абыстайдан» диелгән.
[44] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «кошлар» дип язылган.
[45] Юл өстендә «әзһар, әсмар» сүзләренең «чәчәк, йимеш» дигән мәгънәләре язылган.

**Зәгыйфьнең хатын-кызлара илтимас кәляме**

Хатын-кызлар! Диям бер кәлям[46],
Барыңыза кыйлып игълам,
Сезә мән илтимас кыйлам
        «Бәхил булың, – дип, – абыстаем!»
Хатын-кыз! Сезләрә мәгълүм –
Абыстаңыз булды мәрхүм,
Барыбыз калдык без мәгъмүм[47],
        Риза булың, дәю, абыстаем!
Рәнҗеткән булса сезне бер[48],
Сезләрә мән кыйлам гозер,
Абыстаңыз керә кабер,
        Риза булың – үтенәем[49].
Абыстаңда булса хакыңыз,
Киленез, мәндән алыңыз,
Кыямәтә калдырмаңыз –
        Сезләре риза кыйлаем.
Кыйлса ул сезә хыянәт,
Йә кыйлса сезә җинаять,
Калдырма хакың кыямәт –
        Сораңыз мәндән, вирәем.
Аслан мәндән оялмаңыз,
Хакыңыз булса, алыңыз,
Кыямәт дәгъва кыйлмаңыз –
        Сезләре риза кыйлаем.
Шелтә кыйлса сезне нахак,
Сезләрә булган була гакъ[50] –
Кыямәт сормакыңыз хак.
        Риза булың, гозер кыйлаем[51].
Абыстаң сезә кыйлу гозер
Кодрәте юк, керә кабер,

---

[46] Бу юлның өстендә «сүзләрем» дип искәртелгән.
[47] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «кайгылы» дип язылган.
[48] Бу юлның өстендә «абыстагыз» диелгән.
[49] Бу юлның өстендә «сезләрә» (сезгә) дип теркәлгән.
[50] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «рәнҗеткән» дип язылган.
[51] Бу юлның өстендә «сезләрә» (сезгә) дип искәртелгән.

Аныңчөн мән кыйлам гозер –
Зинһар, риза булың даим.
Кыйлган булса нахак шәтем,
Кыямәт сормакың юк шәкем.
Чәшемнән агызып җәшем –
Кичең хакың, гозер кыйлаем.
Зинһар, хакың кичең һәрбер,
Сезә булыр газыйм әҗер,
Сез дә тиз керерсез кабер –
Кабереңез нур кыйлсын, Ходаем.
Шәфкатьлә риза булсаңыз,
Гаять сез мәэҗүр[52] буласыз,
Абыстаңыз шат кыйласыз,
Каберен нур кыйлыр Ходаем.
Зинһар, хакыңыз кичеңез,
Җакасына ябышмаңыз[53],
Хәсәнат савабә тимәңез –
Сораңыз мәндән, вирәем.
Ул көн хәсәнатең зәррәсе
Тора дөньяның бәһасе,
Сезләр хакыңыз аласы,
Зинһар, бу көндә вирәем.
Гарасат кыйлмаңыз рисвай,
Ул көн дәелми «Абыстай!
Хәзер вир хакымны, давай[54],
Тәэхирсез сәндән алаем».
Вирергә һич шәең булмас,
Гозер кыйлып файда булмас,
Кан-җәш агласаң, кичелмәс –
Гадел хөкем кыйлыр Ходаем.
Алырлар, калмас хәсәнат,
Мәгәр күп булды сәйеат,
Нәчек без булырмыз нәҗат?
Фазл-у-кәрәм кыйл, Ходаем![55]

---

[52] «Мәэҗүр» сүзенең өстендә «саваплы» дигән мәгънәсе язылган.
[53] Бу юлның өстендә мәгънәсе – «гарасатта» (кыяміттә) дип теркәлгән.
[54] Бу юлның өстендә «диерсез» дип искәртелгән.
[55] Бу дүртьюллык 39а кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.

Гарасат халкы аны күрер
Әнбия-әүлиядан оялыр[56],
Нәдамәт кыйлып аглаюр –
        Кыямәт куйма, мән вирәем.
Рәсүлемез күреп торса,
Кулыңыз җакада булса,
Абыстаңыз рисвай булса...
        Хур кыйлмаңыз – мән вирәем.
Фикер кыйлың олуг-кечек –
Абыстаңыз хәле ничек,
Тапмас җирә кермәк тишек[57]
        Хәйран булып торыр каим.
Гайре хәсымнәр күп булса,
Куллары җакада булса,
Абыстаңыз рисвай булса,
        Хур кыйлма – хакың вирәем.
Гаять вәхшәт булыр хәшер[58],
Ул көн дияр адәм: «Иннәл-мәкар»[59]
Риза булың бүген һәрбер –
        Сөальләр кыйлыр бездән Ходам.
Зөнубләремез гаять күп,
Тәүбә кыйлмадык үкенеп,
Әгъмалемез дәгел мәргуб –
        Кан-җәшләр аглармыз даим.
Рәнҗеткән булса мәхлукат,
Эстәмәс бездән хәсәнат,
Вәдагы алыр шул сәгать.
        Чарамыз юк, вир, Ходаем!
Сорар Хода чиксез сөаль[60],
Береннән-бересе әскал[61]

[56] Бу юлның өстендә «абыстаңыз» диелгән.
[57] Бу сүзнең өстендә «качарга» дип язылган.
[58] Бу юлның өстендә «вәхшәт, хәшер» сүзләренең мәгънәләре – «куркыныч, кыямәт» дип искәртелгән.
[59] «Иннәл-мәкар» гыйбарәсе өстендә «кайда качар урын» дип, мәгънәсе язылган.
[60] Бу юлның өстендә «безләрдән» (бездән) дип искәртелгән.
[61] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «агыр» (авыр) дип теркәлгән.

Җавап вирмәю юк һич хәл...
        Фазл-у-кәрәм кыйл, Ходаем!
Абыстаң сезе күрде мөлаем,
Шәфкатьледе сезә даим,
Сез дә дәюп: «Абыстаем»,
        Кичең хакың – гозер кыйлаем.
Абыстаңыз онытмаңыз[62],
Догасыз мәхрүм калмаңыз,
Зәгыйфьне дә калдырмаңыз[63] –
        Газыйм әҗер вирер Ходаем[64].
Хакыйкый остаз ул сезә,
Олуг-кечек, күбеңезә,
Шөбһәсез, риҗасы сездә –
        Дога кыйлмакыңыз даим[65].
Гозерем яшьләрә-олуг,
Абыстаңыз хәйраттан мәмнуг[66],
Дога кыйл рухымыза камуг –
        Кабул кыйлыр догаңыз Ходаем.
Гарасат мәйдан булыр тар,
Көне булыр мунчадан жар[67]
Хәрарәттән димаг[68] кайнар
Вә әгъташ дәюрләр даим[69].

**Хатын-кызлара диям**

Даим сезә гозерем шул –
Абыстаңыздан риза бул,
Зәгыйфь тә өмид кыйлыр ул[70] –
        Дога кыйл, гозер кылаем.

---
[62] Бу юлның өстендә «догадан» дип искәртелгән.
[63] Бу юлның өстендә дә «догадан» дип язылган.
[64] Бу юлның өстендә «сезләрә һәм безләрә» (сезгә һәм безгә) дип искәртелгән.
[65] Бу дүртьюллык 40а кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.
[66] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «тыелган» дип искәртелгән.
[67] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «кызу» дип язылган.
[68] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «баш мие» диелгән.
[69] Бу дүртьюллык 40а–40б кәгазьләрдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.
[70] Бу юлның өстендә «догаңызны» дип өстәлгән.

Абыстаңыз китте ерак,
Барымыздан булып фирак,
Күрмәгә булырмыз мөштак
　　Нә кыйлыйк? Алды Ходаем...

**Якшәнбә көндә булган хәл**

Шимбә үтте, сабах туды,
Кабер казу вакыт булды,
Әкарибе күбе килде
　　Гамь-хәсрәтләр чигеп даим.
Әвемә кереп тулдылар,
Йөзеннән пәрдә ачтылар,
Тәрҗигъ аять укыдылар,
　　Егълаштылар. Нә кыйлаем?..
Госелә шөруг кыйлдылар,
Кабыкка алып салдылар.
Барысы ярдәм кыйлдылар:
　　«Рәхим кыйл! – дәю, – Ходаем!»
Кызы Миһриҗамал җуды,
Гайреләре ярдәм кыйлды,
Кәфенә салып төрелде,
　　Карадылар дәю: «Абыстаем».
Аглаю алар чыктылар,
Ирәннәр килеп керделәр,
Барысы дога кыйлдылар
　　«Рәхим кыйл! – дәю, – Ходаем!»
Хәтем кыйлынган иде Коръән,
Хазир булдылар укыган,
Руха багышладылар ул ан:
　　«Кабул кыйл! – дәю, – Ходаем!»
Искат өчен саум-салават
Әда кыйлынмаган важибат,
Дәүри йөрттеләр кәррат,
　　«Гафу кыйл! – дәю, – Ходаем!»
Тәһлил укыды күп адәм –
Әмватләрә ул бик әһәм.

Багышладылар аны һәм
        «Кабул кыйл! – дәю, – Ходаем!»
Алып чыктылар әвемнән,
Гаиб иттеләр күземнән,
Мәхрүм калдым әһлиямнән...
        Сабры җәмил бир, Ходаем!
Янымнан киттеләр алып,
Карап калдым урныма ятып,
«Әлфирак» дәю хәсрәтә батып.
        Мөбарәк сәфәр кыйл! Ходаем...
Чыгып китте сәфәрә ерак,
Гамь-хәсрәтлә калдым фирак,
Кабере, Раббым, кыйл нур-чырак!
        Тапшырдым сәнга, Ходаем.
Яшьләр-картлар күп җыелган,
Җеназа намаз укылган,



*Бибитаибә абыстайның кабер ташы*

Каберстана варып кергән...
        Риядел-җәннәт кыйл, Ходаем!
Ләхедә салып өртелгән,
Өстенә туфрак өелгән,
Коръән укып, дога кыйлынган.
        Җәннәт бостан кыйл, Ходаем!
Адәмнәр барысы кайткан,
Хәлиләм ялгызы калган,
Бересе мунис булмаган...
        Хәсәнатен мунис кыйл, Ходаем!
Мөәббәд монда ул кайтмас,
Һич кемсә хәлене белмәс,
Кәлям димәк мунис булмас.
        Рәхим кыйл хәлиләмә, Ходаем!
Бинагяһ күзене ачса,
Кабердә ялгызын күрсә,
Нә кыйлачагын белмәсә,
        Имин бәшарәт вир, Ходаем!
Мөнкир, Нәкире күндер, Ходаем,
Камил шәфкатьлә мөлаем,
Җавабә кадир кыйл, Раббым,
        Сөальләренә әһлиям.
Каһәрлә килсә үзләре,
Мәһабәт кыйлыр сүзләре,
Җәшен тик булыр күзләре.
        Безе саклагыл, Ходаем!
Килсәләр гәр тәрәххемлә,
Дәюрләр чичәк кәлямлә,
Сөале кыйлыр тәлкыйнлә,
        Җавап вирер ул мөлаем.
Кыямәткәчә йоклагыл,
Аслан сән гамьнәк булмагыл,
Мәшәкать дөньядан котылгыл,
        Җәннәт насыйп кыйлыр Ходаем.
Гафилмез, күбемез ахмак,
Моннан булмый котылмак,

Һичкемә юк дөньяда калмак –
Гыйбадәтчөн көндерде Ходаем.
Тизүк бу хәлләр киләчәк,
Барымыз аны күрәчәк,
Җавапны нәчек вирәчәк?
Рәхим-шәфкать кыйл, Ходаем!
Вирә алмасак без җавап,
Әхвәлемез безем харап,
Кыйлыначак каһр-у-газап.
Җаваба кадир кыйл, Ходаем!
Күмәрләр ләхедә тыгып
Нәфис әбдан ятар череп,
Буыннар төшәр өзелеп –
Туфрак булып ятар даим.
Ватык касә кеби башлар
Коелыр сакал, чәч, кашлар...
Әкарибләр бары ташлар[71] –
Догасыз ятар ул даим[72].
Кабер хәлен яза алмыйм,
Сезә барын бәян кыйлмыйм,
Китаптан укыгыл даим,
Тәфсилән нәчек язаем?
Сөальләрә виреп җавап,
Ачың кабренә рәхмәт баб –
Рәхәт ятсын җәннәтә карап,
Фазл-у-кәрәм кыйл, Ходаем!
Җеназасын укымадым,
Дәфен кыйлырга вармадым,
Егълаю мән мәхрүм калдым.
Насыйп дәгел, нә кыйлаем?..
Остазбикәм улган мәдфүн,
Фирак булып калдым мәхзүн,
Үлгәнчә ятарам зәбун –
Бөйлә тәкъдир. Нә кыйлаем?..

[71] Бу сүзнең өстендә «онытыр» дип язылган.
[72] Бу дүртьюллык 43а кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.

Мәзкүрләре күрәлмадым,
Озатырга варалмадым,
Нәчек мәдфүн – беләлмадым.
Насыйп дәгел. Нә кыйлаем?..
Мәнкүхәм күмеп кайттылар,
Әвемә кереп тулдылар,
Кәлям Шәриф укыдылар
«Тәкаббәл, – дәю, – Ходаем!»
Остазбикәм китте ерак,
Каберен Раббым кыйл ишрак,
Нә кыйлаем? Тәкъдир. Фирак.
Мәхрүм калдым. Нә кыйлаем?..
Хакыйкый бу булан фирак,
Бәгъре кыйладыр ихракъ[73],
Дөмугы кыйладыр игракъ[74].
Сабры җәмил вир, Ходаем!..
Бу мәзкүрләр дәгел хәфиф,
Ятарам мән даим зәгыйфь,
Зәгыйфькә дога кыйл, әхем шәриф,
«Сабры җәмил вир! – дәю, – Ходаем!»
Әүләрем һич дәгел раушан,
Әһлиям пырагып шауган,
«Фә-әсбиру» дәю Ходаем кушкан.
Сабырым зәгыйфь, нә кыйлаем?

**Зәгыйфьнең дидеге кәлям**

Зәгыйфькә, Раббым, кыйл рәхим,
Җәмигъ әсрареме Галим!
Мәнкүхәмне кыйлдым тәслим –
Җәннәттә васыйл кыйл, Ходаем!
Мөшфика иде әһлиям.
Кыйладе барча тәрбиям...
Имди тәрбиям кемә диям?
Мөшкел хәлә калдым, Ходаем.

---

[73] «Кыйладыр ихрак» сүзләре өстендә мәгънәсе – «яндыра» дип искәртелгән.
[74] Бу юлның өстендә «дөмуг, игракъ» сүзләренең мәгънәләре – «күз җәше, түгә» дип язылган.



*Бибитаибә абыстай мәрсиясе*

Мәмдухәде, хөсенлә[75] әхлак,
Һич кемсә димәде «ахмак»,
Фирак кыйлды Раббым Хәллякъ[76],
Нә кыйлса – тәслим булаем.
Насыйрә[77] иде әһлиям,
Кыйладе барча тәрбиям,
Тәрбиясе иде әһәм.
Рәнҗеми кыйлды ул даим.
Нә кыйлыйм халә мән фирак,
Мәне бырагып китте ерак.

---

[75] Бу юлның өстендә «мәмдухә, хөсенлә» сүзләренең «макталмыш, күркәм» дигән мәгънәләре искәртелгән.

[76] Бу юлның өстендә «...әл-Хәллякуль-Галим» дип язылган (Коръәннең «Әл-Хиҗр» сүрәсендәге 86 нчы: «Иннә Раббикә Һуәл-Хәллякуль-Галим» аятеннән, мәгънәсе: «Һичшиксез, синең Раббың – юктан Бар итүче, Белүче»).

[77] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «ярдәмче» дип искәртелгән.

Кабрен, Раббым, кыйл нур-чырак,
Җәннәт бостан кыйл, Ходаем!
Үзе булса да кабердә
Әфгаль-әкъвале хәтердә,
Язаем бәгъзен сәтырдә.
Барыны нәчек язаем?
Ходаның мән зәгыйфь габид[78],
Мәнкүхәмнән булдым бәгыйд[79],
Раббым «фәгъгаль лә-ма йүрид»[80]
Нә кыйлса, риза булаем.
Ләйл-ү-нәһар кыйлды хезмәт,
Мәнемчөн чикте күп михнәт,
Нәчек анга димәм рәхмәт?..
Җәннәттә васыйл кыйл, Ходаем!
Мотыйгаде остазбикәм,
Сәвекле ул мәнем иркәм,
Ул булмагач кора тенкәм,
Рухына Коръән багышлаем.
Мәкянем кыйладе төзек,
Мөлаем кәлям дәюп чичек,
Ихлас догам кыйлмам нәчек
Намазлар соңра мән даим?
Иренмәде, рәнҗемәде,
Җирәнмәде, чиркәнмәде,
Нәҗес димәде – барын җуды.
Нә кыйлыйм? Алды Ходаем...
Һәр кич уза, сабах туа,
Нәҗасәтләреме җуа,
Оешкан әбданым уа,
Ул юк имди... Нә кыйлаем?
Сүзләремә килми каршы,
Кычыткан әбданым кашый,

[78] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «колы» дип теркәлгән.
[79] Бу сүз өстендә мәгънәсе – «ерак» дип язылган.
[80] Бу гыйбарәнең өстендә мәгънәсе «теләдегемне кыйл» (теләгемә ирештер) дип искәртелгән.

Тәрәххемнән ага җәше,
Зәгыйфе кызганып даим.
Аның әфгале хәмидәсен
Сезләрә димим барчасын,
Беләмән үзем көллесен,
Нафига иде ул даим.
Утыз дүрт елны мөттасил
Тәрбиямне кыйлды хасил.
Рәхмәт, Раббым, кыйл васыйл,
Кабул кыйл догамы, Ходаем!
Имди кәлямен ишетмәм,
Сагынырмын, һич онытмам.
Җәннәтә васыйл кыйл, Мәүлам,
Мөәббәд бергә кыйл, Ходаем!
Сөальләрә вирде җавап,
Каберенә ач җәннәттән баб,
Шат-у-хәррәм кыйлың Ваһһаб,
Рәхмәтә васыйл кыйл, Ходаем!
Әфгаль-әкъвал иде мөлаем,
Тәрбиямне кыйлды даим,
Ризамы эстәде даим,
Әҗре газыйм вир, Ходаем!
Керәнчә кадәри ул кабер
Зәгыйфе кыйлды ул кадер,
Шат-у-хәррәм кыйлың хәшер,
Бәшарәтләр вир, Ходаем?!
Илле биш ел бергә булдык,
Ачу чыгып сугышмадык,
Үфкәләшеп кычкырышмадык[81] –
Сабира иде ул даим.
Яше иде йитмеш яшьтә,
Камил рәнҗетмәде һич тә,
Әфгаль-әкъвале бары истә...
Рәхимәм китте. Нә кыйлаем!

[81] Бу юлның өстендә «азрак булды» дип искәртелгән.

Әхвәлем сорады даим.
Рәхим-шәфкать кыйл, Ходаем!
Ташлап китте, нә кыйлаем?
　　Сабры җәмил вир, Ходаем!
Зәгыйфь ятып даим ялгыз,
Гамь-хәсрәтем була сансыз,
Әвем нурлы дәгел ансыз,
　　Мунисем юк, нә кыйлаем?
Нафигаде мәнга даим,
Ул китте. Мән нә кыйлаем?
Ихласлә дога кыйлаем –
　　Рәхмәтә васыйл кыйл, Ходаем!
Әһлиям рухына ихлас
Коръән хәтем кыйлаем хас,
Гафу кыйл булган булса гас,
　　Раббым, илтимас кыйлаем.
Мәнкүхәмнән улдым җөда,
Нәчек анга кыйлаем дога?
Дәрәҗәтә васыйл кыйл, Ходa,
　　Дидар насыйп кыйл, Ходаем?!
Мәнем ул иде мунисем,
Аныңләде мәҗалисем,
Фирак булу икән кыйсьмем.
　　Тәкъдире бөйлә Ходаем.
Мөшкел хәлем ул булмагач,
Әхвәлләрем соралмагач,
Фирак булып мәхрүм калгач...
　　Мәхбүбәм юк! Нә кыйлаем?
Аны нәчек кыйлмам мәдех,
Әфгальләрен кыйлып шәрех,
Мәне даим кыйлды фәрех,
　　Имди мән кемә бакаем?!
Шөбһәсез, мәдхә мөстәхикъ
Ризамы эстәде тәхкыйк,

Рәхмәтә, Раббым, кыйл гарикъ
        Рәхим кыйл, анга, Ходаем![82]
Димәде ул күп кәлям,
Тугрылыкта иде дәвам.
Рәхмәтә васыйл кыйл, Мәүлам,
        Газап-гыйтаб кыйлма, Ходаем!
Укырде «Йәсин шәриф» һәр көн,
Ихласлә куймый гадәтен,
Камил белеп фазыйләтен,
        «Кабул кыйл, – дәю, – Ходаем!»
Укырде һәм «Хизбе әгъзам»[83]
Белүбән аны бик әһәм,
«Гаммә» сүрә укырде һәм
        Икенде соңра һәр йаум.
Зикр-ү-тәсбих һәм салават[84],
Һәр йаумдә кыйлып гадәт,
Укырде һәм әнваг догават
        Гадәт кыйлубән әһлиям.
Утыз дүрт ел ятам зәгыйфь –
Әшкялем күп дәгел хәфиф,
Әлифтик ятам, әхем[85] шәриф.
        Мәнкүхәм карады даим.
Мөшфикам карады бичара,
Нә кыйлыйм? Китте... Юк чара.
Халә мән вакыйг дучара
        Сабрым насыйп кыйл, Ходаем?!
Утыз дүрт ел кыйлмый җөлүс,
Ятам даим, гүя мәхбүс,
Җәмигыннан булып мәэюс[86].
        Ризамән тәкъдирә Ходаем.

---

[82] Бу дүртьюллык 46б кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.
[83] Бу юлның өстендә «догасы» дип язылган.
[84] Бу сүзнең өстендә «дәюрде» (әйтер иде) дип искәртелгән.
[85] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «туганым» дип язылган.
[86] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «өмидсез» дип искәртелгән.

Сәламәттә күрделәр ләтыйф,
Ятам ялгыз даим зәгыйфь,
Зәгыйфьләр кыйлына тәхфиф,
        Хәфиф дәгел. Нә кыйлаем?
Зәгыйфькә кыйлдыкы хезмәт,
Имкян юк аны китабәт,
Мәнемчөн чикте күп михнәт.
        Әҗре газыйм вир, Ходаем!
Тәрбиям кыйлды иртә-кич,
Рәнҗетмәде мәне ул һич,
Зөнубләрене барын кич[87],
        Рәхимнәр әрхәме Ходам!
Җәрәхәтләреме рәнҗеми,
Пакьләде аслан җирәнми,
Нәчек мән кыйлмам догамни,
        Гафурым, гафу кыйл, Ходаем!
Аның тик кыйлган тәрбия,
Кыйлалмас мәнга бер кемсә,
Тәфсилән язалмыйм сезә,
        Мәхрүм калдым. Нә кыйлаем?..
Бәгъзе вакыт эчем бара,
Мәкянем, әбдан пычрана,
Кемә кушам, кем тазарта?
        Мәхбүбәм юк[88]. Нә кыйлаем?
Гаурәтләремне кем җуар,
Барысы да җирәнеп качар,
Ятарам гаҗиз-у-начар...
        Сабирам юк[89]... Нә кыйлаем?
Сәвеклем һич рәнҗемәди,
Пакьләде, һич җирәнмәди,
Агыз-борын капламади...
        Имди ул юк. Нә кыйлаем?

[87] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «ярлыка» дип теркәлгән.
[88] Бу юлның өстендә «пакьләргә» дип искәртелгән.
[89] Бу юлның өстендә дә «пакьләргә» дип язылган.

Хәзрәти Рәхимә[90] әҗре тик,
Вирең, Раббым, сорыймын бик!
Вирмәкеңә кыйлмыймын шик,
        Зиядә әҗер вир, Ходаем!
Бу мәзкүрләрә кем чыдар?
Ике-өч көннән бары качар,
Мәнкүхәм чыдады биначар,
        Аны аслан онытмаем[91].
Утыз дүрт ел ул чыдады,
Нәҗес дәю пыракмады,
Зәгыйфе камил пакьләде...
        Әҗре газыйм вир, Ходаем!
Әүлядларымыз күп иде,
Барысын тәрбия кыйлды,
Балалара сабак укытты,
        Шәвагыйль күп иде даим.
Бөтен авылның баласи,
Аннан укыды күбеси,
Мәзкүрләр садир көллеси,
        Иҗтиһад кыйлды ул даим.
Мәнга кыйлган тәрбиясе
Язылмый меңнән бересе,
Хәтердә тора көллесе...
        Сагынырмын. Нә кыйлаем?
Хәлиләмде минем тиңдәш,
Сүзләшергә иде иптәш,
Анынңләде даим киңәш,
        Имди мән кемлә сүзләем?
Кыш көн төннәр була озын,
Ятам ялгыз, булып зәбун,
Мунисем юк камил мәхзүн[92],
        Әүһам, хыял, мәмлү даим.

---

[90] Бу юлның өстендә «Әюп галәйһиссәлам җәмәгате» дип искәртелгән.
[91] Бу юлның өстендә «догадан» диелгән.
[92] Бу сүзнең өстендә «кайгылы» дип, мәгънәсе искәртелгән.

Ятарам мән даим ялгыз,
Гамь-хәсрәттән булмый фаиз[93],
Шикаятем дәгел җаиз –
Сабырым юк. Нә кыйлаем?
Утыз дүрт ел мәне караган,
Барысы хак, сезә – ялган.
Нәчек риза булмам аннан?
Сагынырмән. Нә кыйлаем?
Аның тик кыйлган тәрбия
Кыйлалмас мәнга бер кемсә,
Тәфсилән язалмыйм сезә...
Мәхрүм калдым. Нә кыйлаем?
Мохлисәмде мәнга көфу,
Нәҗасәтләремә димәде «фу»...
Зөнубен, Раббым, кыйл гафу,
Әҗре газыйм вир, Ходаем!
Анга кыйлдым ихлас догам,
Кабул кыйлгыл, Рәхим Мәүлам,
Рәхмәтә гарык кыйл, Ходам,
Әгъля дәрәҗат вир, Ходаем!
Утыз дүрт ел – нәчә йөз көн,
Һәр көндә ун тәрбиясен
(Диямән сезә бик азын),
Күпме була? Сездән сораем.
Кичә-көндездә тәрбиям,
Барысын кыйлды әһлиям,
Әшкялем халә кемә диям?
Гаҗиз ятарам. Нә кыйлаем?
«Фә-әсбиру» дәю кыйлдың әмер,
Сабырлара чиксез әҗер[94],
Вә илля[95] күрерәм зәҗер.
Насыйп кыйл, сабырым, Ходаем!

---

[93] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «котылмый» дип теркәлгән.
[94] Бу юлның өстендә «...йувәффә-әс-сабирунә әҗрәһүм би-гайри хисабин» дип язылган (Корьәннең «Әз-Зүмәр» сүрәсендәге 10 нчы аятьтән, мәгънәсе: «Сабыр итүчеләрнең әҗере хисапсыз биреләчәк»).
[95] Бу сүзнең өстендә «сабыр кыйлмасам» диелгән.

Әҗәл җитте, кыйлды рәхәт,
Барымыза куеп нәүбәт.
Без дә тиз кыйлырмыз һиҗрәт,
Хөсне хатимә вир, Ходаем!
Һәркемә әҗәл җитә вакыт,
«Көллү нәфсин заикател-мәүт» –
Тәэхирсез кыйлыначак мәүт.
Бөйлә тәкъдире Ходаем.
Рух әһали бары үләчәк,
Якты дөньядан китәчәк,
Карангы кабрә керәчәк,
Череп туфрак булачак даим.
Ятар вәйран әбдан нәфис,
Ялгыз калып булмый мунис,
Череп-сасып, кәлер кабих ис,
Ләхет кортлар[ы] ашар даим.
Җәмыг кыйлган мәтаг-әмваль,
Әксәре безләрә вәбал,
Гаять дөшвар безем әхвәл –
Хисабын сорар Ходаем.
Җәмигы бездән калачак,
Бәгъзен варислар алачак,
Әксәрдән әгъда талачак,
Безә хисап җәзасы даим.
Хәләл кыйлыначак хисап,
Хәрәм өчен кыйлыр газап,
Шөбһәсенә булыр гыйтаб[96].
Безе гафу кыйл, Ходаем!
Хәләл, хәрәм кыйлмый фәрекъ,
Зөнубләрә булдык гарык –
Сыгмас гаребә һәм шәрык.
Гафу кыйл бездән, Ходаем!
Хәйратымыз юк, бары зөнуб,
Тәүбә кыйлмадык без дүнеп.

[96] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «шелтә» дип искәртелгән.

Кыямәт файда юк үкенеп,
Гафилин булдык без даим[97].
Һәркем әҗәл ширбәт эчәр,
Тәэхирсез дөньядан күчәр,
Рәхәт йә газабә дучар.
Рәхим кыйл безләрә, Ходаем!
Керәчәк кабер – бер ишек,
Сахибе керер, кылма шик,
Бостан йә җәһәннәм тишек.
Җәннәт бостан кыйл, Ходаем!
Мөнкир-Нәкир сөаленә
Гаҗиз кыйлма җавабына,
Җавабым кәлтер телемә –
Тәэхирсез җавап вирәем.
Бәгъзе кемә кабер – бостан,
Ирешүбән рих-ү-рәйхан,
Шат-у-хәррәм ятар һаман.
Насыйп кыйл безләрә, Ходаем!
Җавабын вирә алмаган,
Газабы чигәр ул һаман,
Даим чагар җылан-чаян...
Каһәр күстәрмә, Ходаем!
Сөале симаг кыйлырмыз,
Җавабы нәчек вирермез?
Хәйран-сәргәрдан улырмыз.
Рәхим-шәфкать кыйл, Ходаем![98]
Безләрә кыйлмасаң рәхим,
Газабы татармыз әлим.
Фазл-у-кәрәмлә кыйл сәлим,
Каһәрдән сакла, Ходаем!
Кабериндә ятар ялгыз,
Гамь-хәсрәте булып сансыз,
Даим газапта, имансыз.
Безе әман кыйл, Ходаем!

[97] Бу дүртьюллык 50а кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды
[98] Шушы һәм моннан соңгы дүртьюллык 50б кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.

Мескен адәм бары керәчәк,
Рәхәт йә газап чигәчәк,
Тизүк дөньядан китәчәк.
        Рәхим кыйл безләрә, Ходаем!
Ишеге юк, тәрәзә юк,
Түшәк-ястык, җурганы юк,
Мунисе юк, чырагы юк,
        Горбәт, вәхшәт әве – кабер даим.
Кабер хәле димим бәян,
Китаплара күп язылган,
Абыстаң сезә укыган,
        Нәчек мән аны язаем?
Мөшфикамны тапшырдым, Раббым,
Үзеңә вәдигым[99] кыйлдым.
Рәхмәтә васыйл кыйл, даим,
        Каһәр күстәрмә, Ходаем!
Мөнәҗәтем Раббым Җәлил,
Насыйп кыйлың сабры җәмил,
Хәбибең хөрмәтә һәм Хәлил[100],
        Әҗре газыйм вир, Ходаем!
Мәнкүхәм кыйлмады гыйнад,
Хезмәтемә кыйлды иҗтиһад,
Ачу чыгып кыйлмадык җиһад,
        Сабира иде ул даим.
Остазбикәм онытылмас[101],
Рухы догасыз куелмас,
Сезләрә кыйлам илтимас –
        Дога кыйлмакыңыз даим.
Илле биш ел гомер сөрдек,
Бала-чагалар үстердек,
Фәкыйрьлек-байлыклар күрдек,
        Мәшәкать чикте ул даим.

---

[99] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «әманәт» дип язылган.
[100] Бу юлның өстендә «Хәбибең» сүзенең мәгънәсе «Мөхәммәт галәйһиссәлам» дип, «Хәлил»неке «Ибраһим галәйһиссәлам» дип искәртелгән.
[101] Бу юлның өстендә «догадан» дип искәртелгән.

Аслан дәгелде кязибә,
Вә һәм дәгелде хаинә,
Үлгәнчә улды нафига –
Ризамы эстәде даим.
Мөшфика иде әһлиям,
Тәрбиям кыйлды җәмиләм,
Пырагып китте җәзиләм...
Мәхрүм калдым. Нә кыйлаем?
Тәсәлла кыйладе рәхимәм,
Ул булмагач мән гамь чигәм,
Җәмигъ хәл кыйлды тәрбиям.
Имди мән кемә кушаем?
Ләйл-нәһар ятарам ялгыз,
Гамь-хәсрәтә батып сансыз,
Мөшкел хәлем мәнем ансыз...
Сагынырмын. Нә кыйлаем?
Мәхбүбәңә килсә үлем,
Зәүҗеннән качадыр нәүм,
Вакыйг булып әнваг вәһем
Үткәрү агыр ләяле даим.
Әүһам-хыял күп, тумый сабах,
Шикаятем дәгел мөбах,
Нәчек мән булурмән фәлях?
«Фә-әсбиру» әмре Ходаем!
Кыш көннәр үтә, кич була,
Мунис юк, ятам, юк чара,
Була алмыйм аслан биҗула,
Әүһам-хыял мәмлү даим.
Зикер-тәсбих димәк булам,
Калебтә әнваг хыял дәвам.
Нәчек мән мөфлихин улам,
Һидаять насыйп кыйл, Ходаем!
Мәнем һәр укыган намаз
Фаразый кеби үрдәк-каз,
Сайгакы су дәю көне яз
Коенган тик су дәю даим.

Намазым кыям, рөкүгъ, сөҗуд,
Ишарәлә тәшәһһед, когуд,
Колым диярме Раббым мәгъбүд,
Үрдәк-каз кеби ишарә даим.
Мәнем һәр намаз укыган
Җәмигында була ноксан,
Хали булмый нәҗасәттән,
Шөбһәсез булмыйдыр даим.
Намаз дип укымам ләгаб,
Ихлас улмый мәгәр тәгаб.
Кабул кыйлса, имәс гаҗәп,
Фазлу-у-кәрәм кыйлса Ходаем[102].
Диде: «Фә әдгу Аллаһә мохлисин»
Кыйлаек безләр мәүкыйтин,
Кыйлыр мөфлихин, салимин,
Вәгъдәсе безә Ходаем.
Намазлә әмре бик олуг,
Тәгъдил әркянлә сөҗуд, рөкүгъ,
Калебтә әнваг хыял тулуг,
Хошуг-хозугълә әмре Ходаем[103].
Намазым уку бер гадәт
Ихлассыз улмый гыйбадәт.
Нәчек мән булырам нәҗат?
Рәхим-шәфкать кыйл, Ходаем!
Әмерә кыйлып әшкял,
Намазымда хошуг юк мыскал,
Заһирдә гыйбадәт мисал.
Кәрәмлә кабул кыйл, Ходаем!

### Бәгъзе вакытта

Эч китеп, ага нәҗасәт,
Түшәкләремә һәм гаурәт.

[102] Бу дүртьюллык 52б–53а кәгазьләрдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.
[103] Шушы һәм моннан соңгы ике дүртьюллык 53а кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.

Пакь кыйлу була бик хаҗәт,
        Пакьләргә кемә кушаем?
Мәхбүбәм пакьләп җуаде,
Мәнга шатлыклар буладе,
Ул булмагач мөшкел булды...
        Җуарга кемә кушаем?
Кушарга бары әҗаниб,
Бу әхвәл вакыйг лә рәеб[104],
Ятарам гаҗиз аглаюп...
        Мөшкел бу хәл. Нә кыйлаем?
Яшьтән үк, карчык буланча
Хезмәтләрем кыйлды барча,
Хәтта рухы тәслим кыйланча
        Шул көн дә хезмәтемдә каим[105].

***

Мәрсиямне булса укыган,
Дәюрләр: «Язган кәлям ялган»,
Үземә тәхкыйк раси гаян,
        Кәзебтән сакла, Ходаем!
«Җаиз дәгел шикаятең,
Хаҗәт дәгел сәйеатың,
Нәчөн яздың бу әбъятың[106]?» –
        Мәлямәт кыйлырлар даим.
Сезләрә дәгел әбъятым,
Әүлядым әүлядлара яздым,
Гафу кыйл газиз әхләрем,
        Шәтем кыйлма – гозер кыйлаем.
Булсам идем мән сәламәт,
Кыйлмас идем бу шикаять,
Мозтар халә мән вакыйг, әлбәт,
        Сезләрә аз гына дияем.

[104] «Лә рәеб» гыйбарәсенең өстендә мәгънәсе – «шиксез» дип язылган.
[105] Бу сүзнең өстендә «булды» дип искәртелгән.
[106] Бу юлның өстендә «дәюп» (диеп) дип теркәлгән

***

Мәкянем, гаурәт нәҗес була[107],
Фикер кыйл – аны кем җуа?
Нәзыйф кыйлмак лязим була,
        Җуарга кемә кушаем?
Мәкянемнән кузгалмагач,
Пакьләргә мән гаҗиз булгач,
Аны җумак зарур булгач,
        Фикер кыйлыңыз – нә кыйлаем?
Гаурәтем мән нәчек ачам?
Барысыннан хәям кыйлам,
Җудырмасам, нәҗес калам,
        Бу хәл мөшкел. Нә кыйлаем?!
Хәдәс кыйлып ята бала[108],
Бу зәгыйфь тә шулай була,
Тазартырга гаҗиз кала...
        Мохлисам юк. Нә кыйлаем?
Бала пакьләү гаять сәһел,
Зәгыйфе пакь кыйлу мөшкел,
Өч кеше булмый мөмкин дәгел,
        Гаять мөшкел. Нә кыйлаем?
Түшәктән күтәреп алалар,
Гайре мәкянә салалар,
Нәҗасәтләрем җуалар,
        Гаҗиз булалар. Нә кыйлаем?..
Шул хәл һәм тәкрар пычрана,
Барысы алар сукрана,
Зәгыйфь мескен камил ояла,
        Биззарур тәслим булаем.
Җәмигысенә булам борчу,
Борчуымнан гаҗиз, фөҗу,
Зәгыйфькә дә тияр бит йончу,
        Сабыр кыйлмый, нә кыйлаем?

[107] Бу юлның өстендә «эч барып» дип искәртелгән.
[108] Бу юлның өстендә «астына» диелгән.

Бу хәл вакыйг нәчек ятам,
Барысыннан хәям кыйлам,
Мәнкүхәм юк, гаҗиз калам...
Ул пакь кыйла иде даим.
Киленемә кушып булмый,
Анга кушу җаиз булмый,
Җуарга мохлисәм булмый,
Ятарам гаҗиз. Нә кыйлаем?
Түшәк һәм гаурәт нәҗасәт,
Әвем мәмлү рих кабахәт,
Гаять мөшкел кыйлу нәзафәт[109].
Газыйм хәям. Нә кыйлаем?
Мәзкүрдән гайре күп әшкял,
Береннән-бересе әскал[110],
Монлары мән яздым иҗмал,
Тәфсилән нәчек язаем?
«Фә-әсбиру» әмре безә Аллаһ,
Булачак һәр маша Аллаһ.
Сабыр кыйлың, Нигъмәтулла.
Әҗре газыйм вир, Ходаем!
Утыз дүрт ел[111] ятам дәвам,
Пакь кыйлды хәлиләм тәмам,
Аннан мән кыйлмадым хәям,
Җирәнми пакьләде даим.
Миладия тарих мең дә
Сигез йөз туксан бер елда,
Майның ахыры йаумендә
Мариз, гаҗиз булып калдым.
Шул көннән бирле әһлиям
Үлгәнчә кыйлды тәрбиям,
Чиксез тәрбиясен беләм.
Ул юк имди. Нә кыйлаем?..
Анга даим ихлас догам,
Кабул кыйлгыл Рәхим, Мәүлам!

[109] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «пакь» дип искәртелгән.
[110] Бу сүзнең өстенә мәгънәсе – «агыр» (авыр) дип язылган.
[111] Бу юлның өстендә «халә 36 нчы» (халә – хәзер) дип искәртелгән.

Рәхмәтә гарык кыйл дәвам,
Әгъля дәрәҗат вир, Ходаем!
Әүлядләрем әүлядләри,
Сезә кыйлам гозерләри,
Әби һәм баба рухлари
Шат улсын – дога кыйл даим.
Анлары сез онытмаңыз,
Догасыз мәхрүм кыйлмаңыз,
Кыйламыз даим риҗамыз.
Дога кыйл, дога кыйл даим!

***

Мәрсиямне укысалар,
Укыяннан симагъ кыйлсалар,
Гозерем кабул кыйлсалар,
Дога кыйлың – үтенәем[112].
Әбъятымы яздым ихлас,
Әүлядларым әүлядә хас.
Сез дә дога кыйлың ихлас:
«Рухлары шат кыйл! – дәю, – Ходаем!»
Сезә хас язды бу ахмак,
Укып караңыз бу такмак,
Максуд сезнең – дога кыйлмак,
Онытмаң, дога кыйл даим!
Онытмаңыз дәю яздым,
Коръән укың – риҗа кыйлдым,
Рухымыз шат кыйлың – гозерем,
Намазлар соңра сез даим.
Язып булмый, кул калтырый,
Бер күз сукыр, бере аз карый.
Хөруфләр бозыла бары –
Укый алмыйлар. Нә кылаем?
Каләмнән төшмидер кара,
Чалкан ятып язып кара!

[112] Бу дүртьюллык 55б–56а кәгазьләрдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.

Бармаклар камил пычрана –
        Мөшкел язу, сезә дияем[113].
Безем хәл сезә дәгел мәгълүм,
Кердек кабрә булып мәрхүм,
Догасыз ятамыз мәхрүм.
        Гозерем – дога кыйл даим!
Күземнән агадыр җәшем,
Сиксән биштә халә яшем,
Гаеп итмә һәр кардәшем,
        Рәнҗемә укып – гозер кыйлам.
Вирәлмыйм сезә әрмәган[114],
Бераз кәлям кыйлып игълам,
Күндердем мәрсиям язган –
        Укыңыз, күрсәң мөлаем.
Агып җәшем катрә-катрә,
Бераз кәлям яздым сәтырә,
Зәгыйфе килтереп хәтерә,
        «Рәхим кыйл, – дәю, – Ходаем!»
Сезләре мән күрә алмам,
Сагынып яздым бу намәм,
Хәер-доган камил риҗам,
        Хөсне зан[115] кыйламын даим.
Озак яздым көндез-көндез,
Болыт булса, күрмидер күз,
Яза-яза булды күп сүз,
        Рәнҗемә укып, гозер кыйлаем.
Кабул кыйлсаң, яздым сәнга,
Шәфкать кыйл – дога кыйл мәнга!
Әҗре газыйм сәнга, мәнга –
        Кабул булып доган даим.
Дәюп сезә чиксез сәлам
Күндердем яздыкым намәм,

[113] Бу юлның астында «каләм очы югары булып» дип язылган. Бу дүртьюллык 56а кәгазьдән (икенче дәфтәр өлешеннән) алынды.
[114] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «бүләк» дип искәртелгән.
[115] Бу сүзнең өстендә «кыйлыр дип» сүзтезмәсе өстәлгән.

Гафу кыйлың җәмигъ хатам,
Камил илтимас[116] кыйлаем.
Язылды сәфаһатлә[117] хәмакать
Кыйлу нам хәкарәт-ү-мәлямәт.
Симагълә кыйлурым нәдамәт,
Шикаять кыйлганчөн даим.
Сезә яздым нәчә әүрак,
Укып кара моны азрак,
Мөлаем күрмәсәң – пырак[118],
Мәлямәт кыйлма, үтенәем.
Мәшәкатьлә буны яздым,
Хәер-догаңыз өмид кыйлдым,
Кабул кыйлыңыз гозерем –
Сезә илтимас кыйлаем.
Язуымда бик күп хатам,
Камил картлыктан онытам,
Гафуыңызны риҗа кыйлам,
Сезә илтимас кыйлаем.
«Әрзәли әл-гомри ли-кәй лә йәгълəм»
Шул вакыт җитте дип беләм,
Хатимем ничек? Хода әгъләм.
Хөсне хатимә вир, Ходаем!
Ахыр намәм мәнем сезә,
Укып кара, салып күзә,
Хәер-догаң кыйлың безә –
Даим риҗамыз кыйлаем.
Сиксән биштә инде яшь,
Утыз дүрт ел ятмакым фаш,
Истилка хәл галәл-фираш
Тәмам язылды мәрсиям.

[116] Бу сүзнең өстендә «сезләрә» (сезгә) дип искәртелгән.
[117] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «ахмаклыклә» (ахмаклык белән) дип искәртелгән.
[118] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «ташла» дип искәртелгән.

# «ИКАЗЕЛ-ӘҮЛЯД»[1]

Белеңез әүляд әхвәлем –
Әткәң ята гаять мәгъмүм.
Китабәтләр кыйлам – мәгълүм,
        Догадин кыйлмаңыз мәхрүм!
Сезә яздым тәзкирә чөн,
Максуд-у-гарзым дога чөн,
Гафләттән интибаһ өчен,
        Зәгыйфе кыйлмаңыз мәхрүм!
Форсат хәлдә күреп күзем,
Сезә вәгазь яздым үзем,
Күрмәссез мәгъкуль сез сүзем,
        Укырсыз, мән китеп[2], мәхрүм.
Халә әхвәлем язмасам,
Хәяттә игълам кыйлмасам,
Кабердә ятарам әбсәм[3],
        Кәлямемнән улып мәхрүм.
Имкян улмаз күрешергә,
Рөхсәт улмас тәкәллемгә,
Хәтта улмаз[4] ишетергә –
        Ятарам барындин мәхрүм.
Бөйлә яздым кыйлып хисап,
Догага улыр дип сәбәп.
Зәгыйфе кыйлмаңызлар сәб,
        Язам сездән улып мәхрүм.

---

[1] Бу текстлар Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «987т» шифры белән саклана торган шигъри җыентыктан кыскартылып, 4а–8б, 10а, 12а, 12б, 14а, 14б, 16б–18а, 34б–35б, 37а, 39а–40а, 61а–63а, 69а–70а кәгазьләреннән алынды.

[2] Кульъязмада бу сүзнең өстендә «дөньядан» дип искәртелгән.

[3] Бу юлның өстендә мәгънәсе – «телсез» дип язылган.

[4] Бу сүзнең өстендә «имкян» (мөмкинлек) дип искәртелгән.

Нәчек өзмәм өмидемни[5],
Таба алмыйм сихәтемни,
Шуның чөн яздым «Иказ»ни –
        Әүлядә тәзкирәм мәгълүм.
Үзем сәламәт улмагач,
Хәятымнан өмид өзгәч,
Сезә яздым кәлям бер кач –
        Догадин кыйлмагыл мәхрүм!
Сагынырам барыңызни,
Күрәлмам һәрбереңезни,
Өмид кыйлып догаңызни,
        Гозерем – кыйлмаңыз мәхрүм!
Нәчек кыйлмам моны тараз?
Ятам гаҗиз, күреп мәраз,
Фаразымнан мәнем гараз
        Догадин кыйлмаңыз мәхрүм!
Әткәң күреп, укып ята,
«Вә әхсиб нәфсәкә минәл-мәүтә»[6]
«Вә ма тәдри ма исмикә гадән»[7]
        Булып[8] ихсан, бөйлә мәхрүм.
Гыйбадәтсез гомер мөрүр,
Нәчек улурам мән сөрүр?
«Вәгуддә нәфсәкә мин әһлил-кобур»[9]
        Гафил калып, ятам мәхрүм.
Әҗәл кәлеп кыйлыр мәгъдүм,
Кайчан кәлер – дәгел мәгълүм.
Нәчек улмам ятып мәгъмүм?
        Зәгыйфе кыйлмаңыз мәхрүм!

---

[5] Бу юлның өстендә «хәяттан» (яшәүдән) дип искәртелгән.

[6] Хәдистән алынган бу гыйбарәнең өстендә мәгънәсе – «Хисап кыйл үзеңне үлекләрдән» дип язылган.

[7] Бу юлның өстендә мәгънәсе – «Белмәзсән нидер исемең таңда» (белмәзсән – белмәссең) дип, Коръәннең «Локман» сүрәсендәге 34 нче аятьтән бераз үзгәртеп язылган.

[8] Бу сүзнең өстендә «мәет йә хәй» (хәй – тере) дип искәртелгән.

[9] Хәдистән алынган бу гыйбарәнең өстендә мәгънәсе – «Саясән үзеңне кабер әһелләреннән» (саясән – сана) дип язылган.

Бу язудан мәнем максуд –
Догаңызлә кыйлыңыз сүд,
Сүдеңездән улырам сүд,
    Бу сүддән кыйлмаңыз мәхрүм!
Үземне әмваттан сайып,
Лаек мәңгә олы тайиб,
Фөҗьәт мәүт кәлер диеп,
    Калырам тәүбәсез мәхрүм.
Һиҗрәт кыйлам, улып мәхрүм,
Догасыз кыйлмагыл мәхрүм.
Мәхрүм кыйлсаң, үзең мәхрүм,
    Онытып кыйлмагыл мәхрүм.
Мәңгә сез кыйлыңыз рәхим,
Хода кыйлсын сезә рәхим,
Рәхим кыйлсаң, сезә – рәхим,
    Рәхимнән кыйлмаңыз мәхрүм.
Даим сездән кыйлып риҗа –
Онытып кыйлмасаң дога,
Нәчек сезе диям «бала»?
    Әткәңне кыйлмагыл мәхрүм!
Укыңыз рухыма Коръән,
Риза булыр сезә Рахман,
Сезә рәхмән, безә Рахман,
    Рахманым, кыйлмагыл[10] мәхрүм!
Китәрәм мән сезе куеп,
Кабаих әфгале кыйлып.
Үзеңсән Галләмел-гоюб,
    Рәхим кыйл, әйләмә мәхрүм!
Килепмән әгъмаль кыйлмага,
Нә хаҗат – җөмлә алмага,
Гокбамны мәгъмүр кыйлмага,
    Гафил ятып калам мәхрүм.
Мәңгә сез кыйлсаңыз шәфкать,
Хода сезә кыйлыр рәхмәт.
Рәхим кыйлып, вирер җәннәт,
    Әткәңне кыйлмаңыз мәхрүм!

[10] Бу сүзнең өстендә «рәхмәтеңнән» дип искәртелгән.

Җәмигъ әфгаль мәнем гыйсъян,
Кыйлыпмән кайсысын касдән[11],
Садир һәм бәгъзесе нисьян,
        Рәхмәтдин кыйлмагыл мәхрүм!
Рәхимем, кыйлмагыл газап,
Кадир кыйл, вир мәңа җавап,
Зәгыйфькә ачкыл рәхмәт баб,
        Җәннәтдин кыйлмагыл мәхрүм!
Рия һәп кыйлдыгым әгъмал,
Һаман кыйлдым туле әмәл.
Бу гафләттә кәлеп әҗәл,
        Имандин кыйлмагыл мәхрүм!



*«Иказел-әүляд» кулъязмасы*

[11] Бу сүзнең өстендә «гамдән» (белә торып) дип язылган.

Садир һәп мәгасый чиксез,
Кыйлыпмән җөмләсен шиксез,
Китәрсәм нагяһ тәүбәсез,
Гафу кыйлмаса – мән мәхрүм.
Нә кыйлсам дәю мән хәсәнат,
Рия һәп вә һәм ноксанат,
Кәз(е)бең анда мөфсидәт
Рәхимем, кыйлмагыл мәхрүм!
Лаек әгъмале кыйлмадым,
Риядан хали улмадым,
Әгъмаль дәю мән инандым,
Әҗердин кыйлмагыл мәхрүм!
Әткәң тик улмаңыз, кызлар,
Күреп, гыйбрәт алыңызлар,
Әнваг тагать кыйлыңызлар!
Әткәңез ятадыр мәхрүм.
Әгъмаль дип иттикә кыйлмыйм[12],
Мәнаһиләр[13] куя алмыйм,
Рәхмәтдин өмидем кисмим[14],
Рәхимем әйләмәс мәхрүм.
Ходадин сораңыз тәүфыйк,
Әгъмалеңез улыр рәфикъ,
Мәнем тик улмаңыз тәхкыйк!
Калыпмән әгъмальдин мәхрүм...
Мәгълүм дәгел кәлер рәнҗү[15],
Нәчек сабрың алса сәнчү,
Имкян улмаз дәергә «чү» –
Ятарсән сихәтдин мәхрүм.
Нәваһи кыйлмаңыз, зинһар,
Әвамир кыйл ләйл-ү-нәһар,

[12] «Иттикә кыйлмыйм» сүзтезмәсе өстендә мәгънәсе – «таянмыйм» дип искәртелгән.
[13] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «кабаих әфгале» (яман эшләрне) дип язылган.
[14] Бу юлның өстендә «Лә тәкънәтү мин рәхмәти Аллаһи, дәю» дип язылган (Коръәннең «Зүмәр» сүрәсендәге 53 нче аять, мәгънәсе: «Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез»; дәю – дип).
[15] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «мәрыз» (сырхау) дип искәртелгән.

Мәнем тик кыйлмаңыз фәххар[16]!
    Әгъмальдин кыйлмагыл мәхрүм!
Гыйбадәт кыйлың ихласлә,
Рия-ү-көбердән хәляслә,
Хошугыйлә, хозугыйлә!
    Мәнем тик улмагыл[17] мәхрүм.
Кабул улып[18] әгъмалеңез,
Нурани улып йөзеңез[19],
Җәннәте кыйлыр мәэваңез[20].
    Әткәңне кыйлмагыл мәхрүм!
Заигъ кыйлма гомереңни,
Фикер кыйлгыл гобуреңни,
Кәзалик бел кобуреңни,
    Ятарсән әгъмальдин мәхрүм.
Сезнең һәм гомреңез үтәр[21],
Сихәтлекләреңез китәр,
Фөҗьәтлә әҗәл җитәр –
    Әгъмальдин улырсыз мәхрүм.
Кәлмәке улмагач мәгълүм,
Кәлер мәүт, бәлки, бу йаум.
Уйган, калма гафләт нәүм,
    Әгъмальдин калмагыл мәхрүм!
Сабаха керер ирсәңез,
Фәлән вафат дәю иштәсез,
Фөҗьәт[22] кәлер, үкенерсез,
    Тайиб улмай, калып мәхрүм.
Вакыйг һәм улыр нәдамәт,
Кыйлсамчы дәю гыйбадәт,
Гыйбадәтә кыйлың гадәт,
    Фикер кыйл, калмагыл мәхрүм!

[16] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «мактанучы» дип язылган.
[17] Бу сүзнең өстендә «гыйбадәтсез» дип искәртелгән.
[18] Бу сүзнең өстендә «хәер» дип искәртелгән.
[19] Бу юлның өстендә «кыяматтә» дип искәртелгән.
[20] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «инәчәк урыныңыз» дип язылган.
[21] Бу юлның өстендә «тиз үк» дип искәртелгән.
[22] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «тизлек үзрә» (тизлек белән, кинәт) дип язылган.

Сезе алдамасын дөнья,
Фикер кыйлың даим гокба,
Насыйп кыйл һидаять, Хода!
    Вә иллә улырмыз мәгъмүм.
Гыйбадәтлә улың даим,
Ләялләрдә улың каим,
Рамазанда улың саим –
    Нәвафилдән калма мәхрүм.
Ходадин сора һидаять,
Кыйлыңыз әнваг гыйбадәт,
Алыңыз әгъля дәрәҗат –
    Савапдин калмагыл мәхрүм.
Гафил улма, кәлер әҗәл[23],
Тәрк кыйлгыл туле әмәл,
Даим кыйлгыл хәер әгъмаль!
    Мәнем тик улмагыл мәхрүм[24].
Әткәңез ята әгъмальсез,
Кыйлыңыз ярдәм, әүляд, сез[25]!
Вә иллә мәхрүм куйсаң сез,
    Әткәң мескен, ятар мәхрүм[26].
Нә кыйлдың, кәлсә бу әхвәл[27]?
Кичкә һәм калмас ихтимал,
Әҗәл кәлсә, улмас мәҗал –
    Тәүбәсез китәрсәз мәхрүм.
Гомерең кыйлса гәр фәүт[28],
Кәлеп йитсә сәнгә мәүт,
Ирешер һәркемгә нәүбәт –
    Барындин улурсән мәхрүм.

[23] Бу юлның өстендә «Лә йәстәэхирунә сагатән вә лә йәстәкъдимунә» дип язылган (Коръәннең «Әл-Әгъраф» сүрәсендәге 34 нче аятьтән, мәгънәсе: «Аны бер сәгатькә генә артка да, алга да күчерә алмаслар»).
[24] Бу юлның өстендә «гыйбадәтсез» дип искәртелгән.
[25] Бу юлның өстендә «әткәңезә дога-тәсаддыкълә» (әткәгезгә дога-сәдака белән) дип искәртелгән.
[26] Бу юлның өстендә «каберендә» дип искәртелгән.
[27] Бу сүзнең өстендә «мәүт» (үлем) дип искәртелгән.
[28] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «үтсә» дип язылган.

«Иказ»ымы укыңызлар,
Гоюбеме кичеңезләр,
Рухымы шат кыйлыңызлар,
        Догадин кыйлмагыл мәхрүм.
Нигъмәтулла ирер исмем,
Зәгыйфь, гаҗиз ята җисмем,
Ходадин улдыкы кыйсьмем,
        Сихәтдин кыйлмагыл мәхрүм.

***

Фирашымда истилка
Ятам мәриз, юк лика,
Әбъятым улсын бәка,
        Сезләрә яздым ихлас.
Тавил улды әмразым,
Язуымнан гаразым,
Догаңыздыр фаразым,
        Кыйлыңыз дога ихлас!
«Иказ»[29] яздым иртә-кич,
Гайреләрә дәгел һич[30],
Укыянлар гаебем кич!
        Риҗамдыр сезә ихлас.
Биначар тоттым каләм,
Яздым әбъятым-кәлям[31],
Вә һәм әүлядә сәлам
        Әткәңнән сезә ихлас.
Кыйлмаңызлар мәлямәт,
Шәтем кыйлма кабахәт,
Гафу кыйл – җанга рәхәт!
        Гоюбемнән кыйл хәляс.
Ултыралмыйм, торалмыйм,
Кырынлап һәм яталмыйм[32],

---

[29] Бу сүзнең өстендә «китабымы» дип язылган.
[30] Бу юлның өстендә «мәгәр әүлядыма» (балаларыма) диелгән.
[31] Бу сүзнең өстендә «сезләрә» дип искәртелгән.
[32] Бу юлның өстендә «халә уң тарафа ятам» (хәзер уң ягыма ятам) дип искәртелгән.

Гакыйбәтен белалмыйм...
        Раббым, үзең кыйл хәляс!

***

Халә яхшы ятамән[33],
Кырынлый да аламән[34],
Бәгъзе кяре кыйламән –
        Язамын, укыйм ихлас.
Хаҗәт дәгелде[35] язу,
Әхвәлем бәян кыйлу,
Җәзәгъ-фәзәгъ һәм булу
        Тапмасам да гәр хәляс.
Максуд[36] дәгел шикаять,
Вокугындан хикәят[37],
Хәвеф кыйлам бигаять.
        Шикаятьтән кыйл[38] хәляс!
Сезгә[39] җөмлә сүзләрем,
«Иказ»ымда[40], әүлядым!
Гайрә дәгел кәлямем,
        Әбъят яздым сезә хас.
Максуд мәнем язудан,
Бөйлә нәзым кыйлудан,
Даим рижам догадан –
        Дога кыйлыңыз ихлас!
«Иказ» яздым бөйлә,
Гозер-ниязым илә,
Дога кыйлың шәфкатьлә,
        Зәгыйфь руха сез ихлас.

---

[33] Бу юлның өстендә «әлхәмделилләһи» (Аллаһыга дан) дип искәртелгән.
[34] Бу юлның өстендә «уң тарафка» дип өстәлгән.
[35] Бу сүзнең өстендә «бөйлә» (болай) дип искәртелгән.
[36] Бу сүзнең өстендә «язудан» диелгән.
[37] Бу юлның өстендә «кыйлам» дип искәртелгән.
[38] Бу сүзнең өстендә «йа, Раббым» дип өстәлгән.
[39] Бу сүзнең өстендә «язган» дип искәртелгән.
[40] Бу сүзнең өстендә «китабымда» дип искәртелгән.

Әбелфатихдер кятиб,
Дога риҗасы[41] галиб,
Онытмаңыз, әкариб,
        Зәгыйфькә кыйлыңыз хас[42]!

***

Әүлядым, сезләр,
Укыңыз[43] сүзләр,
Кәлермез безләр[44],
        Кыйлың морагать.
Онытма[45] әмват,
Безләре, бәнат,
Кыйлың сәдакат[46],
        Һәм укып айат!
Каулемә[47] бак син,
Әмватлар мескин[48],
Кыйлыңыз тәскин[49]
        Укубән айат[50].
Өмидлә[51] нәзым[52]
Тәзкирә куйдым[53],
Укың, әүлядым[54],
        Әткәңә айат!
Назыйм максуды
Вә һәм гозере –

[41] Бу сүзнең өстендә «сездән» дип искәртелгән.
[42] Бу юлның өстендә «догаңызны» дип язылган.
[43] Бу юлның өстендә «яздыкым» (мин язган) дип искәртелгән.
[44] Бу юлның өстендә «сезләрә өмидлә» (сезгә өмет белән) диелгән.
[45] Бу сүзнең өстендә «әүлядым» дип искәртелгән.
[46] Бу юлның өстендә «рухларымыза» (рухларыбызга) дип язылган.
[47] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «сүземә» диелгән.
[48] Бу юлның өстендә «гаять» дип искәртелгән.
[49] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «шат кыйлып» дип теркәлгән.
[50] Бу юлның өстендә «рухларына» дип искәртелгән.
[51] Бу сүзнең өстендә «дога» диелгән.
[52] Бу сүзнең өстендә «кыйлдым» дип язылган.
[53] Бу юлның өстендә «сезләрә» дип искәртелгән.
[54] Бу юлның өстендә «китабымы» диелгән.

Доганыз хәйре
Бу шәриф әүкат.
Әбъят назыймы,
Әбелфатихы,
Мәгълүм һәм намы –
Зәгыйфь ул гаять.
Алла нигъмәти,
Язды әбъяти,
Гозер-хаҗати,
Доганыз гаять.
Йиденче җылым[55]
Зәгыйфь калмакым[56],
Әбъятым куйдым
Кыйлып китабәт.

***

Салып фазл-у-гыйнаятең, Илаһым,
Бу зәгыйфе гафу кыйлгыл, пәнаһым!
Кабахәт җөрм-ү-гыйсъянлә мөбтәляем,
Тәҗавез кыйл, Раббым, дәю ялвараем[57].
Сәгать бә-сәгать садир булган зөнубем,
Тәмам мәмлү җиһан әнваг гоюбем.
Сәвекле Хәбиб хөрмәтенә кәрәм кыйл[58],
Зөнубләрем гафу кыйлып, гадәм кыйл[59]!
Әгәр сән кичмәсәң һәрнә зөнубем,
Кемә ялварам? Юк гайре гафурым[60].
Гафу кыйлмасаң, кем кичәр гөнаһи[61]?
Зәгыйфьнең һич имәс гайре пәнаһи[62].

[55] Бу юлның өстендә «нәзым кыйлдыкыма» дип искәртелгән.
[56] Бу юлның өстендә «ятмакыма халә унтукызынчы җыл» (халә – хәзер) дип язылган.
[57] Бу юлның өстендә «үзеңә» диелгән.
[58] Бу юлның өстендә «Йа, Раббым» дип искәртелгән.
[59] Бу юлның өстендә «дәфтәремнән» дип язылган.
[60] Бу сүзнең өстендә «сәндән гайре» диелгән.
[61] Бу сүзнең өстендә «зәгыйфьнең» (ягъни, авторның) дип искәртелгән.
[62] Бу юлның өстендә «сәндән гайре таянычы» дип язылган.

Әгъмаль дәю кыйлыпмән әнваг әшрар,
Гафу кыйл хөрмәтә әбрар вә әхъяр!
    Кәрәм кыйл хөрмәтә Рәсүлең мохтар,
    Рәхим кыйл, каһреңә кыйлма дучар!
Зөнубем ирерсән Саттар вә Гаффар,
Сәтер кыйл, каһрә кыйлма грифтар!
    Мөнәҗәте зәгыйфьнең руйи сияһ,
    Кабул кыйл хөрмәтенә Хәбибең[63] җаһ?!
Риҗасы гасый колың Нигъмәтулла,
Дидең сән: «Лә тәкънәтү мин рәхмәтулла».

***

Дидем сезә мән, кызлар
Бу кәлямем вәгазь өчен,
Кыйлдым сезә тәнбиһләр
    Гафләттән интибаһ өчен.
Бераз игътибар кыйлыңыз,
Кәлямем фикер идеңез,
Догаңыздин онытмаңыз,
    Сезә яздым вәгазь өчен.
«Иказ»ым сезә, кызларым,
Укыңыз ошбу сүзләрем,
Сезә кыйлган вәгазьләрем,
    Камил шәфкатем булганчөн.
Бу мордар дөньяда мәсрүр,
Улубән, кыйлмагыл горур,
Гыйбадәт кыйлың гоюр!
    Нә кыйлсаң – үзеңез өчен.
Ирер карчык хәсис җифә,
Күстәрә үзен гафифә.
Котылмак мәкерендин кәйфә
    Үземезне фәлях өчен.
Кәлүдән максуд дөньяга
Коллык кыйлмак чөн Аллага[64],

[63] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «сәвекле» (сөекле) диелгән.
[64] Бу юлның өстендә «Фә-әдгу Аллаһә мохлисинә, – диде» дип язылган (Коръәннең «Гафир» сүрәсендәге 14 нче аятьтән, мәгънәсе: «Ихлас белән Аллаһка гыйбадәт итегез»).

Ходаның колы булмага
Әвамирә имтисаль өчен[65].
Кыйлыр ирсәң гыйбадәтни,
Тәркилә сәйеатларыни,
Кыйлынмас сәб бу дөньяни,
Гыйбадәт кыйлганың өчен.
Хода кыйлды сезә гыйззәт,
Караңыз сез, алып гыйбрәт,
Гыйбадәт кыйлыңыз, әлбәт,
Җәмигъ хәлдә Хода өчен.
Мөкәррәм кыйлды инсанни,
Мәдехлә Коръәндә ани,
Белеңез аның кадрени,
Халикъ кыйлмыш гыйбадәтчөн[66].
Кыйлмады безе эт-дуңгыз,
Кәзалик сөббагъ[67] һәм кондыз,
Иманы вирде, белеңез –
Һидаять вирде рәхмәтчөн.
Кәленмәде бу дөньяга,
Җыеп мал, гасый улмага.
Мәгәр гыйбадәт кыйлмага,
Кәлмәкемез әгъмаль өчен.
Әвамир кабул кыйлмасаң,
Нәваһи тәрек кыйлмасаң,
Дәелерме сәнгә инсан,
Хайвандин фәркъ юк өчен?
Җәмигъ мәхлуклар тәсбихтә[68],
Бәян кыйлды кәлямендә,

[65] Бу юлның өстендә «фәраизы кыйлып, нәваһидән иҗтинаб өчен» (фарызларны үтәп, тыелганнардан саклану өчен) дип искәртелгән.
[66] Бу юлның өстендә «Вә ма хәләкътү әл-җиннә вәл-инсә иллә ли-йәгъбүдуни» дип язылган (Коръәннең «Әз-Зарият» сүрәсендәге 56 нче аять, мәгънәсе: «Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яралттым»).
[67] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «җырткучы хайван» (ерткыч) дип искәртелгән.
[68] Бу юлның өстендә «Вә ин мин шәйин иллә йүсәббиху би-хәмдиһи вә ләкиннә лә йәфкаһунә тәсбихәһүм, иләх» дип язылган (Коръәннең «Әл-Исра» сүрәсендәге 44 нче аятьтән, мәгънәсе: «Аны мактау белән мактамаган һичбер нәрсә юк, ләкин сез аларның тәсбихләрен аңламыйсыз»).

Бересе дәгел гафләттә,
	Дия тәсбих Хода өчен.
Кыйлып ихсан, сәне инсан[69],
Вирде ислам, дәхи иман[70].
Фәраизлар хәмел кыйлган,
	Мәгасыйлар тәрек өчен.
Бу дөнья фани әмвале,
Барының булыр сөале,
Калыр бакый кыйлан әгъмале...
	Әгъмаль кыйлыйк бәка өчен.
Вафасы юк бу дөньяның,
Әмвале дәхи җаһының,
Мәгәр файдасы әгъмальнең
	Кыйлынган халис Лилләһчөн.
Нәчек күп кемсә алданды,
Җәмигъ кыйлып һәлак улды,
Бу нәүбәтләр сезә калды.
	Һәлак йә нәҗат улмакчөн.
Вафа кыйлмас, җәфа кыйлыр,
Сафа кыйлмас, хафа кыйлыр.
Бәка кыйлмас, һәба кыйлыр
	Барысы безә җәфа өчен.
Әмвальләрен кыйлып әмляк[71],
Һаман касды кыйлу һәлак[72].
Кыйлыйк теләк[73], күтәр беләк
	Мәкерендин хәляс булмакчөн.

[69] «Ихсан» сүзенең өстендә «Хода» дип, «инсан» сүзе өстендә «адәм кыйлды» дип язылган.
[70] Бу юлның өстендә «һәм гакыл» дип өстәлгән.
[71] Бу юлның өстендә «безләрә» (безгә) дип искәртелгән.
[72] Бу юлның өстендә «безе» (безне) дип искәртелгән.
[73] Бу юлның өстендә «Ходага» диелгән.

**Әйдан**

Гыйззəттə идем,
Хөрмəттə идем,
Җаһа таяндым
        Һəм мəгъзул улдым.
Хəзрəте[74] идем,
Хəсрəте чиктем,
Бу əбъят яздым[75]
        Сезə – əүлядым.
Шатлыкта идем,
Мөəəббəд белдем,
Барын мəн куйдым...
        Мəхрүми булдым.
Һəм зəгыйфь калдым,
Хыял кыйлмадым[76],
Тəкъдире булдым,
        Халə мəн белдем...
Җаһа таяндым,
Мала куандым,
Каумə ышандым
        Һəм мəгъзул булдым.
Гаҗиз мəн калдым,
Мəнсəбе куйдым.
Сабрымы сордым,
        Рəхим кыйл, Раббым?!
Канигъ улмадым[77],
Тамгы куймадым,
Сəна[78] кыйлмадым,
        Көфраны кыйлдым.
Җөмлəсен куйдым,
Халə бик белдем –

---

[74] Бу сүзнең өстендə «кавемгə» (халыкка) дип язылган.
[75] Бу юлның өстендə «тəзкирə» (истəлек) дип искəртелгəн.
[76] Бу юлның өстендə «бөйлə улмакым» (болай булуымны) диелгəн.
[77] Бу юлның өстендə «барына» дип искəртелгəн.
[78] Бу сүзнең өстендə мəгънəсе – «хəмед» (мактау) дип язылган.

Мәхрүми улдым[79],
        Нәдамәт кыйлдым.
«Иказ»ым яздым[80],
Беленңез, кызым!
Догага[81] күзем
        Биначар[82] үзем.
Укып сүзләрем,
Көлмә, кызларым!
Кәбаб, бәгырем,
        Биззарур яздым.
Фикер кыйлмадым
Бөйлә калмакым.
Мәгълүм әхвәлем –
        Күрдең, әүлядым.
Ятып ялгызым
Әбъятым яздым.
Укың, әүлядым –
        Тәзкирәм куйдым.
Рижҗам әүлядым,
Сезә кәлямем[83],
Дога морадым[84],
        Кыйлың һәр йаум!
Кыйлып мән нәзым
Кәлям, «Иказ»ым,
Сезә вәгазем,
        Кыйлдым видагым[85].
Нигъмәтулла намым,
Белең, өхләрем,
Заһир кәлямем,
        Шат кыйлың рухым?!

---

[79] Бу юлның өстендә «барыннан» диелгән.
[80] Бу юлның өстендә «сезләрә хас» (хас – махсус, багышлап) дип искәртелгән.
[81] Бу сүзнең өстендә «өмидлә» (өмет белән) дип искәртелгән.
[82] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «гаҗиз» дип искәртелгән.
[83] Бу юлның өстендә «яздым» диелгән.
[84] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «максуд» (максат) дип теркәлгән.
[85] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «исәнләштем» дип язылган.

**Фил-җөмлә мариз хәлеме бәян**

Яздым сәтырә,
Төшеп хатерә,
Укың мәзкүрә
　　Җөмлә әүлядым.
Яздым эч пошып,
Гаять тырышып,
Хотурә төшеп
　　Рәнҗү әхвәлем.
Кыйлдым мән хыял,
Маразым әхвәл,
Дәюрдем әкъваль[86],
　　Җөмлә сагындым.
Азан әйтелә
Һәм ишетелә,
Варасым килә...
　　Ятам ялгызым.
Һәркем варалар,
Олуг-кечекләр,
Намаз укыйлар...
　　Мән мәхрүм улдым.
Яшьтән мәсҗидтә
Улдым мәҗлестә,
Барысы истә –
　　Гыйzзәт күрдекем[87]...
Улдым михрабта,
Вә һәм мәнсабта,
Ирдем вәгазьдә
　　Каумемә гомум.
Симагъ кыйлдылар,
Кабул кыйлдылар,
«Рәхмәт!» – диделәр
　　Җөмләсе каумем.

---

[86] Бу юлның өстендә «мариз хәлемдә» (мариз – авыру) дип искәртелгән.
[87] Бу юлның өстендә «гавамнан» (халыктан) диелгән.

Һич тора алмыйм,
Тәһарәт алмыйм,
Сугам тәяммем[88],
        Ятып укыдым[89].
Ишарә[90]дәвам,
Намазым кыйлам,
Ниязым риҗам,
        Кабул кыйл, Раббым?!
Өч җылым улды[91]
Күрмимен иле[92],
Ятамән егълый,
        Мәхрүми улдым.
Мәхрүм мәсҗидтән
Һәм мәҗалистән,
Мәхрүм җөлүстән,
        Хәсрәте чиктем.
Язды әткәңез,
Бәнат, белеңез
Һич онытмаңыз,
        «Иказ»ым куйдым.
Ятадыр җисмем[93],
Ходадин кыйсьмем[94],
Нигъмәтулла исмем,
        Газиз дустларым.
Нәзмым укыян,
[Газизем ихван][95],
Гозерем гаян.
        Дога өмидем.

[88] Бу юлның өстендә «заруратттән» дип искәртелгән.
[89] Бу юлның өстендә «ишарәлә» (ишарә белән) диелгән.
[90] Бу сүзнең өстендә «кыйлып» дип искәртелгән.
[91] Бу юлның өстендә «нәзым кыйлдыкыма» (иҗат итүемә) дип искәртелгән.
[92] Бу юлның өстендә «халә унтукызынчы ел ятам» дип һәм соңрак (шәмәхә кара белән) «халә 32 ел» дип язылган.
[93] Бу юлның өстендә «зәгыйфь» дип язылган.
[94] Бу сүзнең өстендә мәгънәсе – «насыйп» диелгән.
[95] Кульязманың бу урынында кәгазе ертылган.

# [ДОГА][1]

Гафу кыйлып бу гасыйни,
Кәзалик атам-анамни,
Әкъриба һәм әүлядымни,
Ярлыкагыл барысыни!

Газиз мөшфикъ остазымни,
Җәмигъ мөэмин-[мөэ]минатни,
[Ярлык]агыл җәмигыни,
Кәрәмеңлә барысыни!

Җәмигъ хәсәб-нәсәбемни,
Кәзалик әшнә-әхбабни,
Шат-у-хәррәм кыйл барыни,
Насыйп кыйлып рәхмәтеңни!

Кабул кыйлып хәсәнатни,
Гафу кыйлып сәйеатни,
Насыйп кыйл безә җәннәтни,
Кыйлып фазл-у-гыйнаятни!

Шафигъ кыйлып Рәсүлеңни,
Насыйп кыйл безә фазлыңни,
Вирең әгъля дәрәҗатни,
Мөяссәр кыйл дидарыңни!

Сәнгә кыйлдык әманәтни,
Дине ислам иманымни,
Кәзалик кыйлган әгъмальни,
Вәдигам сәнгә барыни.

Кыйла шәятыйн мәкерни,
Кыйлып әнваг вәсвәсәни,
Заигъ кыйлмакчөн иманни,
Хафизым, мәхфуз кыйл мәни?!

[1] Бу текстлар Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «6674т» шифры белән саклана торган җыентыкның 30а–32б кәгазьләреннән алынды.

Кыйламыз газыйм хәвефни,
Безә кыйлганчөн мәкерни,
Кыйлың мәкъһүр дошманыңни,
Иманлә үткәреп безни!
Кыйлып Раббым игътимадни,
Вәдига кыйлдык иманни,
Мәхфуз кыйл, Кадир Сөбхани,
Кыйлып шәфкате рәхмәтни!
Мәсрүр кыйлма бу шайтани,
Мәкренә вирмә сәбилни,
Кыйлың мәрдүд ул мәлгуньни,
Безә кыйл фазл-у-кәрамни!
Мөстәҗаб кыйл догамызни,
Виреп максудларымызни,
Мөяссәр кыйлгыл ризаңни,
Кыйлып рәхмәт гыйнаятни?!

## [КЫЙЛА КҮРГЕЛ ДОГАҢЫЗНЫ!]

Нәсаихем кәлямемни,
Тәмам кыйлдым китабәтни,
Үтенәмән догаңызни –
Кыйла күргел догаңызни!
Укыса балалар мони,
Риҗам анлар догасыни,
Тапсалар иде нәфгыни,
Кыйла күргел догаңызни!
Сезә дә вирсен нәфгыни,
Мәнгә һәм вирсен әҗрени,
Риҗалә[2] яздым китапни,
Зинһар, кыйлың догаңызни!
Кабул кыйлып догаңызни,
Гафу кыйлыр гөнаһымни,
Насыйп кыйлыр ризасыни,
Кыйла күргел догаңызни!

---

[2] Бу сүзнең өстендә «өмидлә» (өмет белән) дигән мәгънәсе язылган.

Гафу кыйлып сези-безни,
Салып фазл-у-кәрамени,
Насыйп кыйлсын җәннәтени,
Кыйла күргел догаңызни!
    Каләм, кара, кәгаземни,
    Истилка хәл яздым мони,
    Риҗам камил догаңызни –
    Кыйла күргел догаңызни!
Гафу кыйлып гоюбемни,
Төзек кыйлың китабымни,
Мәлямәт кыйлма зәгыйфьни –
Кыйла күргел догаңызни!
    Укып сезләр бу китапны,
    Догалә шат кыйл рухымны,
    Үтенәмән сездән аны,
    Кыйла күргел догаңызны?!
Мөшкел чалкан язу мони,
Төшереп булмый карани,
Пычратадыр бармакымни,
Кыйла күргел догаңызни!
    Ятубән сезләр чалканый,
    Язып караңыз язуни,
    Белерсез нәчек булгани.
    Кыйла күргел догаңызни!
Гаеп итмәң кәлямемни
Язган дип безә юк сүзни,
Сезә кыйлам гозеремни –
Кыйла күргел догаңызни!
    Сезә һәм кыйлам догамни,
    Вирсен җөмлә мәкасыйдни,
    Ярлыкасын барыңызни,
    Кыйла күргел догаңызни!
Онытмаңыз бу зәгыйфьни,
Кыйлыңыз шат бу рухымни!
Кабул кыйлып гозеремни,
Кыйла күргел догаңызни!

Кыйлып сезә сәламемни
Тәмам кыйлдым китабымни.
Үтенәм һәм догаңызни –
Кыйла күргел догаңызни!
Сәдакаи җариямни,
Язып куйдым сезә мони.
Тәрәххем кыйлып зәгыйфьни,
Кыйла күргел догаңызни!

***

Миладия тарих мең тукыз
Тукызы сәнә дәю укыңыз,
Април уны белеңез,
Бу китап нәкыль улмышни.

# КУЛЪЯЗМАЛАР ТАСВИРЛАМАСЫ

(1–8 нче саннар белән билгеләнгәннәре Татарстан Республикасы Милли китапханәсе Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, 9 нчы санлысы авторның туганнарында саклана)

**1. «Кадер кичәсе»**

Китапханәдә «3589т» шифры белән саклана торган бу кулъязма Россиядә XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән, 17х21,5 см. зурлыгындагы 10 кәгазьдән тора.

Катыргы тышлыгының читләренә кара төстәге тукыма ябыштырылган булган, түбе ак төстәге юан тегәрҗеп белән тегелеп, кызыл тукыма куеп төпләнгән. Форзацларына XX гасыр башында Казанда нәшер ителгән «Кояш» газетасы битләренең аерым өлешләре ябыштырылган. 3 нче кәгазьнең түбәнге ягы шул ук газета кисәген ябыштырып реставрацияләнгән булган.

Сакланышы начар: кәгазь читләре бик таушалган, ерткаланган һәм тузган. Кайберләре бер-берсенә ябышып зарарланган, тишкәләнгән. Язулары өлешчә һәм авырдан танылa. Тышлыгы төбеннән аерылып чыккан диярлек.

Кустодлары бар. Автор тарафыннан бит читләренә язылган пагинациянең 8–11, 13–14, 26, 33–39 саннары күренә.

Текстлар караңгы көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән.

Әсәр текстының башы һәм ахыры юк. Ахырындагы бер-ике кәгазе төшкән булса кирәк.

Кулъязманың тексты хәрәкәләр кулланып язылган. Өстәмәләр һәм төзәтмәләр, аерым сүзләргә юл араларында аңлатмалары теркәлгән. 10а кәгазьдәге 12 строфа автор тарафыннан сызылган, шул ук юллар 10б кәгазьдә кабатланган.

Бу кулъязмада Нигъмәтулла Солтанбәковның «Кадер кичә-се»нә багышланган күләмле тезмә әсәренең тексты теркәлгән.



*«Кадер кичәсе» кулъязмасы*

Строфаларның күбесендә «Кадер кичәсе» сүзтезмәсе рефрен булып кабатланган.

Текстының башы (1а кәгазьдә):

... сәламе,
Вирер мөзәйян хөллә савабы,
Улыр җәннәттә мәкяне,
Бөйләдер Кадер кичәсе.

Ахыры (10б кәгазьдә):

Назыйме намы Нигъмәтулла,
Риза булгай иде Алла,
Язды сезә халисән Лилләһ,
Нәзымлә әбъят барчасы.

Шул ук 10б кәгазендә:

Түртүнче ел ятам истилка
Бу әбъятым сезә бәка.
Сәбәп дип рәхмәте лика
Кадер кичә тәрҗемәсе,

– дип язылган. Авторның 1891 елдан авыру хәлдә калганлыгын истә тотканда, әлеге әсәр 1895 елда иҗат ителгән булып чыга. Бу кулъязма нөсхәсе исә XX гасыр башында күчерелеп төпләнгән.

Солтанбәков әлеге әсәрен хатын-кызларга – абыстайларга багышлаган дип аңлашыла, чөнки текстында «абыстайлар, кыйлың фикер», «ишетеңез, абыстайлар» кебек мөрәҗәгать сүзләре еш кабатланган. Шулай ук ул бу әсәрен «Кыйлдым беразы тәрҗемә» дип һәм

Нәзар кыйлдым китаплара,
Тәрҗемә кыйлдым нисаларга,

– дип тә искәрткән.

Әсәр сәнгати яктан нәфис. Мәсәлән, анда түбәндәгечә эчке рифмалар да бар:

Безә рәхмәт, безә дәүләт,
Безә носрәт, безә восләт,
Безә гыйззәт, безә хөрмәт,
Безә бу Кадер кичәсе.

Әлеге кулъязма китапханәгә 2019 елның июль аенда Мамадыш районы Яңа Комазан авылының Инсаф Габделхәевтән алынган.

**2. «Мәүлиде Рәсүлулла»**

Китапханәдә «2687т» шифры белән саклана торган бу кулъязма китап Россиядә XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән, 17x21,5 см. зурлыгындагы 66 кәгазьдән гыйбарәт.

Катыргы тышлыгының читләренә кызыл төстәге тукыма, өслегенә исә бизәкле кәгазь (обой) ябыштырылган. XX гасыр башында Казанда нәшер ителгән «Йолдыз» газетасының аерым өлешләре форзац битләре рәвешендә ябыштырылган.

Сакланышы уртача: тышлыгы элегрәк аерылып чыкканнан соң төбенә ак төстәге юан тегәрҗеп белән тегеп куелган, 1а кәгазе төбе ягыннан яртылаш ертылган. 37а кәгазе төбеннән аерыл-

ган. Кулъязма дымлану кичергәнлектән, кәгазьләренең читләре бераз саргайган. Төп тексттан тыш, соңрак башка кешеләр кулы белән язылган һәм балалар тарафыннан сызылган урыннары бар (мәсәлән, 1а, 27а, 32а, 45а, 51а һ.б. кәгазьләр). Аларның кайберләре кыска җырлар һәм мөнәҗәт юллары.

Һәр кәгазьдә кустодлары тотрыклы куелган. Автор тарафыннан һәр битнең өстендә, уртада пагинация теркәлгән. 37б кәгазьдә өч строфа язылганнан соң автор тарафыннан сызылган.

Текстлар көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. Бу кулъязмадагы барлык текстлар да хәрәкәләр кулланып язылган.

Кайбер битләрдә автор өстәмәләре һәм төзәтмәләре, кыскача аңлатмалары язылган.

Әсәр текстының башы бар, ахырындагы берничә кәгазе төшеп югалган.

Бу кулъязмадагы әсәрен авторы – Нигъмәтулла Солтанбәков «Мәүлиде Рәсүлулла» дип атаган һәм ул аерым рәвештәге тезмә-шигъри һәм чәчмә өлешләрдән тора.

Текстның башы (1б кәгазьдә):

Башлаем мән бу китабы
Гыйнаять кыйлса Аллаһы,
Бәян кыйлам иҗмалән
Мәүлиде Рәсүлуллаһы.

Ахыры (66б кәгазьдә):

Рәсүл әйде Госмангә: «Сән, и, яр!
Ибраһимны юубән, тунларын сар!»

Әсәрнең төп өлеше шигъри калыпта һәм аерым урыннарында (3б, 6а, 29б–30б, 41а–41б, 45б–63а кәгазьләрдә) чәчмә текст белән аралашкан. Чәчмәләрнең күпчелеге «Алты бармак» китабыннан күчерелгән, шулай ук Коръәннән һәм «Шәрхе Кара Даут әфәнде» исемле китаптан өземтәләр бирелгән. Шунлыктан, шактый гына шигъри өлгеләре «Диям дәхи риваятьтән», «Диелде дәхи риваять», «Бәян кыйлаем риваятьтән», «Китапларда язылмыш», «Китапларда күрелде» кебек башламнардан гыйбарәт.

Тезмә рәвештәге текстлар төрлечә шигъри үлчәмнәргә салып язылган. Бу яктан әсәр XV гасыр әдибе Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабын хәтерләтә. Шигъри-тезмә текстлар кәгазь битләрендә икешәр һәм дүртәр багана рәвешендә язылган.

Шигъри өлешләрендә автор борынгы төрки-татар әдипләре традициясен дәвам итеп, әсәр тексты эченә үзенә мөрәҗәгать итү рәвешендә һәм исемен белдереп тә язган. Мәсәлән, «Җаһил Нигъмәтулла ал гыйбрәт» (5б кәгазь), «Зәгыйфь Нигъмәтулла гафил» (16б кәгазь) дигән, 3а кәгазьдә исә «Зәгыйфь, сән дә бел кадреме» дигән. Юл арасында «Мәүлидне» (ягъни, Мәүлиднең кадерен) дип искәрткән.

Нигъмәтулла хәзрәт үзенең шушы әсәрен кызларына атап язганлыгын берничә урында белдергән һәм кабатлаган. Мәсәлән (4б кәгазьдә):

И, газиз кызларым,
Укыңыз нәзымнарым!
Сезә хас кыйлып яздым
Мәүлиден Рәсүлулла.

Шулай ук автор «Ишеттеңме, кызларым» (23а кәгазь), «Кызларым, сез укыңыз бу кыйссаны...» (43б кәгазь) дип тә мөрәҗәгать иткән.

Җыентыкның 38б–40б кәгазьләрендә автор үзенең зәгыйфь хәлдә ятуын да тасвирлап үткән.

Кульязманың ике урынында шушы «Мәүлид» җыентыгының күчерелгән датасы белдерелгән. 36б кәгазьдә:

Миладия тарих мең дә
Тукыз йөз тукыз елда
Июльнең унтукызында
Нәкыль кыйлдым галәл-фираш.

Шундагы ук тезмә юлларда дата һиҗри буенча «1327 елның 14 нче рәҗәп көне»ндә «кызларыма мәнкуль фаш» (күчерелде) диелгән.

Кульязманың 40б кәгазендә:

Тарих мең дә
Һәм тукыз йөздә
Тукызынчы елда
Мәнкуль әбъятым.
Июль унтукызынчы,
Якшәнбә киче,
Зәгыйфь кятибче
Мәгълүмем куйдым.

– рәвешендә шул ук дата теркәлгән.



*«Мәүлид» җыентыгындагы мәчет рәсеме*

41б кәгазьдә дәвам итеп:
Тарихе һиҗрия
Һәм мең өч йөздә
Егерме йидедә
Сәнәдә күчердем.
Маһе рәҗәптә
Һәм үндүртендә,
Якшәнбә көндә,
Тәмам кыйлмакым,

– юллары язылган.

Автор күрсәткән дата әсәрнең күчереп язылган вакытын белдергән. Иҗат ителүе исә 1891–1899 еллар арасында булгандыр.

Кульъязманың 17а кәгазендә ике манаралы, уртасында зур һәм аның ике ягында кечерәк ике (барлыгы өч) гөмбәзле мәһабәт мәчет бинасының рәсеме ясалган. Аның манаралары Төркия мәчетләренә охшатылган. Бу рәсемне Нигъмәтулла мулла кемнәндер ясаткан, күрәсең.

Кульъязманың 4а кәгазендә гади карандаш белән «Ошбу китап иясе Нурелфаат» дип теркәлгән. Нигъмәтулла Солтанбәков төзегән шәҗәрәдә аның Нурелфуад исемле улы да язылган. Җыентыкның 54б–55а кәгазьләрендә башка кешеләр тарафыннан, карандаш белән «Өммегөлсем, Рабига» дигән исемнәр, 65б кәгазьдә «Әюп абзый, Сөләйман, Фәхрегалләм, Гыйльмеруй, Шәмсеруй» исемнәре теркәлгән. Нигъмәтулла Солтанбәковның Иске Комазан авылында яшәгән бертуган сеңлесе Бибиситдыйканың Әюп исемле улы һәм Рабига исемле кызы булган (бу китаптагы шәҗәрә исемлегенә карагыз). Төрле бит читләрендә карандаш белән кыска җырлар, мөнәҗәт юллары да язылган.

Бу кульъязма Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең 2016 елда Мамадыш районына оештырган археографик экспедициясе вакытында Көек-Ерыкса авылында яшәүче Ранил Талиповтан бүлек мөдире Айрат Заһидуллин тарафыннан 20 июльдә алынган.

**3. «Иказел-әүляд»**

Китапханәдә «987т» шифры белән саклана торган бу кульъязма Россиядә XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән, 11x17,5(17,2) см. зурлыктагы 70 кәгазьне тәшкил итә.

Тышлыгы юк. Төбе ак җеп белән тегелгән. Сакланышы яхшы диярлек. Бары тик башындагы ике һәм иң ахыргы кәгазе таплан-ган һәм соңгысы бераз ертылган.

Кустодлары тотрыклы. Автор тарафыннан пагинация (битнең өстендә уртада яисә читендә) куелган.

Текстлар ачык һәм караңгы көрән төсләрдәге язу каралары белән теркәлгән. Юл араларында һәм бит читләрендә кайбер сүзләргә карата аңлатмалар аерым очракларда гади карандаш һәм шәмәхә кара белән дә язылган.

Бу кульъязмадагы бөтен текстларда хәрәкәләр кулланылган.

Кульъязмада Нигъмәтулла Солтанбәковның үзе иҗат иткән

23 шигъри әсәре урын алган. Текстының иң башында ул болай дигән: «Зәгыйфь «Иказел-әүляд» китабында фил-җөмлә дидеке». Димәк, бу җыентыгы «Иказел-әүляд» дип исемләнгән, ә «зәгыйфь» дип автор үзен атаган.

Әлеге шигъри җыентыгын Н.Солтанбәков үзенең кызларына, балаларына атап язган. Үгет-нәсихәт рухындагы шигъри вәгазьләре белән бергә, ул үзенең авыру халәтен дә шактый тасвир иткән, гыйбрәт алырга кушкан.

Тезмәләре төрлечә шигъри үлчәмнәрдә һәм алар берберсеннән сызык белән аерылганнар.

Тексты тулы. Башы (1б кәгазьдә):

Зәгыйфь «Иказел-әүляд» китабында фил-җөмлә дидеке

Мән эчем пошкач  
Язаем бер кач.  
Әүлядлар калгач –  
Тәзкирәм рәваҗ.

Ахыры (70а кәгазьдә):

Нәзмым укыйан,  
[Газизем ихван],  
Гозерем гаян,  
Дога өмидем.

Җыентыкның ахырында (70а кәгазьдә) автор тарафыннан түбәндәге юллар язылган: «Тарихы миладия 1909 нчы елда июньнең 12 нче йаумендә, һиҗрия 1327 нче сәнәдә җөмадиелахирнең 7 нче [йау]мендә. Кадь истәрәхә әл-каләм мин нәкалә әссәвади илял-бәйади би-гауни Аллаһу әл-Маликел әл-Ләтыйф, әл-Фәйяз мин йади зәгыйфь Нигъмәтулла бине мулла Мөхәммәдсафа әл-мәрхүм Солтанбиков әл-мөтәваттан бил-Ушмы әл-Голүви лиәмән әс-сәфәгый. Нәфигаһә Аллаһу Тәгалә нәфиган җәлиййән фид-дарәйни» (гарәпчәсенең тәрҗемәсе: «Хуҗабыз – мөлаем, юмарт Аллаһының ярдәме белән караламадан акка күчереп каләм тибрәтте Югары Ушмыда яшәгән зәгыйфь Нигъмәтулла Мөхәммәтсафа мәрхүм Солтанбиков улы. Аллаһы Тәгалә ике дөньяның олуг нигъмәтләрен насыйп итсен».

Кулъязманың кайбер битләрендә автордан башка кешеләр тарафыннан соңрак теркәлгән язмалар да бар. Мәсәлән, 1а кәгазьдә латин (яңалиф) хәрефләрендә карандаш белән: «Низамова Хәсби,

Гыйльметзин, Гыймазетзин(?), Кәшафетзин, Закир, Шакир» дигән исемнәр язылган. Шунда ук кирилл хәрефләрендә «Гайшә Гаязова(?), 7 апрель 49 ел» һәм «Газиль... 7/IV–46» дип теркәлгән.

22б кәгазьдә башка берәү тарафыннан гади карандаш белән болай диелгән: «Бу китапны укымагыз! Моннан да начар китап юк. Моны аяксыз кеше язган, аягың сынар». Шул ук кул белән 24б кәгазьдә: «Монда бар да ялган язылган» диелгән. 70б кәгазендә шәмәхә төстәге кара белән латин хәрефләрендә кыска җыр теркәлгән:

Су буйлары, су буйлары
Су буйларында нарат.
Суга барсам, онытып кайтам
Су агымына карап.

Бу кулъязманың китапханәгә кайсы елда һәм кемнән алынган булуы билгесез. Ул кыскача тасвирланып, бүлекнең инвентарь кенәгәсенә 2001 елның 2 февралендә теркәлгән. Димәк, китапханәгә шул вакытка кадәр алынган.

Җыентыктагы «Бу китапны укымагыз...» рәвешендәге сүзләрнең татар археографиясендә ара-тирә очрый торган бер күренешне хәтерләтүен искәртергә кирәк. Совет чорында, динне эзәрлекләү белән бергә, гарәп язуындагы иске китапларны саклау да яман эш булып хисаплана иде. Шуңа бәйле кайбер үзенчәлекле язулар да очратканыбыз булды. Мәсәлән, әти-әниләренең төсе-хәтере итеп кадерләп саклый торган китаплар белән бергә аерым кәгазьгә латин язуында яки кириллицада «болар начар китаплар» яки башка шуңа охшаш теркәлгән искәрмәләргә юлыкканыбыз булды. Алар, әлбәттә, күз буяу (ягъни, искелек калдыгын саклап ятуда гаепләнмәс) өчен генә язылган ялган сүзләр.

**4. Җыентык**

Китапханәдә «3560т» шифры белән саклана торган кечкенә форматлы – 8,8х11 см. зурлыгындагы җыентыкның гомуми күләме 115 кәгазьне тәшкил итә. Шуның 1–62 кәгазьләре кулъязма, ә 63–115 кәгазьләре басма Коръән сүрәләре һәм төрле догалар китабыннан тора. Кулъязма өлешенең кәгазе Россиядә XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән.

Тышлыгына кызгылт-көрән төстәге дермантин ябышты-

рылган. Җыентыкның төбе ак җеп белән тегелгән. Сакланышы уртача: ул дымлану кичергән, төбе тышлыгыннан аерыла язган, башлангыч битләре күбрәк пычранган.

62а кәгазьдәге кульъязма бите басма китапның үз пагинациясендәге 9 нчы битенә ябыштырылган. Ягъни, басманың башындагы (9 нчы биткә кадәрге) битләре юк. Ахыры исә үз пагинациясе буенча 146 нчы биттә (бу җыентыкта 115б кәгазьдә).

Кульъязма өлешендә иясе тарафыннан күпчелек битләргә пагинация саннары куелган. 1–95 битләре өзлексез номерланган (1а–47а кәгазьләр), 47б һәм 48а кәгазьләре буш – язусыз. 48б кәгазьдән 54б кәгазьгә хәтле яңадан 1–14 нче битләр буларак саннар язылган. 55а–62а кәгазьләрдә автор пагинациясе юк. Кустодлары тотрыклы, аларга караганда, җыентыкның кайбер кәгазьләре төшеп җуелган.

Текстлар барысы да Нигъмәтулла Солтанбәков тарафыннан көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. Бары тик 1а кәгазьдә «Фатих мулла Нигъмәтулла угылы Солтанбәков» дигән язу бу җыентыкның иясе тарафыннан теркәп куелган. Кульъязма текстларны һәм басма догалык китабын Нигъмәтулла мулла үз улы Фатих өчен махсус хәзерләп, төпләткән дип аңлашыла.

Җыентыкның 1б–25а кәгазьләрендә сорау-җаваплы «Иман шарты», 25а–44б кәгазьләрендә «Кырык фарыз» тексты язылган. 44б–47а кәгазьләрдә тәүбә-истигъфар догасы, 48б–52а кәгазьләрдә «Касыйдәтү Әбүбәкер әс-Сиддыйк разый Аллаһы ганһе» дип исемләнгән, гарәп телендәге тезмә әсәр язылган. 52а–60а кәгазьләрдә «Диване Коддуси» китабыннан ике шигъри әсәр күчереп язылган. Юллар арасында кайбер сүзләргә аңлатмалар бирелгән.

60б–62а кәгазьләрдә Нигъмәтулла Солтанбәковның аянычлы үз хәлен тасвирлаган, бишәр иҗекле үлчәмдәге шигъри әсәре теркәлгән. Бу текст алдагыларыннан ваграк итеп һәм хәрәкәләр кулланып язылган.

Соңгы текстның ахырында авторының 17 ел урын өстендә ятуын белдергән сүзләренә караганда, аның бу шигъри тезмәсе 1908 елда иҗат ителгән.

Тексты тулы. Башы (60б кәгазьдә):

Бакың кауленә
Зәгыйфь, кәминә
Язды нәзмилә
Әбъяты каму.

Ахыры (62а кәгазьдә):

Язды бу ахмак
Әхвәлем бик чак.
Ятам – пөр почмак
Унйиде ел бу.

Бу кульязма китапханәгә Яр-Чаллы шәһәрендә яшәүче Айрат Шәвәлиевтән 2019 елда (июль аенда) алынган.

**5. Җыентык**

Китапханәдә «6674т» шифры белән саклана торган бу кульязма җыентык Россиядә XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән, 11х17 см. зурлыктагы 38 кәгазьдән тора.

Катыргы тышлыгының читләренә кызыл төстәге, төбенә башта шулай ук кызыл һәм соңрак соры төстәге тукыма ябыштырылган. Форзац битләре өчен XX гасыр башында Казанда нәшер ителгән «Йолдыз» газетасының кисәкләре кулланылган. Төбе ак җеп белән тегелгән.

Сакланышы уртачадан түбәнрәк: тышлыгының төбенә өстәп ябыштырылган соры тукымасы купкан. Шулай ук эчтәге кайбер битләре төшеп җуелган, кайберләре төбеннән аерылган һәм пычранган, текстлары тулы түгел. Соңрак кайбер битләре төсле карандашлар белән балалар тарафыннан буялган (мәсәлән, 8а, 12а, 17а, 17б һ.б. кәгазьләр).

Кустодлары тотрыклы. Кәгазьнең өстендә, бит читләрендә автор тарафыннан пагинация куелган.

Беренче әсәр тексты үз пагинациясе буенча 6–89 нчы битләрне тәшкил итә. (Әйтеп үтелгәнчә, эчендәге кайбер битләре төшкән һәм сакланмаган. Ә икенче әсәр тексты үз пагинациясендә 3–11 битләр буларак номерланган һәм ул өлеше 34–38 нче кәгазьләргә туры килә.

Китапханәдә куелган кәгазь номерлары буенча 1 нче санлысы үз пагинациясендәге 59 һәм 60 битләр булып, тексттагы урыны 21 нче кәгазьдән соң булырга тиешле.



*Кулъязма җыентыкның 60б кәгазе*

38 нче кәгазь (үз пагинациясе буенча 2–3 нче битләр) эчтәлеге буенча әсәр текстының башына карый һәм ул дөреслектә 34 нче кәгазь алдында булырга тиешле.

Җыентыктагы беренче текстның күпчелек өлеше (1–21 кәгазьләр) караңгы көрән төстәге, ә 22–32 кәгазьләр һәм икенче әсәр тексты ачыграк көрән төстәге язу каралары белән теркәлгән. Беренче текстта хәрәкәләр кулланылмаган, икенчесенең бөтен сүзләре хәрәкәләр белән язылган.

Беренче әсәр – Нигъмәтулла Солтанбәков иҗат иткән «Кыйла күргел намазыңны» әсәре. Үзендә исеме күрсәтелмәгән булса да, строфаларның күбесендә кабатланган «Кыйла күргел намазыңны» дигән рефренга нигезләнеп, әлеге тезмә әсәрне шулай дип исемләргә мөмкин. Бу әсәрнең башындагы берничә кәгазе сакланмаган.

Әлеге текстта автор үзенең исемен күрсәтмәгән, ләкин аның электәге шундый ук исем белән мәгълүм шигъри вәгазьгә нәзыйрә рәвешендә Н.Солтанбәков тарафыннан язылганлыгы аңлашыла. Моның шулай икәнлеген тел-стиль үзенчәлекләре ачык күрсәтә. Шулай ук бу текстта 5б кәгазьдән башлап әче тәнкыйть сүзләре (укымышлыларның, галимнәрнең азгынлыклары, хәләл һәм хәрәм турында), хәмергә каршы үгетләүләр аларны нәкъ Нигъмәтулла мулла язганын ачык белдерә.

Текстның башы (2а кәгазьдә, үз пагинациясе буенча 6 нчы биттә):

Тәкрар орырса ул сәни,
Кыйла күргел намазыңни.

Ахыры (30а кәгазьдә, үз пагинациясендә 85 нче бит):

Укып бу мәзкүр вәгазьни,
Кабул кыйлың нәсаихни,
Кичә-көндез кыйл сәгыйни,
Кыйла күргел намазыңни!

Җыентыкның 30а–32б кәгазьләрендә авторның шигъри-тезмә догасы язылган. Күпчелек строфа ахырларында кабатланган сүзләренә күрә, аны шартлы рәвештә «Кыйла күргел догаңызны» дип исемләргә мөмкин.

Бу текстның башы (30а кәгазьдә, үз пагинациясендә 85 нче биттә):

Гафу кыйлып бу гасыйни,
Кәзалик атам-анамни,
Әкъриба һәм әүлядымни,
Ярлыкагыл барысыни!

Ахыры (32б кәгазьдә):

Сәдакаи җариямни,
Язып куйдым сезә мони,
Тәрәххем кыйлып, зәгыйфьни,
Кыйла күргел догаңызни!

Шунда ук автор болай дип тә өстәгән:

Миладия тарих мең тукыз
Тукызы сәнә дәю укыңыз,
Апрель уны – белеңез,
Бу китап нәкыль улмышны.

Ягъни, 1909 елның 10 апрель көнендә караламадан акка күчереп язылган. Иҗат ителгән вакыты да, ихтимал, шул ук елга туры килгәндер. Түбәндәге мәрсия шулай дип фаразларга нигез бирә.

Җыентыкның 34–38 кәгазьләрендә (үз пагинациясе буенча 2–11 битләрдә) Нигъмәтулла Солтанбәковның Түбән Ушмы авылы Һадиулла хәзрәткә багышлап язган мәрсиясе теркәлгән. Аның башы һәм ахыры юк.

Кулъязма җыентыкта әсәр текстының башы (38а кәгазь, үз пагинациясендә 2 нче бит):

Дәю күр угылына, рәгъбәт,
Һадиулла хәз(е)рәте.

Ахыры (37б кәгазьдә):

Әүкаты варды дөньяви,
Кәзалик инфак охрави,
Күп галим дәгел мөсави,
Вәзен кыйлсаң, гадәләти.

Текстларда кайбер төзәтмәләр һәм аңлатмалар бар.

Түбән Ушмы авылының өченче мәхәллә мәчетендә имам булып торган Һадиулла Әхмәтев, ихтимал, 1908 яки 1909 елда вафат булгандыр[1]. Чөнки аннан соң улы Габдешшөкүр шул ук мәчеттә 1909 елдан башлап имамлык вазифасын үтәгән.

Бу җыентык китапханә хезмәткәрләре тарафыннан Байлар Сабасы авылында 2000 елда табып алынган.

**6. Мөбарәкзадә мәрсиясе**

Китапханәдә «7882т» шифры белән саклана торган бу кулъязма Россиядә XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән, 17,5х22 см. зурлыктагы 10 кәгазьдән тора.

Тышлыгы юк. Кәгазьләре таркау. Сакланышы уртача: башындагы һәм 4–5 нче кәгазьләре арасында берәр кәгазе сакланмаган; дымлану кичергән, ләкин язуы зарарланмаган.

Кустодлары бар, фәкать 2б кәгазендә күрсәтелмәгән һәм 6б кәгазьдәге кустоды ялгыш язылган. Автор тарафыннан куелган пагинациянең бераз ялгыш икәнлеген искәртергә кирәк: 11 саны

[1] Вафат булган вакытын архив мәгълүматларыннан төгәл ачыкларга мөмкин.

урынына ялгыш 22 дип язылган һәм 13 саны бер-бер артлы ике мәртәбә кабатланган.

Текст көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән.

Текстның башы юк, ахыры бар. Сакланган өлешенең башы (1а кәгазьдә):

...Кәтде имди мәҗалем,
Кани күркәм җәмалем,
Бәян кыйлыйм әхвәлем,
Сезә тәзкирәм кала.

Ахыры (10а кәгазьдә):

Вә йәбкаль-хатт фил-әүрак,
Кятибе улса да туфрак,
Мөбарәкзадә улып фирак,
Тәзкирәм бу атам-анам.

Бу әсәрнең кайсы елда иҗат ителгән булуы төгәл билгеле түгел.

Мөбарәкзаденең кем булганлыгы һәм мәрсиядә тасвирланган вакыйгалар турында кереш мәкаләдә яздык.

Бу кулъязма китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Шәйхенур Ахмановтан бүлек мөдире Айрат Заһидуллин тарафыннан 2000 елның 5 май көнендә алынган.

**7–8. Бибитаибә мәрсиясе**

Китапханәдә «3561т» шифры белән саклана торган кулъязма истәлек XX гасыр башында эшләнгән, 11х18 см. зурлыгындагы, түбән сыйфатлы сары-соргылт кәгазьдә. Гомуми күләме 57 кәгазьне тәшкил итә.

Бу саклану шифры белән билгеләнгән берәмлектә бер төрле үк текст язылган ике дәфтәр саклана. Китапханәдә аларның берсе 1–28 кәгазьләр, икенчесе 29–57 кәгазьләр буларак номерланганнар. Алар – 1924 елның 26 декабрендә вафат булган Бибитаибә Могтәмидшаһ мулла кызына багышлап ире Нигъмәтулла Солтанбәков язган мәрсиянең ике нөсхәдәге күчермәләре.

Дәфтәрләрнең берсе – каралама текст, ә икенчесе акка күчерелгән дип тә уйларга мөмкин кебек. Ләкин, чынлыкта, бу дәфтәрләр авторы тарафыннан аерым нөсхәләр рәвешендә күчерелгәннәр. Аларның берсен аерып каралама дип атап булмый, чөнки иҗат ителгән вакытына хас сызган-төзәткән урын-

нары юк диярлек. Ә икесендә дә бит читләрендә язылган өстәмәләре бар. Ике дәфтәрнең текстларында берникадәр аермалар бар. Бер-берсендә кабатланмый торган текст өлешләре, кайбер строфаларның һәм шигъри юлларның урыннары үзгәргән булуы, аерым сүзләрнең мәгънәдәш синонимнары кулланылганы, бер үк сүзнең кушымчалары төрлечә язылган очраклар күзәтелде. Ике дәфтәрнең дә бит читләрендәге өстәмәләр бер үк вакытта шәмәхә кара белән теркәлгәннәр. Икенче дәфтәр текстындагы 17 дүртьюллык беренче дәфтәрдә юк, ә беренчесендәге ике дүртьюллык икенчесендә юк. Автор беренче дәфтәр текстын икенчесенең кайбер өлешләрен кыскартып һәм камилләштереп язгандыр дигән нәтиҗә ясап булмый. Күрәсең, ул, үзенең физик халәтенә күрә, бер дәфтәр текстын теркәгәндә башкасыннан файдаланган булса да, ара-тирә күз төшереп кенә алгандыр дип фаразларга мөмкин һәм аермалар шул сәбәпле дә килеп чыккандыр. Ягъни, кайбер сүзләрнең һәм юлларның урыннары да үзгәргән, строфалары үзләре дә башка урынга күчереп язылган. Әгәр дә шушы ук мәрсиянең тагын бер күчермәсе табыла калса, анысында да өстәмәләр һәм үзгәрешләр булачагы аңлашыла.

Безнең карамактагы ике дәфтәр текстлары бер-берсен тулыландырганга күрә, бу китапта беренче дәфтәрне (язуы яхшырак танылa торганын) нигез итеп алып, аңа икенче дәфтәр өстәмәләрен кушып бирдек. Андый өстәмәләр астөшермәләрдә искәртелде.

Ике дәфтәрдәге текстлар да хәрәкәләр кулланып язылган. Кайбер битләренең читләренә строфалар һәм аерым юллар өстәлгән. Юл араларында кайбер сүзләргә карата искәрмәләр һәм аңлатмалар бирелгән.

1–28 нче кәгазьләрдәге аерым дәфтәрнең кәгазе бераз калынрак һәм икенчесе белән чагыштырганда сыйфатлырак. Ул шәмәхә төстәге язу карасы белән теркәлгән. 16б кәгазьдәге текстны язганда төшеп калган өлеше махсус өстәмә итеп тегелгән (17 нче кәгазь).

29–57 нче кәгазьләрдәге дәфтәрнең кәгазе түбәнрәк сыйфатлы булуы өстенә, яшел төстәге сыек кара белән язылган тексты начар танылa. Монысының аерым битләрендәге начар күренгән юллары өстеннән автор шәмәхә кара белән кабатлап язып чыккан, 31–49 нчы кәгазьләрендәге текстларын исә тоташтан яңарткан.

Тышлыклары юк. Ике дәфтәрнең дә төпләре ак тегәрҗеп белән тегелгән. Беренче дәфтәрнең сакланышы уртача, икенчесенеке – уртачадан түбәнрәк: битләре төбеннән өзелеп буталган һәм яшел каралы язуы шактый начар күренә.

Кустодлары бар. Ике дәфтәрнең дә битләрендә (өске якларында) автор тарафыннан пагинация куелган. Берсендә (1–28 кәгазьләрдә) бит саннары кәгазьнең уртасында, ә икенчесендә (29–57 кәгазьләр) битнең читенә куелганнар. Беренчесенә 1–51 нче, икенчесенә 4–61 нче бит саннары язылган.

Ике дәфтәрдәге текстлар да авторның башка кулъязмаларына караганда, эрерәк итеп, зур тырышлык белән язылган. Аның мәрсияне укучыларга тану өчен ничек тә уңайлырак булсын дигән теләк белән язганлыгы аңлашыла.

Беренче дәфтәрдә текстның башы бар, ахырында бер кәгазе җуелган.

Мәрсия текстындагы «Утыз дүрт ел ята хәзрәт…» сүзләренә карата авторның өстәп язган «халә 35» (хәзер 35) дигән искәрмәсе мәрсиянең 1925 елда иҗат ителгән булуын дәлилли.

Текстның башы (1б кәгазьдә): Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим

Чиксез хәмедем Аллаһ дияем,
Рәсүлә салаватым күндерәем.
Аль, әсхабләренә һәм
Зәгыйфьтән күндерәем.

Ахыры (28б кәгазьдә):

Ахыр намәм мәнем сезә,
Укып кара, салып күзә,
Шәфкатьлә дога кыйл безә,
Даим сезә риҗа кыйлаем.

Икенче дәфтәрдә текстның башы юк (ике кәгазе төшкән), ахыры бар.

Дәфтәрдә сакланган текстның башы (29а кәгазьдә):

Барымыз тордык без аңлап...

Ахыры (57б кәгазьдә):

Сиксән биштә инде яшь,
Утыз дүрт ел ятмакым фаш,
Истилка хәл галәл-фираш
Тәмам язылды мәрсиям.

57б кәгазьдә бу нөсхәнең (икенче дәфтәрнең) күчереп язылган датасы «1927 нче елда, априлнең 23 нче көнендә ...» дип теркәлгән. Язуының карасы бик уңганлыктан, ахырындагы ике сүзен танып булмый.

Җыентыкның 9 һәм 10 нчы кәгазьләренә Мамадыш район больницасыннан 1944 елда М.Шаһвәлиевага бирелгән белешмә ак җеп белән тегеп беркетелгән.

Кулъязманың 1а кәгазендә башка бер кеше тарафыннан карандаш белән «Кулы да калтыраганлыктан, аның язуын танып булмый» дигән сүзләр теркәлгән.

Бу кулъязмалар китапханәгә Яр-Чаллы шәһәрендә яшәүче Айрат Шәвәлиевтән 2019 елда алынган.

**9. «Шәҗәрә» җыентыгы**

Бу тасвир кулъязманың фотокүчермәсе буенча язылa. Шунлыктан, тулы тасвир өчен зарур кайбер үзенчәлекләрен чагылдырып булмый. Кулъязманың төп нөсхәсе Солтанбәковлар нәселе дәвамчыларында саклана. Безгә күчермәне Кукмара шәһәренең Туеш мәхәлләсе мәчете имамы Айрат хәзрәт Шәфигуллин бирде.

Кулъязма Россиядә XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән 10 кәгазьдән гыйбарәт.

Сакланышы уртача: кайбер кәгазьләренең читләре таушалганга һәм язулары уңганлыктан танылып җитми (бигрәк тә 10а, 10б кәгазьләрдә).

Кустодлары бар. Автор тарафыннан битләрнең өстендә, уртада пагинация куелган. Соңрак шулар белән янәшәдә хәзерге саннар да язылган.

Җыентыкның шигъри өлешендә Нигъмәтулла Солтәнбәков иҗат иткән ике әсәр текстлары урын алган. Беренчесе – «Югары Ушмы мулла Мөхәммәтсафа хәзрәтнең әнсаблары шәҗәрәсе (бикадәрил-имкян китабәт кыйлынды)» дип аталган һәм әлеге шигъри шәҗәрә 1–10 битләргә теркәлгән. Башы (1 биттә):

Мирза Бакиев нәселеннән
Мирзалар Ушмысында
Рахманкол мирза әүлядлары
Гани улмыш бихисап.

Ахыры (10 биттә):

Гаять ирдем гыйззәттә,
Даим булдым хөрмәттә.
Имди хәсрәт-михнәттә
Мәгъмүм ятамән егълап.

Җыентыктагы икенче текст авторның бертуган энесенә багышлап язылган мәрсия. Ул «Мөһаҗир мулла Шәехзадә мулла Мөхәммәтсафа угылы Солтанбәк хакында» дип исемләнгән. Башы (11 биттә):

Мөхәммәтсафа хәзрәтенең
Шәехзадә һәм угылы
Өфе өязе Олуг Күлдә
Имам иде ул әхбаб.

Ахыры (17 биттә):

Фикер кыйлып караңыз,
Зәгыйфе онытмаңыз,
Мәхрүм-мәэюс кыйлмаңыз,
Дәю яздым бу китап.

Текстлар шәмәхә төстәге язу карасы белән теркәлгән, ә хәрәкәләре һәм юл араларындагы автор искәрмәләре кызгылт-көрән төстәге кара белән өстәлгән.

Кулъязма җыентыкның 19–20 битләрендә Солтанбәковлар нәселе шәҗәрәсенең схемалары Нигъмәтулла мулла тарафыннан сызылган һәм аларга карата кыскача аңлатмалар теркәлгән.

Бу нәселнең аерым тармаклары алда әйтеп үтелгән шигъри «Шәҗәрә» текстының юл араларында һәм 2–4, 8, 9 битләренең читләрендә дә язылган.

Нигъмәтулла Солтанбәковның бу җыентыгы 1895 елның 12 октябрендә язылып төгәлләнгәнлеге үзе тарафыннан 20 биттә теркәп куелган.

# СҮЗЛЕК

*аглаю, аглаюп* – елап
*агыр* – авыр
*айат* – аятьләр
*аләт* – корал
*Аллаһу әгъләм* – Алла – иң яхшы белүче
*алубән* – алып
*аль-әсхаб* – нәсел, сәхабәләр
*ан* – кыска вакыт, гүзәллек
*анга* – аңа
*асам* – гөнаһлар
*аслан* – бер дә, беркайчан да
*ачкыл* – ач
*аяга* – аякка

*әбәд* – мәңге, мәңгелек
*әбваб* – ишекләр, капкалар
*әбдан* – гәүдә, тән
*әбрар* – изге кешеләр
*әбъят* – бәетләр, шигырьләр
*әве* – өе
*әгъда* – дошманнар
*әгъҗәб* – бик гаҗәп, гаҗәпнең гаҗәбе
*әгъләм* – иң яхшы белүче
*әгълял* – богау
*әгъмаль* – гамәлләр
*әгъния* – байлар
*әгъташ* – сусау, эчәсе килү
*әда* – үтәү
*әдәп-хилмиде* – әдәпле-йомшак иде
*әҗаниб* – чит кешеләр
*әҗре газыйм* – зур савап
*әҗһәл* – бик надан, иң белемсез
*әза* – иза, газап
*әзкяр* – зикерләр, искә алулар
*әзһар* – чәчәкләр
*әйдан* – тагын, тагы да, янә

*әйде* – әйтте
*әййүл* – июль
*әймешга* – әйтергә
*әйям* – көннәр
*әкариб* – якыннар, туганнар
*әкәлли* – тешли
*әкәл-ү-шәраб, әкәл-ү-шөруб, әкәл-шәрап* – ашау һәм эчү, ашау-эчү
*әкрәм* – бик юмарт, бик хөрмәтле
*әксәр* – күпчелек
*әкябир-гани* – олуглар-байлар
*әкъбәх* – бик әшәке
*әкъваль* – сүзләр
*әкъвам* – халык
*әкъриба* – якыннар, туганнар
*әл* – кул
*әләм* – авырту
*әлван* – төрле төсле
*әлим* – үзәк өзгеч, бик газаплы
*әлифтик* – «әлиф» хәрефе кебек төз
*әлфаз* – сүзләр
*әлфирак* – аерылышу
*әлхәмде Лилләһ* – Аллаһыга мактаулар булсын
*әмваль* –мал-мөлкәт
*әмват* – мәетләр
*әмирәт* – әмирлек
*әмляк* – милекләр
*әмн-ү-аман* – исән һәм имин
*әмраз* – авырулар
*әмре мәгъруф, нәһи мөнкәр* – кушылган изге эшләр һәм тыелган гөнаһлы гамәлләр
*әнваг* – күп төрле
*әнвәр* – бик нурлы, бик якты
*әнсаб* – нәсәпләр
*әрвах* – рухлар
*«Әрзәли әл-гомри ли-кәй лә йәгъләмә» (Коръән, «Ән-Нәхл» сүрәсе, 70 нче аятьтән)* – белгән бар нәрсәне дә онытып, гомернең иң зәгыйфь чагына кире кайтарыла
*әркиб* – утырып
*әсабигъ* – бармаклар
*әсваб* – киемнәр
*әсмар* – җимешләр
*әсрар* – серләр
*әү, әүвә* – өй, өйгә
*әүвәбин* – үкенеч, тәүбә

*әүвәлән* – иң әүвәл, башлап
*әүкат* – вакытлар
*әүкат хөмес* – биш намазның берсе
*әүляд* – балалар
*әүляил-әлбаб* – акыл ияләре, яхшырак белүчеләр
*әүрад* – Коръәннең төнлә укыла торган өлеше
*әүрак* – кәгазь битләре
*әүһам* – ялгыш уйлар, хыяллар
*әфгаль-әкъваль* – фигыльләр һәм сүзләр
*әфгале хәмидә* – мактаулы эшләр
*әх* – туган
*әхадис* – хәдисләр
*әхак* – хаклырак
*әхбаб* – дуслар
*әхҗәр-тораб* – таш-туфрак
*әхсән* – бик матур
*әхъяр* – яхшы кешеләр, изгелек кылучылар
*әһали* – халык, кешеләр
*әһәм* – бик кирәкле
*әһваль* – куркулар
*әһле гыял* – гаилә әгъзалары
*әһлия* – хатын
*әшкял* – ишарәләр, шәкелләр
*әшкярә* – ачык
*әшрар* – явызлыклар

*баб* – ишек, капка
*баз* – янә
*баз, базы* – карчыга, лачын
*бакарде* – багар иде, күрер иде
*батыйн* – яшерен, күренми торган
*батыйны җәваһир* – яшерен җәүһәрләр
*баша* – башка
*бәгъдә* – шуннан соң
*бәгъзә, бәгъзе* – берәүгә, кайбер
*бәгыйд* – ерак
*бәка* – мәңгелек, яшәү
*бәкәтил-арду вәс-самават* – җир һәм күкләр елар
*бәнат* – кызлар
*бәрек* – хөрмәт
*бәрҗа* – урынлы, уңай
*бәхре (бәхер)* – диңгез
*бәхтияр* – бәхетле
*бәшарәт* – шатлык, шатлыклы хәбәр

*бәшәр* – кеше, кешеләр
*белмәян* – белмәгән
*бигаять* – чиксез
*бижҗула* – ризасыз, килешмәүче
*биззарур* – чарасыз, ирексездән
*би-кадәрил-имкян* – мөмкин булганча
*бинагяһ* – кинәттән
*биначар* – чарасыз, мәҗбүри
*бирия* – риясыз, чын күңелдән
*бирьян* – кыздырылган ризык
*бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим* – рәхимле, шәфкатьле Аллаһының исеме белән
*би-хаккы «Сүрәи Ихлас»* – «Ихлас» сүрәсе хакына
*бостан* – бакча
*бөйлә* – болай, мондый
*бөлуг* – җитлегү, балигълык
*бөрадәр* – туган, кардәш
*бөют* – өйләр, урыннар
*булан, буланча, буланы* – булган, булганчы, булганы
*бырагып* – ташлап

*важҗибат* – үтәргә тиешле эшләр
*вакыйг* – булу, барлыкка килү
*вар, вары* – бар, бары
*васыйг* – киң
*васыйл кыйлгыл гыйззәтә* – гыйззәт-хөрмәткә ирештер
*васыф* – сыйфат, билге
*Ваһһаб* – бөтен нәрсәне бирүче зат (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исеме)
*Ваһһаб-у-Тәүваб* – бөтен нәрсәне бирүче һәм тәүбәләрне кабул итүче (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре)
*вәбал* – гөнаһ, авырлык
*вәдагы* – әманәтне
*вәзен* – үлчәү
*вә йәбкал-хатт фил-әүрак* – кәгазьдәге язу мәңгелек
*«Вә ма тәдри нәфсүн би-әйи ардин тәмүтү» (Коръән, «Локман» сүрәсе, 34 нче аять)* – һичбер кеше кайсы җирдә үләчәген белми
*вәһем* – хыял, шикле уй
*вир (вирең, виргел), вирәрсән, виреп, вирмеш* – бир, бирерсең, биреп, биргән
*воcләт* – кавышу
*вөзуэ* – тәһарәт алу
*гавам* – гади халык
*гавам-хасс* – гади халык һәм югары катлау, бөтен халык

*гада* – иртәгә
*гадат* – гадәтләр
*гадәләт* – гаделлек
*гадәм* – юк булу, юклык
*гаддар* – хыянәтче, залим
*гажизин гыйбад* – гаҗиз кол
*гаҗиз-у-начар* – зәгыйфь һәм чарасыз
*газбе кәлмәди* – ачуы килмәде
*газем кыйлмыш фирар* – качуны максат иткән
*газемлә* – тәвәккәллек белән, ниятләп юлга чыгу
*газыйм* – бөек, әһәмиятле
*гаиб иттеләр* – югалттылар
*гаит* – хаҗәт
*гайдәйн* – ике гает бәйрәме
*гайяр* – гайрәтле
*галәддәвам* – туктаусыз
*галәл-фираш* – ятакта, түшәктә
*галиб* – җиңүче
*Галим* – һәр нәрсәне иң яхшы белүче (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исеме)
*Галләмел-гоюб* – гаепләрне иң күп белүче зат (Аллаһы Тәгаләнең күркәм сыйфаты)
*гамил, гамилде* – дәрәҗәле кеше, гамәл кылучы иде
*гам – гомуми*
*гамь, гамьнәк* – кайгы, кайгылы
*Гани* – бик бай, бирү белән байлыгы кимеми торган зат (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исеме)
*гараз* – теләк, максат
*гарасат* – кыямәт, мәхшәр
*гарәбия* – гарәп теле
*гаргарә* – тамак чайкау
*гарикъ* – бату, күмелү
*гарыз* – аңлату, җиткерү
*гасир* – авыр, читен
*гас, гасый* – гөнаһлы
*гатикъ* – азат итүче
*гафил, гафилин* – ваемсыз, игътибарсызлар
*гафифә* – пакь, намуслы, абруйлы
*гафләт* – игътибарсызлык, гамьсезлек
*Гафур, Гаффар* – гафу итүче, гөнаһ-хаталарны ярлыкаучы (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре)
*гаһед* – ант, вәгъдә
*гаян* – ап-ачык, билгеле
*гәр* – әгәр

*гобрәт* – мөлкәт
*гозер-хажҗат* – үтенеч, теләк
*голәма* – галимнәр, укымышлылар
*гокубат* – газаплар, авырлыклар
*гораб* – козгын
*гораба* – зәгыйфьләр
*горбәт* – ялгызлык, читтә булу
*горуб улды* – батты
*гофран* – гөнаһларны кичерүче
*гоюб* – гаепләр, гөнаһлар
*гөруһ* – төркем, нәсел
*грифтар* – дучар, читен хәлгә төшкән
*гыйбарәт* – гыйбарәләр
*гыйльман-вилдан* – җәннәт хезмәтчеләре
*гыйльме мантыйк* – мантыйк фәне
*гыйльме нәхү* – нәхү (синтаксис) фәне
*гыйльме фикъһ* – шәригать хөкемнәре, юриспруденция
*гыйльме һәйәт* – астрономия
*гыйнад* – тискәрелек, үзсүзлелек
*гыйндендә* – янында
*гыйсъян* – баш тарту, каршылык күрсәтү
*гыйтаб* – шелтә, орышу

*давай* – бир, әйдә
*даим* – даими
*дамелла* – зур укымышлы, мәдрәсәдә укытучы
*дафигъ* – кире кайтаручы, читләштерүче
*дахил* – керү, катнашу
*дәвамәт* – даими
*дәгел, дәгелде, дәгелмән* – түгел, түгел иде, түгелмен
*дәк* – тик, тикле, хәтле
*дәм* – сулыш
*дәмбәдәм* – һәрвакыт, өзлексез
*дәрәҗҗат* – дәрәҗәләр
*дәрсә* – дәрескә
*дәүри* – әйләндереп
*дәфен* – җирләү, күмү
*дәхел* – катнашу
*дәхи* – тагын
*дәю, дәюбән (дәюр)* – дип, дияр
*деләрәм* – телим
*дидар* – йөз, күренеш
*дидеге, димәгә, димәсдек, дирделәр, диялем, диян* – дигән, диярgә, димәс идек, дияр иделәр, дим, дигән

*диләнке* – кишәрлек, бүлем; рус телендәге «делянка» сүзе
*динә* – дингә
*дога бәд* – бәддога
*дөхүл кыйлып җәннәтә* – җәннәткә кертеп
*дөшвар* – кыен, авыр, җитди

*җавабә кадир кыйл* – җавап тотарга көч бир
*җавабе шафи* – дөрес җавап
*җаиз* – дөрес, ярый торган
*җамид* – туң, каткан
*җаһ* – югары дәрәҗә, вазифа
*җаһил* – надан
*җәббар* – зур көчле, куәтле
*җәгърафия* – география
*җәзәгъ-фәзәгъ* – шик-шөбһә, курку-тынгысызлык
*җәзилә* – хөрмәтле
*Җәлил* – иң бөек дәрәҗәле (Аллаһы Тәгалә)
*җәмаль* – йөз, күркәм йөз
*җәмгы әмваль дәгелде* – мал җыючы түгел иде
*җәмигъ* – барлык
*җәмилә* – чибәр, күркәм
*җәнабәт* – тән пычраклыгы
*җәһлә зольмате* – наданлык караңгылыгы
*җилд* – том
*җинан* – җәннәтләр
*җирә* – җиргә
*җифә* – үләксә
*җөда* – аерылган
*җөлүс* – утыру
*җөнеб* – госелләнергә тиешле кеше
*җөрм-ү-гыйсъянлә мөбтәляем* – гөнаһ һәм каршылыкка бирелгән идем

*забут* – завод
*зарб, зарбә* – сугу, кыйнауга
*заһир* – ачык, күренеп тора торган
*зәбун* – зәгыйфь, хурлыклы
*зәҗер* – җәфа, мәҗбүрилек
*зәлил* – хурлыклы, түбән, кадерсез
*зәррә* – бөртек
*зәүҗ* – ир
*зикр-ү-тәсбих* – зикер һәм тәсбих
*зилзилә* – җир тетрәү
*зирагать* – игенчелек

*зиядә* – артык, күбрәк
*зөнуб* – гөнаһлар
*зөррияте* – нәсәп
*зыяфәт* – кунак итү, сыйлау

*игълам* – игълан, белдерү
*игътимад* – ышаныч, таяныч
*идүбән* – итеп
*иҗмалән* – кыскача
*иҗтинаб* – саклану, тыелу
*изен* – рөхсәт
*иксаб* – кәсеп итү
*илтимас* – үтенеч
*имәс гаҗәп* – гаҗәп түгел
*имәс гайрә* – башкага түгел
*имди* – инде
*имкян* – мөмкинлек
*ингамлә ихсан, ингам-у-ихсан* – ярдәм итү-булышу, сыйлау һәм изгелек эшләү
*«Ин күнтүм җөнүбән фәт-таһһару» (Коръән, «Әл-Маидә» сүрәсе, 6 нчы аятьтән)* – иселләнергә тиешле булсагыз, пакьләнегез
*интибаһ* – уяну, күз ачу
*интикам* – үч алу, ачу кайтару
*инфак* – яшәү өчен киәк булганнарны биреп тору
*ирәннәр* – ир-атлар
*ирер* – булыр
*иржигый хитап* – Коръәндәге «Фәҗер» сүрәсенең 28 нче аятендәге «иржигый илә Раббики» (Раббың хозурына кил) гыйбарәсе күздә тотылган
*искат өчен саум-салават* – ураза һәм намазларны өстән төшерү өен
*ислах* – яңарту, реформа
*истигъфар* – гафу итүне, ярлыкауны сорау
*истилка* – чалкан яту
*истинҗа* – тәрәттән соң пакьләнү
*истиһза* – көлү, мыскыл итү, хурлау
*исһар* – төнлә йокламау
*иттифак* – берлек, бердәмлек
*ифһам кыйл* – аңлат
*ихван* – ир туганнар, кардәшләр
*ихтисаб* – хисап бирү
*ишгаль* – шөгыльләнү, эшләү
*ишелмәде* – ишетелмәде
*ишрак* – яктырту, нурландыру
*ишрак дөха намазы* – иртә белән кояш күтәрелгәч укыла торган

нәфел намазы

*йаум* – көн
*йаумә йакумел-хисап, йаумел-хисап, йаумел-гыйкаб* – хисап биреләчәк көн, кыямәт көне, җәза көне
*йәрә* – җиргә
*йиймәгел, йийеп* – ашама, ашап

*кабаих* – кабахәтләр, әшәкелекләр
*кабил* – кебек, охшаш
*кабих* – кабахәт
*кабрә тыка* – кабергә тыга
*кабубән* – кабып
*кавагыйд* – гарәп теле кагыйдәләре
*кави* – куәтле
*кагыйд* – утырып тору
*Кадир Сөбхани* – һәр нәрсәгә көче җиткән бөек зат (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре)
*кадр-у-гыйззәт* – кадер һәм хөрмәт
*казаи хаҗәт* – вакытында үтәлергә тиешле бурычлар
*казый әл-хаҗәт* – зарур эшләремне үтәтүче
*каим* – аяк өстендә басып тору
*калан, калыпмән* – калган, калдым
*калил* – аз, кечкенә
*кальб* – йөрәк, күңел
*камуг* – бары
*кани* – кайда
*канигъ* – канәгать
*кантон пумышәге* – кантон башлыгының ярдәмчесе; *пумышәк* – ярдәмче; рус телендәге «помощник» сүзе
*капансаң* – капланып ятсаң
*карар күрмеш* – яшәгән
*карыз (карз)* – бурыч
*карый* – карт
*карья* – авыл
*касд* – максат, ният
*касыйр* – кыска
*катрә* – тамчы
*каулечә, каулилә* – сүзенчә, сүз белән
*каһр-у-газап* – каһәр һәм газап
*кәбаб* – утта кыздырган ит
*кәзалик* – шулай ук, тагы да
*кәзб-ү-гайбәт* – ялган һәм гайбәт
*кәйфә* – ничек

*кәлеп, кәлтер, кәлмәке, кәлмәсене, кәлүбән* – килеп, китер, киләсе, килмәячәген, килеп
*кәлляб* – этләр
*кәл-һәвам* – зарарлы бөҗәк кебек
*кәлям, кәлямлә* – сүз, сүз белән
*кәмал, кәмаләт* – камил, камиллек
*кәмтәр* – түбән, хур
*кәнде каләмилә* – үз каләме белән
*кәрамәт* – могҗиза
*кәрәк ирсә* – кирәк булса
*кәрәмеңлә, кәрәмлә* – юмартлыгың белән, юмартлык белән
*кәррат* – кат-кат, бик күп тапкыр
*кемсәлә* – кеше белән
*керәнчә* – кергәнче
*китабәт кыйлынды* – язылды
*китән* – киткән
*когуд* – утыру
*колүб* – күңелләр
*коруг* – коры
*көллесе* – барысы
*«Көллү нәфсин заикател-мәүт» (Коръән, «Әлү Гыймран» сүрәсе, 185 нче аятьтән)* – һәрбер җан үлемне татыячак
*көн бә-көн* – көннән-көн
*көфран* – денсезлек
*көфу* – пар, тиңдәш
*крипеч* – ныгытма, кальга; рус телендәге «крепость» сүзе
*купис* – сәүдәгәр; рус телендәге «купец» сүзе
*куюбән* – куеп
*күргәз, күстәр* – күрсәт
*кыйгыр* – карчыга, лачын
*кыйлмаюр, кылубән* – кылмый, кылып
*кыйл-каль* – юк-бар сүз, имеш-мимеш
*кыйсьмәт, кыйсьме* – язмыш, язмышы
*кыям* – аягүрә басып тору
*кязибә* – ялганчы хатын-кыз
*кяр* – эш, шөгыль
*кятиб, кятибәһе* – язучы, моны язучы
*кяшки* – үкенечне белдерә торган ымлык: эх, аяныч, кызганыч

*ләгаб* – уен, кыйлану, ялган
*ләгаллә* – бәлки
*ләзиз* – татлы
*ләйл, ләйл-ү-нәһар* – төн, төн һәм көн
*лә рәеб* – шиксез

*ләтафәт, ләтыйф* – нәфислек, ямьле
*«Лә тәкънәтү мин рәхмәтулла» (Коръән, «Зүмәр» сүрәсе, 53 нче аять)* – Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез
*ләхедә* – ләхеткә
*ләхем* – ит
*«Ләһү мәза ма маза лә йәнфагул-хәзәрү галәл-каза» (хәдис аңлатмасыннан)* – үткән үтте инде, аның сезгә ярдәме юк
*ләял* – төннәр
*либас* – кием
*лика* – юлыгу, кавышу, очрашу
*Лилләһ* – Алла хакы өчен
*локмә* – бер кабым, телем, сынык
*лөгать* – тел, сүзлек
*ля әкаль* – һичьюгы, ким дигәндә
*лябед* – әлбәттә, котылгысыз, зарур
*лязим* – зарур, тиеш
*лямигъ* – ялтыраучы, нур чәчүче

*мазар* – зират
*максуд* – максат, ният
*максуд-у-гарзым* – максатым һәм аңлатуым
*манигъ* – киртә, каршылык
*«Ма Раббикә?», «Ма нәбийүкә?», «Ма динүкә?»* – Раббың кем, пәйгамәрең кем, динең нинди
*маһир* – оста
*маһ, маһы* – ай
*маэва* – урын
*мәган* – бергә
*мәгаш* – яшәү, тереклек
*мәгъбүд* – табына торган зат, Аллаһы Тәгалә
*мәгъдүд* – саналган, хисапланган
*мәгъдүм* – юк нәрсә, булмаган нәрсә
*мәгъзул* – хезмәттән азат ителгән
*мәгъзүр* – берәр сәбәп белән эшне эшли алмаучы
*мәгъмүм* – кайгылы, хәсрәтле
*мәгъмүр* – төзек
*мәгъфу* – гафу ителгән, кичерелгән
*мәгъюб* – гаепләнүче, гаебе булган
*мәдех, мәдехлә* – мактау, мактап
*мәдфүн тораб, мәркаде тораб* – кабер, җирләнгән
*мәдхә мөстәхикъ* – мактауга лаек
*мәҗал* – көч, мөмкинлек, түземлек
*мәҗалис* – мәҗлесләр
*мәҗмуг* – барлык, җыелган

*мәҗрух* – яралы, җәрәхәтле
*мәзият* – өстенлек
*мәзкүр* – әйтелгән, исеме аталган
*мәзруб* – суктырылган
*мәкалят* – язылган әйберләр
*мәкам* – урын
*мәкасыйд* – максатлар
*мәкруһ* – дин тарафыннан хупланмаган эш
*мәктүб* – хат
*мәкян* – урын
*мәкъбүл* – кабул күрелгән, яраклы
*мәкъһур* – каһәр төшкән, җәберләнгән
*мәляик* – фәрештәләр
*мәлямәт* – шелтәләү, орышу
*мәмат* – үлем, җан чыгу
*мәмдух* – макталган, мактап сөйләнгән
*мәмлү* – тулы
*мәнга, мәнгәде* – миңа, миңа иде
*мәнкуль* – күчерелгән
*мәнкүх, мәнкүхә* – никахлы ир, никахлы хатын
*мәнсәб* – дәрәҗә
*мәншүр* – билгеле бер хезмәт үтәү өчен бирелгән хокук кәгазе
*мәныг* – тоткарлык, киртә
*мәраз, мәриз* – авыру, хаста
*мәргуб* – кулай, әйбәт сыйфатлы
*мәрдүд* – кире кагылган, кабул ителмәгән
*мәсабих* – яктырткычлар, шәмдәлләр
*мәсаил* – мәсьәләләр
*мәсмуг* – ишеткән
*мәсрүр* – шат, сөенгән
*мәтаг* – йорт җиһазлары
*Мәүла* – ия, хуҗа (Аллаһы Тәгалә)
*мәүлид* – туган көн, туган җир
*«мәүте галим – кә-мәүте галәм»* – галимнең үлеме – бер галәмнең юкка чыгуы кебек
*«мәүтел-голәма идәр зольмәт» (хәдис)* – галимнәрнең вафаты караңгылык китерә
*мәхбүбә* – сөекле
*мәхбүс* – тоткын, әсир
*мәхдүм* – мулла улы
*мәхзүн* – хәсрәтле
*мәхү* – юк булу, юкка чыгу
*мәхфуз* – сакланган
*мәшарик* – кушылган, берләшкән кеше

*мәшвәрәт* – киңәш
*мәэхуз* – кабул ителгән
*мәэюс* – өметсез
*миръат* – көзге
*мисле* – кебек, охшаш
*миһман* – кунак
*Могыйн* – ярдәмче (Аллаһы Тәгалә)
*мозтар* – чарасыз, мәҗбүр
*моназарә* – бәхәс
*морагать* – әдәп саклау, игътибар итү
*моракабә* – рухани галәмгә чуму, күңелне чистарту
*мордар* – үләксә, шакшы
*мосыйбәт* – бәла, хәсрәт
*мотлака* – шиксез, ничек булса да
*мотыйг* – буйсынучы, сүз тыңлаучы
*мохалиф* – каршы
*мохәйяр* – irekле, ихтыярлы
*мохлис, мохлиса* – ихласлы
*мохтар* – сайланган
*мөәббәд* – мәңгелек
*мөбаләгълә* – арттырып, күпертеп
*мөбах* – дин тарафыннан кушылмаган да, тыелмаган да эш
*мөвәсвис* – вәсвәсәле
*мөждәлә* – сөенеч белән
*мөҗтәһид* – дин китаплары буенча хөкем чыгаручы
*мөзәйян һәм мөҗәүһәр* – зиннәтләнгән һәм бизәлгән
*мөкаддәм* – элек
*мөкаддәр* – тәкъдир, язмыш
*мөкәррәм, мөкәррәмә* – кадерле, хөрмәтле
*мөләттыйфде* – йомшак иде, тынычландыра торган иде
*мөнаҗәт* – догалар
*мөнәүвәр* – нурлы, якты
*мөнкатыйг* – өзелгән, тукталган
*мөнкәсир* – сынган, ватылган
*мөрид* – ишан шәкерте
*мөрүр* – узу, үтеп китү
*мөршид* – тугры юлга өндәүче, остаз, ишан
*мөсави* – бәрабәр, тигез
*мөсәлләм* – риза, канәгать
*мөсәммә* – исемләнгән, аталган
*мөстәҗәб* – теләгәне кабул ителгән
*мөттасил* – тоташ
*мөттәкый* – тәкъва, диндар
*мөфлихин* – уңышлы, теләккә ирешкән

*мөфсидәт* – азгынлык, бозыклык
*мөхаль* – мөмкин түгел
*мөхәкъкак* – шөбһәсез, ачык
*мөштак* – омтылучы, сагынучы
*мөшфикъ* – шәфкать итүче
*мөяссәр* – насыйп
*мунис* – якын кеше, дус

*нагозер* – гозерсез, ялынмый торган
*нагяһ, нагяһән* – кинәт, кинәттән
*надир* – сирәк, ялгыз
*назыйм* – шигырь язучы
*найумный* – ялланган кеше; рус телендәге «наёмный» сүзе
*нам* – исем, исемле
*намә* – хат, документ
*нас* – кеше
*насыйр* – ярдәмче, яклаучы
*нафигаде, нафигъ* – файда китерүче хатын-кыз, файдалы
*нәвафил* – яхшы эшләр
*нәваһи* – тыелган эшләр, эшләмәскә кушу
*нәдамәт* – үкенү, үкенеч
*нәдер* – нәрсә
*нәҗасәт* – шакшылар
*нәҗат* – котылу
*нәзар* – караш, игътибар
*нәзыйф* – пакь, пөхтә
*нәзым* – тезмә әсәр, шигырь
*нәкый* – пакь, катнашмасыз
*нәкыль кыйлдым* – күчердем
*нәсаих* – нәсихәтләр
*нәүм* – йокы
*нәфәка* – өлеш, ризык, яшәү өчен кирәк булган мал (акча)
*нәфәс* – сулыш, тын алу
*нәфгы* – файдасы
*нәфсә әммарә* – тыйнаксызлык, яманлыкка (бозыклыкка) тартучы эчке тойгы
*нәһи* – тыелган эш, эштән тыю
*нәчә* – ничаклы, күпме
*нида* – чакыру, тавыш, ыңгырашу
*ниса* – хатын-кыз
*нисьян мөнсиян* – бөтенләй онытып бетерү
*нифак* – икейөзлелек, алдакчылык
*ниязлә* – үтенеч белән, ялварып
*ноксанат* – кимчелекләр, җитешсезлекләр

*носрәт* – ярдәм
*нөфус* – җан, гомер
*нөфүс* – тыннар, сулышлар
*нуш* – эчемлек

*охрави* – ахирәткә бәйле, мәңгелек

*өҗрә* – хезмәт хакы
*өхләрем* – кызларым

*палашчы* – палач
*патлис* – әшәке җан, начар кеше; рус телендәге «подлец» сүзе
*пәнаһ* – яклаучы, саклаучы
*пәракәндә* – таркалу, хәсрәтләнү
*пәрһизкяр* – сакланучы, сакчыл
*пиядә* – җәяү
*пөр* – тулы
*пул* – вак бакыр акча берәмлеге
*пушты* – почта
*пырагып, пыракты* – ташлап, ташлады

*Раббел-әрбаб* – хуҗаларның хуҗасы (Аллаһы Тәгалә)
*рабутник* – эшче; рус телендәге «работник» сүзе
*рат* – шат; рус телендәге «рад» сүзе
*рәваҗ* – таралу
*рәгъбәт* – теләү, омтылыш, кызыксыну
*рәдд* – кире кагу
*раси* – какшамас, үзгәрешсез
*раушан* – яктыртучы, нурлы, ачык
*Рәхим* – рәхимле, ярлыкаучы (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исеме)
*рәхимә* – рәхимле хатын-кыз
*риҗа* – үтенеч, теләү
*рих-ү-рәйхан* – хуш исләр
*риядел-җәннәт* – җәннәт бакчасы
*рия-ү-көбер* – рия һәм тәкәбберлек
*рөҗуг* – кайту
*рөкүгъ* – иелеп тору, намазда тезләргә таяну
*рөтбә* – дәрәҗә
*руз-у-шәбде* – көн һәм төн иде
*руйсияһ, руйи сияһ* – кара йөзле
*русия* – рус теле
*сабавәт* – сабыйлык
*сабах* – таң
*сабира* – сабыр хатын-кыз

*сабранжҗа* – рус телендәге «собрание» сүзе; бу китаптагы текстларда Уфадагы Диния Нәзарәте – «Мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя» («Оренбургское Духовное магометанское собрание») күздә тотылган
*сабры җәмил* – күркәм сабырлык
*сагъ* – сау
*сада* – аваз
*садир* – барлыкка килү, башлану
*саеп, сая* – санап, саный
*саим* – ураза тотучы
*сайд* – ау, аучылык, балык тоту
*салимин* – сәламәтләр, исән-сау торучылар
*самигъ* – тыңлаучы, ишетүче
*сарих* – ачык, ап-ачык
*Саттар* – гөнаһларны кичерүче (Аллаһы Тәгаләнең күркәм сыйфаты)
*сахиб* – ия, автор
*сахибе михраб* – михраб иясе, имам, мулла
*сәб* – сүгү, начар сүзләр әйтү
*сәбил* – юл, олы юл
*сәвад* – кара
*сәвекле, сәвеп* – сөекле, сөеп
*сәгать бә-сәгать* – сәгать саен
*сәгый* – тырышлык
*сәдакаи җария* – дәвамлы файдасы булырдай игелек
*сәйеат* – начарлыклар, бозыклыклар
*сәкран* – исереп
*сәкыйльде* – авыр иде, кыен иде
*сәлами хитаб* – карагыз: *иржҗигый хитап*
*сәлим* – сәламәт, төзек
*сәмарат* – җимешләр, нәтиҗәләр
*сәмәк* – балык
*сәмән* – акча
*сәнә* – ел
*сәнга, сәнсән* – сиңа, синсең
*сәнчү* – чәнчү
*сәрвәр* – дәрәҗәле кеше
*сәргаскәр* – гаскәр башлыгы
*сәргәрдан* – аптыраган
*сәргезәшт* – баштан үткән хәл, вакыйгалар
*сәркәшйазидан, сәркәшлек* – карышу, каршылык күрсәтү, тыңламау
*сәтер* – ябыну
*сәтыр* – юл, язу юлы
*сәү* – сөй, ярат

*сәхаб зольмәте* – болыт караңгылыгы
*сәһел* – җиңел
*сәһер* – уяулык, йокысызлык
*сәясендә* – эчендә, янында
*симагъ, симагълә* – ишетү, ишетеп
*сиррән* – яшерен, кешегә күренмичә
*сияһ* – кара
*сор, сордисә, сормыш* – сора, сораса, сораган
*сөаль, сөалә* – сорау, сорауга
*сөек* – сөекле
*сөҗуд* – сәҗдә, иелү
*сөрүр* – шатлык, сөенеч
*сөхән* – сүз
*суд* – файда
*сыгмас гаребә һәм шәрык* – көнбатышка да, көнчыгышка да сыймас
*сыйбиян* – сабыйлар

*табигъ* – буйсынучы, иярүче
*тавил* – озын
*таг-у-таш* – тау һәм таш
*тайиб* – яхшы, хуш
*тайяр* – хәзер, әзерләнгән
*таләбә* – шәкертләр
*талиб* – шәкерт
*там* – тулы, бөтен, төгәл
*тамгы* – зур теләк, ачкүзлелек
*тараз* – сурәтләү
*тарикать* – ишанлык юлы
*тарых* – ташлау
*тасдыйк* – раслау
*тәварих* – тарихлар
*тәгаб* – мәшәкать, хезмәт кую
*тәгаллем* – уку, белем алу
*тәгъдид* – санау
*тәгъдил* – гадел хәл итү, хөкемне йомшарту
*тәгъҗил* – ашыктыру, тизләтү
*тәгъзия* – кайгы уртаклашу
*тәгъзыйм* – олылау, хөрмәтләү
*тәҗавез* – гафу итү
*тәҗәссес* – эзләнү, тикшерү
*тәзкирә* – истәлек
*тәкаббәл* – кабул итү
*тәказа* – кичектерү
*тәкәллем* – сөйләү

*тәклиф* – көчләп
*тәкрар* – кабатлау
*тәкрим* – хөрмәтләү
*тәкъсыйр* – руханиларга олылап эндәшү сүзе
*тәкый* – тагын
*тәлкыйн* – мәетне җирләп, озатучылар киткәч, мулланың үлекнең исенә төшерү өчен иман укуы
*тәлкыйнлә* – аңлатып
*тәмәллык* – ялыну, ялагайлану
*тәмиз* – саф, чын
*тәнбиһ* – кисәтү, искәртү
*тәнзиһ* – пакьләү
*тәрәддед* – шикләнү, шөбһәләнү
*тәрәххем* – мәрхәмәт итү, кызгану
*тәрҗигъ аяте* – Коръәндәге «Әл-Бәкара» сүрәсенең 156 нчы аяте: «Инна Лилләһи вә инна иләйһи раҗигун» (мәгънәсе: «Без Аллаһы тарафыннан яратылганбыз һәм аның хозурына кайтабыз»)
*тәрк* – ташлау, кую
*тәркиб* – сүз тезмәсе
*тәсаддык* – сәдака бирү
*тәсәлла* – юату
*тәслим* – тапшыру
*тәукыйр* – олылау, хөрмәтләү
*тәфасир* – тәфсирләр
*тәфәррежлә* – ял итеп
*тәфсилән* – тәфсилләп
*тәфтиш* – тикшерү
*тәхәммел* – күтәрә алу, чыдау
*тәхкыйк* – һичшиксез
*тәхкыйрь* – яманлау, хурлау
*тәхминән* – якынча
*тәхсин* – мактау
*тәхфиф* – кимсетү
*тәһәҗҗед* – төнлә укыла торган намаз
*тәһлил* – «Лә иләһә иллә Аллаһ» (бер Алладан башка илаһы юк) җөмләсен әйтү
*тәэхир* – кичектерү, соңга калдыру
*тәшәһһед* – намазда «Әттәхият» догасын уку
*тәшрих* – анатомия
*тәяммем* – су булмаганда кулларны туфракка сугып тәһарәт алу
*тилавәт* – Коръән уку
*тогъян* – азгынлык
*торубән* – торып
*төркийә* – төрекчә

*төфәң-ука маһир* – мылтык-укка оста, аучы
*трахтир* – трактир
*тулуг* – тулы
*тулляб* – шәкертләр
*туле әмәл* – өметтә комсызлык

*у* – ул
*укубән, укыян* – укып, укыган
*ула, улгач, улмасде, улса, улурсән, улмыш* – була, булгач, булмас иде, булса, булырсың, булган
*ултырмыш* – утырган
*умарып* – өметләнеп
*усы* – акылы, тәрбиясе
*ушандак* – шулай ук

*үгрәнде, үгрәтмеш* – өйрәнде, өйрәткән

*фазл-у-гыйнаять, фазл-у-кәрәм* – өстенлек һәм ярдәм, өстенлек һәм юмартлык
*фазыл* – өстенлек, камиллек, белемлелек
*фаиз* – теләгәненә ирешүче
*фарзы гайн* – эшләнергә тиешле гыйбадәт гамәлләре
*фарсыви* – фарсыча
*фасикъ* – бозык, имансыз
*фасыйл кыйлмыш* – аерган
*«Фә-әдгу Аллаһә мохлисинә» (Коръән, «Гафир» сүрәсе, 14 нче аятьтән)* – ихлас белән Аллаһка гыйбадәт итегез
*фәлях* – бәхет, котылу
*фәраиз* – фарыз эшләр, мирас бүлү кагыйдәләре
*фәрекъ, фәркъ, фәрикъ* – аеру, аерма
*фәрех, фәрхан* – шатлык, сөенеп
*фәүҗ-фәүҗ* – төркем-төркем
*фәүзе нәҗат* – котылу
*фил-җөмлә* – тулаем, шул исәптән
*фирак* – аерылу
*фираш* – ятак, түшәк
*фирагать* – аерма
*фи сәбилиллаһ* – Аллаһ юлы өчен
*фискъ-у-фәсад* – бозыклык һәм азгынлык
*фөҗу(р)* – бозыклык, әхлаксызлык
*фөҗьәт, фөҗьәтән* – кинәт, көтмәгәндә
*фөнүн* – фәннәр
*фөюзат* – бәрәкәтләр, белемнәр

*хаб* – йокы
*хадим* – хезмәтче
*хаҗәт* – хаҗәтләр
*хаз* – өлеш, ләззәт
*хазир* – булучы, катнашучы
*хакепай* – аяк астындагы туфрак
*халә* – хәзер
*хали* – буш
*Халикъ* – барча галәмне яратучы (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исеме)
*халка* – халыкка
*хам, хамә* – җитлекмәгән, тупас
*хамил* – күтәрүче
*ханә* – йорт
*харикъ улмыш* – янган
*харикыльгадә* – гадәттән тыш
*хасид* – хөсетле
*хатим* – ахыр
*хауз* – күл
*Хафиз* – бәла-казалардан саклаучы (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исеме)
*хашия* – бер китапның эчтәлеген ачыклый торган икенче китап
*хәбиб* – сөекле, дус
*хәдәс* – кече йомыш
*хәддән бирән* – чиксез биргән
*хәез-ү-нифас* – күрем һәм аналык каны
*хәзәр* – утрак тормыш
*хәйрат* – хәер-сәдакалар, изге эшләр
*хәкарәт* – яманлау, хурлау, сүгү
*хәкарәт-ү-мәлямәт* – хурлау һәм орышу
*хәлилә* – хатын
*хәляс, хәляслә* – котылу, котылу белән
*хәмакать* – акылсызлык, тинтәклек
*хәмәл* – зодиакаль календарьдагы ай атамасы; 22 марттан 22 апрельгә кадәрге вакыт арасы
*хәмед* – мактау, данлау
*хәмел* – күтәрү
*хәммам* – мунча
*хәрарәт* – эсселек
*хәсәб-нәсәб* – данлы нәселдәш
*хәсәнат* – саваплы эшләр
*хәсир* – арыган, хәсрәт чигүче
*хәсис* – әшәке, начар
*хәсым* – каршылык
*хәтем* – уку

*хәүфә* – хәвефләнү, курку
*хәфиф* – җиңел, ансат
*хәшер* – кыямәт
*хәя* – оят, тыйнаклылык
*хәят* – яшәү
*хиҗаләт* – оялу, оялып йөз кызару
*хиҗарат* – ташлар
*хилаф* – каршы
*хинзир* – дуңгыз
*хисса* – өлеш
*хитап* – мөрәҗәгать
*хифыз* – саклау
*хиш* – якын, туган, кардәш
*хосем* – дошманлык
*хотур* – хәтергә килү
*хофәр* – кабер
*хофр-у-нар* – кабер һәм тәмуг
*хошугъ-хөзугълә* – түбәнчелек белән
*«Хөббел-ватан мин әл-иман» (уйдырма хәдис)* – «Ватанга мәхәббәт – иманлылыктан»
*хөллә назик* – нәзек хөллә (өс киеме)
*хөммәлә* – кабер
*хөруф* – хәрефләр
*хөсне зан* – яхшы уй
*хөсне хатимә* – күркәм ахыр

*һакәза* – шулай, шулай ук
*һәба* – тузан бөртеге, файдасыз
*һәдия* – бүләк
*һәндәсия* – геометрия
*һәп* – бөтен, барча
*һәфтә* – атна
*һидаять* – туры юлга керү
*һиҗрәт* – күчеп китү
*һиҗрия* – һиҗри (мөселманча) ел исәбе
*һиммәт* – тырышлык

*чәшем* – күз
*чичек, чөчек* – татлы
*чөн* – өчен
*чурак* – буш, уңдырышсыз, файдасыз

*шагъ* – ачык, якты, нурлы
*шаигъ* – таралган, билгеле

*шат-у-хәррәм, шат-хәррәмде* – шат һәм куанган, шат-куанган иде
*шафигъ* – шәфагать кылучы, яклаучы
*шәвагыйль* – шөгыльләр, эшләр
*шәдид* – көчле, кырыс
*шәй* – әйбер
*шәйх вә шаб* – карт һәм яшь
*шәк, шәкавәт* – шик, бәла
*шәкый* – явыз, бәхетсез
*шәмаил* – холык, сыйфат
*Шәмс-ү-Камәр* – Кояш һәм Ай
*шәраит* – шартлар
*шәремсар* – оятлы
*шәрех* – кискәләү, аңлатма
*шәрик* – иптәш, катнашучы
*шәрме йә хәер* – яхшымы яки яманмы
*шәтем* – сүгү, хурлау
*шәфагать* – арадашлык, яклау
*шәфикъ* – шәфкатьле, рәхимле
*шәятыйн* – шайтаннар
*шиддәт* – көчле
*шикяр* – ау аулау
*шимди* – хәзер
*шөҗагать* – батырлык, гайрәт
*шөруг кыйлмыш* – керешкән
*шөрүр* – әшәкелекләр, явызлыклар
*шөһәда* – шәһидләр

*эстәү* – теләү
*эчмеш әҗәли шәрап* – әҗәл шәрабын эчкән; ягьни, вафат булган

*юубән* – юып

*якыйн, якыйнән* – ачык белү, ышанып
*янибең* – дөресе: җанибең – яның
*яран* – иптәшләр, дуслар, якыннар
*ятмаю* – ятмыйча

# РЕЗЮМЕ

В 33-ем издании серии «Татарская археография» представлены поэтические произведения Нигматуллы Султанбекова (1841–1928), уроженца села Верхняя Ошма Мамадышского района Республики Татарстан.

Выходец из семьи священнослужителей (его отец Мухамметсафа и дед Кульмухаммет служили муллами в этом селении), Нигматулла Султанбеков также стал имамом, но внезапная тяжёлая болезнь, случившаяся в 1891 году, приковала его к постели на долгие годы. Несмотря на недуг, Нигматулла не оставлял писательской деятельности: сочинял стихи и элегии, переписывал поэтические сочинения Кульмухаммета Султанбекова (1777–1849). Наследие Нигматуллы Султанбекова, помимо сочинений, представлено мусульманскими надгробными плитами, которыми он занимался ещё до болезни. На кладбищах разных селений Мамадышского и других районов республики сохранились изготовленные им изящные эпиграфические памятники.

В отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан хранятся восемь рукописных сборников Нигматуллы Султанбекова. Один интереснейший сборник автора хранится у потомков Султанбековых. В нём содержатся два произведения: «Шеджере» (Родословная) и одна элегия, посвящённая брату автора, а также схема родословной Султанбековых. Родословная представляет ценный исторический материал.

В данной книге представлены: родословный список, полные тексты «Шеджере» и четырёх элегий, также избранные стихотворные тексты из различных сборников автора. Элегии Н.Султанбекова посвящены его близким людям, а также уважаемому имаму села Нижняя Ошма Хадиулле хазрату.

Первая из них посвящена родному брату автора – мулле Шаихзаде Султанбекову, покинувшему родную землю во время переселения мусульман-татар в Турцию, где он скончался летом 1894 года.

Элегия, посвящённая Мубаракзаде – родному племяннику, описывает движение татарской учащейся молодёжи, которая в начале 1907 года, оставив своё медресе в деревне Тюнтер, продолжили учё-

бу в Иж-Бобьинском медресе – одном из передовых татарских учебных заведений своего времени.

Самая объёмная элегия Н.Султанбекова посвящена его супруге Бибитаибе, скоропостижно скончавшейся в 1924 г. Супруги прожили вместе 55 лет, из которых 34 года Бибитаиба посвятила заботам о больном супруге. Автор в разных текстах описывал и своё тяжёлое состояние. Все элегии пронизаны глубокой горечью утрат своих близких.

Произведения Н.Султанбекова передают богатые литературные традиции: язык его сочинений близок к языку многовековой тюркоязычной суфийской литературы, произведений известных татарских поэтов XIX века – Хибатуллы Салихова-Каргалы, Гали Чукри и др.

Во вступительной статье дан детальный обзор произведений Н.Султанбекова, содержится информация о его роде, о родном селении, об изготовленных им эпиграфических памятниках.

В конце книги представлено научное описание рукописей Нигматуллы Султанбекова. Издание иллюстрировано факсимиле отдельных рукописей автора.

# «ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР

(төзүчесе – археограф, текстолог Раиф Мәрданов;
«Милли китап» нәшрияты)

**Мәүла Колый поэмалары:** «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты». – Казан, 2008. – 88 б. – (1 нче китап). **Шул ук.** Икенче басма. – Казан, 2011. – 88 б.

**Түләк китабы: дастан**. – Казан, 2008. – 76 б. – (2 нче китап).

**«Кыйссаи Йосыф»** поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар. – Казан, 2009. – 92 б. – (3 нче китап).

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: әсәрнең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары.** – Казан, 2009. – 128 б. – (4 нче китап).

**Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары...** – Казан, 2010. – 92 б. – (5 нче китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур**. – Казан, 2010. – 128 б. – (6 нчы китап).

**[Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы**. – Казан, 2011. – 68 б. – (7 нче китап).

**Сәяхәтнамәләр.** – Казан, 2011. – 84 б. – (8 нче китап).

**Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте**. – Казан, 2012. – 184 б. – (9 нчы китап).

**Кыз хикәяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (10 нчы китап).

**Сөрген хатлары.** – Казан, 2013. – 103 б. – (11 нче китап).

**«Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр**. – Казан, 2013. – 128 б. – (12 нче китап).

**«Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре.** – Казан, 2014. – 119 б. – (13 нче китап).

**Гали авылы тарихы.** – Казан, 2014. – 164 б. – (14 нче китап).

**Тинчурин К. Каракүз: музыкаль мелодрама; Нәни абый: комедия.** – Казан, 2015. – 192 б. – (15 нче китап).

**Тинчурин К. Чит илләрдә: хыялый комедия.** – Казан, 2015. – 108 б. – (16 нчы китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер.** – Казан, 2016. – 124 б. – (17 нче китап).

**Сугыш һәм солдат бәетләре.** – Казан, 2016. – 264 б. – (18 нче китап).

**Дастане җайә (Мәликә китабы).** – Казан, 2017. – 148 б. – (19 нчы китап).

**Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898–1906 еллар**. – Казан, 2017. – 140 б. – (20 нче китап).

**Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар.** – Казан, 2018. – 180 б. – (21 нче китап).

**Солдат Ярулла дәфтәре:** бәетләр һәм мөнәҗәтләр. 1905–1906 еллар. – Казан, 2018. – 92 б. – (22 нче китап).

**«Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар. –** Казан, 2019. – 288 б. – (23 нче китап).

**Халык җырлары: XVII–XX гасырлар.** – Казан, 2019. – 146 б. – (24 нче китап).

**Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре: Җиңүнең 75 еллыгына**. – Казан, 2020. – 276 б. – (25 нче китап).

**Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар**. – Казан, 2020. – 218 б. – (26 нчы китап).

**Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар**. – Казан, 2021. – 252 б. – (27 нче китап).

**Шәҗәрәләр**. – Казан, 2021. – 196 б. – (28 нче китап).

**«Утызынчы елларда...»: халык тормышының фаҗигале сәхифәләре.** – Казан, 2022. – 180 б. – (29 нчы китап).

**Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә.** – Казан, 2022. – 250 б. – (30 нчы китап).

**Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә.** – Казан, 2023. – 234 б. – (31 нче китап).

**Килешү-хокук язмалары (XVIII–XX гасыр башы).** – Казан, 2023. – 224 б. – (32 нче китап).

# ЭЧТӘЛЕК


«ОНЫТМАГЫЗ БУ ЗӘГЫЙФЬНЕ...» ....................................................3

Туган авылы турында кыскача ....................................................3

Автор һәм аның нәселе....................................................5

Кабер ташлары ясау остасы ....................................................12

Кулъязмалары ....................................................17

Әсәрләре ....................................................21

Мәрсияләре....................................................26

Шигърияте....................................................36

Әсәрләрнең теле....................................................39

Китапта текстларның бирелеше ....................................................40

Шәҗәрә (исемлек) ....................................................43

«Шәҗәрә» ....................................................50

Мәүлид....................................................70

Шәехзадә мәрсиясе....................................................86

Һадиулла хәзрәт мәрсиясе ....................................................99

Мөбарәкзадә мәрсиясе ....................................................108

Бибитаибә абыстай мәрсиясе ....................................................137

«Иказел-әүляд» ....................................................180

Дога ....................................................198

Кыйла күргел доганызны!....................................................199

Кулъязмалар тасвирламасы....................................................202

СҮЗЛЕК ....................................................221

РЕЗЮМЕ ....................................................243

«Татар археографиясе» сериясендә чыккан китаплар ........................245

# ПРОИЗВЕДЕНИЯ НИГМАТУЛЛЫ СУЛТАНБЕКОВА

*(на татарском языке)*

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Ирина Мещанинова

Басарга кул куелды 24.05.2024. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 100 данә. Заказ № 489.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86.

Подписано к печати 24.05.2024. Формат 60x84 1/16.
Тираж 100 экз. Заказ № 489.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.

[illegible]

... معلوم قیلمش ایدی

... شهید اصحاب بیله بیلدی

... اوردن کلدی

... بیر سنی آرزو قیلادی

... اوروب عمر دوری قیلدی

... پیغمبر ... بیلدی

... سنی جمالنی کورکل ...

... اول شهید اول قیبو ...

... قیلدی اول ...

... دوری ... بر ... ایدی

[illegible]

اینشد ...

اول شهید حق ... قیلدی

... اول ...

اول شهیدنک ... قبول ...

اول شهیدی ...

... قتیلونی ...

بیر سنی آلله ...

علی الدوام ... قیلدی ...

بیر سنی ... آرزو ...

اولکنده ...